# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2022 2(34)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның халык шагыйре (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Нур-Солтан)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
МӨХӘММӘТҖАНОВА Л.Х., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., ЛУКЬЯНЧЕНКО Е.Ф., ЧУГУНОВ А.С.

**БУ САНДА**

## ТЕЛ БЕЛЕМЕ


*Нуриева Ф.Ш.* Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» дастанының поэтик үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
*Кузьмина Х.Х.* Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында метафоралар кулланышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
*Мирхәев Р.Ф.* XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә *-мак* кушымчалы исем фигыльләрнең кулланылыш үзенчәлекләре . . . . . . . . . . 25
*Хөсәинова А.Я.* Татар диалекталь консонантизмын өйрәнүнең кыскача тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30


## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ


*Закирова И.Г., Даутова С.Б.* Алтын Урда чорын чагылдырган тарихи романнар: автор концепциясе *(В. Ян һәм И. Есенберлин иҗатлары мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
*Хәбетдинова М.М.* Хәзерге заман татар һәм башкорт әдәбиятларында газап чигүче хатын-кыз образлары. . . . . . . . . 44
*Галиева Л.Ш.* Фәиз Зөлкарнәй хезмәтләрендә әдәби тәнкыйть мәсьәләләре. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
*Хөсәенова Г.Р.* Татар романик дастаны: әдәби-сәнгати үзенчәлекләре *(«Ләйлә белән Мәҗнүн» дастанының кулъязма варианты мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62


## ХАЛЫК ИҖАТЫ


*Сафиуллина Р.Ф.* Татар фольклорын рус теленә тәрҗемә итү мәсьәләләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
*Брусько З.М.* Татар дастаннарында этник йолалар чагылышы . . . 79


## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ


*Сибгатуллина Ә.Т.* «Идел-Урал» журналы (1955) . . . . . . . . . . 85


## ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕН РӘСМИ КАБУЛ ИТҮГӘ – 1100 ЕЛ


*Дәүләтшин Г.М.* Болгарларда ислам таралышы этаплары . . . . . 93
*Хуҗин Ф.Ш.* Болгар илендә ислам һәм элгәреге шәһәрләр . . . . 103
*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Татар дастаннары үсешендә исламның роле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
*Ахунов А.М.* Ибне Фазлан «Язмалар»ының татар теленә беренче фәнни тәрҗемәсе турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121


## СӘНГАТЬ


*Шевченко Е.Н.* Әлмәт татар дәүләт драма театры сәхнәсендә немец драматургиясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

*Гыйлаҗев З.З.* Татар язучылары әдәби мирасы
Татарстан Республикасы музейларында . . . . . . . . . . . . . . . . 135
*Умәров Д.И.* Дөнья картинасы контекстында
татарларның традицион бию культурасы . . . . . . . . . . . . . . . . . 140

**ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР ФӘНЕ**

*Фәхриева Л.М., Дәүләтшина Л.Х.* Төрек мифологиясе
персонажларын классификацияләү мәсьәләсенә карата . . . . . . 146

**ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР**

Солтан Габәши татар музыкасы турында *(дәвамы)* . . . . . . . . 152

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Майнагашева Н.С.* Күренекле тюрколог
Николай Федорович Катанов юбилее уңаеннан . . . . . . . . . . . 165
*Галимҗанова Э.М.* Фазыл Туйкин мирасы: барлау һәм өйрәнү
мәсьәләләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Галимова О.Н.* И.И. Сабитова, Э.И. Сафина, Ф.И. Таһированың
«Татар теленең кыенлыклар сүзлеге»
(Казан: ТӘһСИ, 2019. 184 б.) турында . . . . . . . . . . . . . . . . 174

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Нуриева Ф.Ш.* Поэтические особенности дастана «Джумджума султан» Хисама Кятиба . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
*Кузьмина Х.Х.* Метафоры в поэме «Кысса-и Йусуф» Кул Гали . . . 18
*Мирхаев Р.Ф.* Особенности использования имен действий на *-мак* в произведениях татарской просветительской прозы конца XIX – начала XX века . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
*Хусаинова А.Я.* Краткая история изучения татарского диалектального консонантизма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30

## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Закирова И.Г., Даутова С.Б.* Художественные особенности авторских концепций истории и личности эпохи Золотой Орды *(на примере творчества В. Яна и И. Есенберлина)* . . . . . . . . . 35
*Хабутдинова М.М.* Образы женщин-мучениц в произведениях современной татарской и башкирской литератур . . . . . . . . . . 44
*Галиева Л.Ш.* Вопросы литературной критики в трудах Фаиза Зулькарная . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
*Хусайнова Г.Р.* Литературно-художественные особенности татарского романического дастана *(на примере рукописного варианта «Лейли и Маджнун»)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Сафиуллина Р.Ф.* Проблемы перевода жанров татарского фольклора на русский язык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
*Брусько З.М.* Отражение этнических обрядов в татарских дастанах . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Сибгатуллина А.Т.* Журнал «Идел-Урал» (1955) . . . . . . . . . . . 85

## 1100 ЛЕТ СО ДНЯ ПРИНЯТИЯ ИСЛАМА ВОЛЖСКОЙ БУЛГАРИЕЙ

*Давлетшин Г.М.* Этапы распространения ислама у волжских булгар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
*Хузин Ф.Ш.* Ислам и древние города в Волжской Булгарии. . . . 103
*Мухаметзянова Л.Х.* Роль ислама в формировании и развитии жанра дастана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
*Ахунов А.М.* О первом научном переводе «Рисале» Ибн Фадлана на татарский язык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121

## ИСКУССТВО

*Шевченко Е.Н.* Немецкая драматургия на сцене Альметьевского татарского государственного драматического театра . . . . . . . 128

*Гилазев З.З.* Литературное наследие татарских писателей в музеях Республики Татарстан . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
*Умеров Д.И.* Традиционная танцевальная культура татар в контексте картины мира . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140

**НАУКА ТЮРКСКИХ НАРОДОВ**

*Фахриева Л.М., Давлетшина Л.Х.* Вопросы классификации мифологических персонажей турецкой мифологии . . . . . . . . 146

**НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ**

Султан Габаши о татарской музыке *(продолжение)* . . . . . . . . 152

**ПЕРСОНАЛИИ**

*Майнагашева Н.С.* К юбилею великого тюрколога Николая Федоровича Катанова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
*Галимзянова Э.М.* Наследие Фазыла Туйкина: вопросы изучения . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169

**НОВЫЕ КНИГИ**

*Галимова О.Н.* О словаре «Татар теленең кыенлыклар сүзлеге» (Казань: ИЯЛИ, 2019. 184 с.) И.И. Сабитовой, Э.И. Сафиной, Ф.И. Тагировой . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174

**НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ**

УДК 811.512.001.5

***Ф.Ш. Нуриева***

# ХИСАМ КЯТИБНЕҢ «ҖӨМҖӨМӘ СОЛТАН» ДАСТАНЫНЫҢ ПОЭТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Хисам Кятиб был крупнейшим поэтом, в творчестве которого нашли отражение основные тенденции тюрко-татарской литературы золотоордынского периода. Статья посвящена раскрытию мастерства поэта в употреблении языковых ресурсов при создании поэтического текста «Джумджума султан». Ритмика стихотворения, формирующая многообразные структуры, основана на схеме рифмовки по бейтам месневи. В поэтике Хисама Кятиба автологический приём употребляется своеобразно, позволяя выделить экспрессивные языковые и стилевые приёмы автора. Основу металогического приёма составляют такие стилистические средства, как гипербола, метонимия. Исследование изобразительных средств поэмы Хисама Кятиба позволяет выявить общие закономерности развития поэтики татарского литературного языка.

**Ключевые слова:** Хисам Кятиб, «Джумджума султан», золотоордынский, поэтика, автологический, металогический приём.

Khisam Kyatib was a famous poet whose work reflected the main trends of the Turkic-Tatar literature of the Golden Horde period. The article reveals how the poet skillfully used the language resources to create the poetic text «Jumjuma Sultan». The rhythm of the poem which forms diverse structures is based on the rhyming scheme based on Mesnevi bayts. In the poetics of Khisam Kyatib the autological technique is used in a peculiar way, allowing to highlight author's expressive linguistic and stylistic tools. The metalogical technique is made up of such stylistic means as hyperbole and metonymy. The study of the visual means of the poem by Khisam Kyatib allows us to identify the general patterns of the Tatar poetics.

**Keywords:** Khisam Kyatib, «Jumjuma Sultan», the Golden Horde, poetics, autological technique, metalogical technique.

Көнчыгышта киң таралган җан белән тән бәхәсе, Кисекбаш турындагы риваятьләрнең сюжетын файдаланып, аларны иң беренче шигырь юлларына салучы булып фарсы шагыйре Фәридетдин Гаттар санала. 1369 елда Идел буе шагыйре Хисам Кятиб, мәгълүм сюжетка нигезләнеп, «Җөмҗөмә солтан» дип аталган дини-лирик эчтәлекле әсәр иҗат итә. В.Д. Жуковский һәм Е.Э. Бертельс әйтүенчә, үзенең әсәрен ул турыдан-туры фарсы чыганагыннан тәрҗемә итмәгән, мөселманлык рухын арттыру йөзеннән, яңа темалар өстәгән, мәсәлән, җәһәннәм һ.б. Язылу датасы әсәрдә күрсәтелгән: «Кем тарих йите йөз йитмеш иде, Хисам Кятиб моны битмеш иде» [Татар әдәбияты…, 1986, б. 232]. Археографик экспедицияләр вакытында «Җөмҗөмә солтан» кульязмаларының даими табылып торуы – аның татарлар арасында электән таралганлыгына ачык дәлил. Хисам Кятибнең Идел-йортта яшәве, Алтын Урда белән бәйләнеше галимнәр арасында бәхәс

уятмый [Миңнегулов, 2014, б. 292]. Урта төрки чор әдәби телләрен өйрәнүче төрек галиме Айсу Ата Алтын Урдадагы мөселман төркиләре тарафыннан яратып укылган бу әсәрнең 995/1548 елда Кырым ханы Сәхипгәрәй бин Хаҗи Гәрәйнең әмере буенча Алтын Урда төрки теленнән Анадолу төркисенә тәрҗемә ителүен күрсәтә [Aysu Ata, 2014, s. 57]. Хәзерге вакытта мирасханәләрдә поэманың 26 нөсхәсе булуы билгеле, шуларның 18 е – Казан шәһәре мирасханәләрендә, Башкортстан Республикасы Фәннәр академиясенең Тарих, тел, һәм әдәбият институты архивында – өч кулъязма, Көнчыгышны өйрәнү Институтының Санкт-Петербург бүлеге фондында – өч нөсхә, Париж милли китапханәсендә әсәрнең бер күчермәсе саклана [Нуриева, 2011, с. 77–80]. Кулъязма күчермәләрнең күпчелеге XIX гасыр башына карый. А.И. Исламова поэманың гарәп хәрефләрендәге күчермәләренә һәм басма нөсхәләренә нигезләнеп төзегән тәнкыйди текстын диссертациясенең кушымта өлешендә урнаштырган, мәкаләдәге мисаллар әлеге хезмәттән китерелде [Исламова, 1998, с. 39–62 ].

Хисам Кятиб поэмасын беренчеләрдән булып өйрәнгән тюркологлар – И.Н. Березин, Т. Флейшер, С.Н. Эргун, М.Ф. Көпрүлүзадә, Е.Э. Бертельс. Күренекле галимнәр әсәрне Алтын Урда мохите әдәби җимеше дип саныйлар. Е.Э. Бертельс «Җөмҗөмә солтан» поэмасы теленең «шактый саф кыпчак телле» булуын ассызыклый [Нуриева, 2011, с. 80].

XX гасырның 60 нчы елларыннан башлап истәлекне татар әдәбияты ядкяре, Шәрык классикасы арасындагы багланышлар, Урта гасыр татар фәлсәфә фикере юнәлешендә Г. Госман, Ш. Абилов, Х.Й. Миңнегулов, М. Әхмәтҗанов, Р.М. Әмирханов, А.М. Шәрипов кебек күренекле татар галимнәре өйрәнә, «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томында язма истәлек һәрьяклап тулы яктыртылган [Татар әдәбияты…, 1984, б. 231–246, 2014, б. 292–300]. Татар телчеләре поэмада үз чоры өчен гаять кыю һәм гуманистик фикерләр үткәрелүен, әсәр теленең гадилеге һәм хәзерге татар теленә бик якын торуын күрсәтәләр. Мәсәлән, Х. Курбатов төрки халыкларның гомуми әдәби ядкярләре арасында Хисам Кятиб әсәре бүгенге татар теленә иң якыны дияргә була, дип билгели [Курбатов 1984, б. 61–70]. Татар әдәбиятының кыйммәтле истәлеге «Җөмҗөмә солтан» тел җәһәтеннән А.И. Исламованың кандидатлык диссертациясендә графо-фонетик, морфологик, лексик планда шактый тулы өйрәнелгән [Исламова, 1998]. Алтын Урда чоры язма истәлекләре, шул исәптән «Җөмҗөмә солтан» әсәре дә, «Татар әдәби теле тарихы» хезмәтенең өч томында графофонетик, грамматик һәм лексик яссылыкта тикшерелде [Татар әдәби теле тарихы, 2015, б. 271–326; 2017, б. 112–195; 2019, б. 172–251].

«Җөмҗөмә солтан» поэмасының сәнгатьчә эшләнеше бик тә югары, әдәбиятчылар һәм телчеләр тарафыннан бу хакта күп фикерләр әйтелгән. Әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләргә, композиция, сюжет, традициягә нисбәттә сурәтләү алымнары Ш. Абилов, Х.Р. Курбатов, Х.Й. Миңнегулов, А.И. Исламова хезмәтләрендә аеруча җентекле ка-

ралган. Бүгенге көн укучысына дастан Җәвад Алмаз тәрҗемәсендә тәкъдим ителгән [Алмаз, 1996, б. 42–57].

Ф. Гаттар һәм Х. Кятиб әсәрләренең нигезендә Җөмҗөмә һәм Гайсә турындагы легенда ятса да, аларга салынган идея эчтәлегендә аерма бар. Гаттардагы Җөмҗөмә солтан – Алласын, пәйгамбәрен белмәгән мәҗүси зат, Х. Кятибтә исә мөселманлык төсмерен алуы, дөньялыктагы игелекне өстен куюы һәм сәнгатьчә эшләнеше белән аерыла.

«Җөмҗөмә солтан»ның сюжеты мавыктыргыч, андагы вакыйгалар турыдан-туры чынбарлыкны тасвирламый, фантастик алым кулланып, яшәеш хакында фикер йөртелә. Әсәрнең композициясе дә үзенчәлекле төзелгән. Поэманың 48 шигъри юлдан торган кереш өлешендә дөньялыкның фанилыгы, тормышның мәгънәсе турында хөкем йөртелә: *И җиһан бақидур тигән қани / эшетиң дөнйа ишин билиң аны / чүн бу ғаләм ғақибәт йоқ болисәр / мундағылар һич бақи калмайсар / бу ишләр тиләр һуд бизгә йитәр / нә ким бардур мәһлуқат барча кетәр / көргил анларын ким әүәл кечтиләр / һәм йаман һәм йахшы барча кечтиләр / қани мунча миң нәби шаһлар / ол бина қылған улуғ дәрғаһлар / қани Адәм Нух ол Хәлил / бақи қалмас ғақибәт иллә җәлил / қани Сафуан қани Җәмшид чәһәрйар / қани Хөсрәү, Ширин, Зөлқәрнәин, ғәд / қани Дәқйәнус шидад ләғин / қани Нәмруд, Фәридун гөзин / қани ол Рөстәм Әсфәндүйар / йахуд ол қани Нәүширwан шәһрийар / қани ол Мәхмүд шахи Ғазнави / ким турды сурәтдә дөрест мәгни / қани ол Ибраһим ол кәбир / ким қойды қулға өздин солтан игү / қани Чынгыс қани һәлақ бу қамуғ / һәрберси бу җиһанны тутдылар / иллә ишит ким суңында киттиләр* (39: 1–26 )[1]. Автор күп шәхесләрне күздән кичереп, дөньяда яшәгән теләсә кемнең, җир йөзендә нинди генә тормыш алып барса да туфрак булачагы турында хөкем йөртә. Шагыйрьнең бу мәсьәләгә мөнәсәбәте риторик сорау аша белдерелә, шуңа күрә текстта *кани* сорау алмашлыгы, сорау интонациясе урын ала.

Хисам Кятиб керештә әйтелгән әлеге мәсьәләне әсәрнең төп өлешендә, легендага нигезләнеп, коры сөяккә калган башны Тәңре ярдәме белән телгә китереп яктырта. Гайсә пәйгамбәр Шамнан икенче бер илгә барганда юл буендагы таш өстендә бер баш сөяге күрә, баш иясенең дөньялыкта кем булуын белергә теләп, Тәңрегә ялвара, баш, телгә килеп, үзенең кемлеген сөйләп бирә. Җөмҗөмә иксез-чиксез дәүләт биләгән, гадел хөкемдар булган, әмма хәерчегә бер тапкыр ярдәм кулы сузмаганга, ул авыруга дучар ителә, яман шештән газапланып үлә, дөньядан имансыз киткәнлектән, дүрт мең елга тәмуг газапларына дучар ителә. Бөтендөнья әдәбиятына таныш сюжетны Хисам Кятиб ислам диненең кодрәтен күрсәтү юнәлешендә файдалана. Әсәрдәге вакыйгалар агышы Гайсә пәйгамбәр белән Җөмҗөмә арасында барган әңгәмә рәвешендә оештырылып, кешеләрнең үлгәннән соңгы

[1] Тексттан алынган үрнәкләрнең бит һәм юл саны.

тормышын сурәтләүгә багышлана. Хисам Кятибнең герое Җөмҗөмә солтан кяфер булуына карамастан гафу ителә, Гайсә пәйгамбәр үтенече буенча Тәңре аны яңадан терелтә, хак мөселман булып, җитмеш ел буе гыйбадәт кыла: *Кұр Хақ аңа ни ғинайәт әйләди/ ғақибәт мәэмин улуб чықты җаны* [Курбатов, 1984, б. 7].

Әсәрнең мавыктыргычлыгы аның сюжетында гына түгел, язучы кулланган стиль алымнарында да. Хисам Кятиб – талант иясе, язучының тәэсир көче әсәрдәге күренешләрне сурәтләгән һәр сүзендә бөркелеп тора. Х. Курбатов күрсәтүенчә, әсәр ритмик яктан да саллы яңгырый, ул рәмәле мөсәддәсе мәхзуф вәзененә салынган. Шагыйрь сүзгә саран, тасвирда хәрәкәт өстенлек итә, композициядә нинди дә булса катлауландыру юк, ләкин бер үк вакытта ул шундый итеп төзелгән: укучының игътибарын автор әледән-әле яңартып (контекстны көчәйтү юлы белән), бер үзәккә туплап тора [Курбатов, 1984, б. 62]. Хисам Кятиб поэмасы үзенең идея-проблематикасы, төзелеше, бу һәм теге дөнья күренешләрен үзара үреп тасвирлавы белән, – ди Х.Й. Миңнегулов, – Данте Алигьериның (1265–1321) атаклы «Илаһи комедия»сенә дә билгеле дәрәҗәдә аваздаш. Иҗтимагый явызлыкка каршы вөҗдан тойгысын үстерү ярдәмендә көрәш аларның һәр икесенең дә үзәгендә тора [Миңнегулов, 2014, б. 298].

«Җөмҗөмә солтан» дастанындагы вакыйгаларга урын һәм вакыт ягыннан киң колачлылык хас, алар реаль һәм хыялый күренешләр, фәлсәфи уйланулар, лирик чигенешләр белән үрелеп бара. Хисам Кятибнең тормыш мәгънәсе, кеше гомеренең кыскалыгы, яшәү һәм үлем хакындагы фәлсәфи уйланулары шигъри чаралар – риторик сорау, метафора, гипербола, чагыштырулар ярдәмендә сурәтләнә.

Поэтик текстта Хисам Кятиб, башлыча, сүзләрне туры мәгънәдә куллана, ягъни автологик алым белән эш итә, шулай ук метологик алым да үз урынын алган, тик кулланылыш дирәсе киң түгел.

Сүзләрне туры мәгънәдә кулланып, поэтик текст барлыкка китерү шагыйрьдән зур осталык таләп итә. Бу турыда Х. Курбатовның фикере игътибарга лаек: «Монда тасвир объекты үзе күчерелмә мәгънәдә, мондый гайре табигый хәлне сөйләп бирү өчен авторга күчерелмә мәгънәдәге сүзнең әллә ни кирәге дә юк» [Курбатов, 1984, б. 66].

Хисам Кятиб контекстта җөмләләрне синтаксик яктан да, мәгънәви яктан да бер-берсенә тыгыз бәйләп, синтаксик бөтеннәрнең экспрессив һәм логик мәгънә бирүенә ирешә. Мәсәлән, текстта Гайсә пәйгамбәрнең сәяхәтен, табигать күренешен тасвирлаган җөмләләр фикернең башлануына ишарә итсә, аның үстерелеше, билгеле бер экспрессив төсмер алуы кеше башы күренеше белән бәйле: *Ғайсә пәйғамбәр бир күн мөсафирлық қыла / гизди шам илиндин бир илә / көрди бу сахраны хош мәрғәзәр / сулар ақа құшлар учар зар зар / баруп ол су йақасында отруп /wозу қылур ирди ол йирдә эчрүп / көрәр ол сахрада бир сахра ташы / йәнә ол таш үзрә адәм башы / нә көзи қалмыш нә ағзы нә гәүдәси / әйди алла көрүпдүр нәчә баш / ғибрәт алып хәйран эчрә қалды аңа / көрмәдим мән йир йүзиндә мунча баш / бақты йаз-*

*мыш элиндә ики хат / сән и баш мунча йүрүп мунча йат / йәнә сәндин мунча ишләр кичисәр / суңра җан куш сәндин учисар / ғайсә пәйғамбәр хәйран ичиндә калып /андин суң тәңри фәрмани билә / тили тиши йок икән кәлди тилә* (40: 25, 26; 41: 1–15; 42: 13, 14).

Хисам Кятиб кеше идеалын гадел хөкемдар сурәте нигезендә эзли. Гайсә пәйгамбәр очраткан баш та гадел хөкемдар булган. Аның игелекле гамәлләре хикәяләү рәвешендә, үткән заман хикәя фигыль формалары кулланылып, I зат исеменнән бәян ителә: *кем кәлүр әйди һәмиш қайу әсир / болса мискин йа ғәриб йә фәқир / көндә миң келсә иди дәрвиш йәтим / алмайыны кетмәз ирди тон атым/ андин өзгә бәхеш ихсан үкүш / қылур ирдим дәрдигәр дәрман күкүш / кечә күндүз ғадел дад ирдим ишим* (45: 3–9).

Газраилне, Мөхәммәд пәйгамбәрне сурәтләгәндә, Х. Кятиб, җөмләләрдә төп билгеләрен саный барып, мәгънәви бәйләнеш тудыра, синтаксик бөтен эчендә аларның поэтик образын күз алдына китерүгә ирешә*:* а) кешеләр җанын алучы Газраилнең сурәте: *чықты бир сурәт ким алты йүзи бар / қан қуйулмыш тасға биңзәр көзи бар / мәшриқ мәгриб тутмыш ики қанаты / ол ғазраил ирмиш уған койған аты / бири астун бири үстүн һәрбири / сағ сул артқары һәм илгәри / бир илиндин чанғул бир илиндә кәдәх / көрмәз ирмеш ичкән ғөмриндә фәрәх* (48: 19–24; 49: 1, 2); ә) Мөхәммәд пәйгамбәрнең үзенчәлекләре: *ол йаратқанның хәбиби мостафа / ким қамуғ җанлар табар андин сафа / ол нөбүвәт мәгдәнитиң гәүһәри / һәм кәрәмәт һәм wилайәт сәрwәри / ол ким ушбу онсигиз миң ғаләмиң / сәрвәридур җөмлә ғаси адәмиң / дөнйада һәм ахирәтдә шаһ ирүр / зирәким хәбибуллаһ ирүр / әнбийәләр хатими ол болысар* (49: 13–21).

Текстта сорау һәм җавап репликасына шактый еш мөрәҗәгать ителгән. Үзенчәлекле яңгыраш кабатлаулар исәбенә дә барлыкка килә. Аларда авторның чынбарлыктагы вакыйгаларга мәгънәви мөнәсәбәте белдерелә, эмоциональ кичерешләре бирелә. «Кем идең» дигән дәшү аша килеп, язучы Җөмҗөмәнең башыннан кичкәннәрен үзеннән сөйләтә: *Ғайсәгә билдүрди ол кәнд өзүни / Ғайсә сурды йәнә ол башдин сөал / ким йәнә сөзләгил сахибҗәлал / җан нә түрлүк бердиң аны сөзләгил / гүрдә нә көрдүң аны хикәйәт әйләгил / һичкимирсә кәлип сурдыму сәни / урдыму ухшадыму йахуд сәни / нә сифатлықдур уҗмах йахуд тәмуғ / көрдүң ирсә сөзләгил аны камуғ / ахырың нә болды аны шәрх қыл / ... бу сөзни сурғач ол аһ тиди / андин әйди, Ғайсә рухуллаһ тиди / қылдуңыз йаулақ ғазим ағыр сөал / қани бу сөзни әймәкгә мәңа хәл / иллә сурдуң миң дә бирин дим йәйим* (45: 20–24; 46: 1–4, 9–12). Башның хикәяте тоташ монолог түгел, автор аны диалог формасында оештырган, ул сорау–җавап берлегеннән гыйбарәт. Җөмлә төзүдә төп чара булган әйтеп бетермәү, сораулар биреп бүлдерү, дәвам иттерү алымын куллану язучыга Җөмҗөмәнең язмышын җанлы да, тасвирлы да, гыйбрәтле дә итеп сурәтләүгә мөмкинлек ача. Әсәрдәге вакыйгаларның урыны: герой үзе яшәгән мохит, тәмуг күренешләре һәм шуңа бәйле заман төсмерләре үзгәреп

тора. Җөмҗөмә теге дөньяда дүрт мең ел тәмуг газабы кичерә. Өстен катлау кешеләренең үлгәннән соң кичергән тәмуг газаплары, моның сәбәбе булган дөньялыкта кылган яман эшләре ислам дине күзлегеннән чагылдырыла. Язучы тәмугның үзенә генә хас сыйфатларга ия булган җиде төрен, аларда газаплanучыларның сурәтләрен – маймыл йөзле, нәфесләрен тыя алмаган, корсаклары тау кадәрле дуңгыз кыяфәтенә кергән кешеләрне тасвирлап, инсаннарны тәмуг газабы белән куркытып, аларны яман эшләрдән чикләргә тели. Тәмугның берсеннән-берсе куркынычрак җиде дәрәҗәсе, һәр дәрәҗәдә каралган җәзалар поэмада хикәяләү рәвешендә исем сүз төркеменең төрле функцияләре ярдәмендә бирелгән: *йити түрлүкдүр қат-қат тәмуғ / тикмә бириниң биридин қатығрақ /* ***Һawиә*** *әүwәл тәмуғ атыдур / ким аның ғазабы оты қатыдур /* ***Хатамә*** *икинчиси атыдур / барча насраниларның кесмәтидүр / йәнә икинчиниң атыдур* ***Сәкар*** */ ол ағзын ачып җүһүдләргә бақар / йәнә төртинчисиниң атыдур* ***Сағир*** */ анда йалған сөзләгүчиләр һәм кирүр / ол бәшинчисиниң атыдур* ***Ләза*** */ ким мәҗүсиләр башығадур қаза / андин алтынчысының* ***Җахимдүр*** *аты / андин йитинчисиниң атыдур* ***Җәһәнәм*** */ ошбу тәмуғ ким йитиниң биридүр /ол Мөхәмәд өммәтиниң йиридүр* (53: 9–24; 54: 1–3, 7, 8).

Шигырь юлларының бертөсле, анафорадан башланып китүе уй-фикерне көчәйтүдә куәтле стилистик алым булып тора. Хисам Кятиб, сөйләмне эмоциональ югарылыкта бирү өчен, поэмада кабатлауны бик еш куллана, аларның яңадан-яңа төрләрен таба, Аһәңне көчәйтеп җибәреп, ритмик төгәллеккә ирешүдә сорау алмашлыкларын, саннарны, исем, фигыль сүз төркемнәрен сайлый. Хисам Кятиб кереш өлештә сүз башында *кани* алмашлыгын кабатлап, үзенчәлекле мәгънәви градация барлыкка китерә. Мисаллар: ***қани*** *Сафуан* ***қани*** *Чәһәрйар/****қани*** *Хөсрәү Ширин Зөлқарнәйин ғад /* ***қани*** *Дақйанус Шидад ләғин/* ***қани*** *Нәмруд Фәридун гөзин/ йахуд ол* ***қани*** *Нәүширwан шәһрийар/* ***қани*** *ол Мәхмүд шахи Ғазнаwи/* ***қани*** *ол Ибраһим ол кәбир* (39: 13–21)*;* ***кими*** *солтан* ***кими*** *қул* ***кими*** *әмир/* ***кими*** *хуҗа* ***кими*** *бай* ***кими*** *фәқир* (40: 16–17)*;* ***йәнә он миң*** *сақи қулум бар иди/* ***йәнә он миң*** *хазир башмақдар иди/* ***он миң*** *ирди җефтем ай күндин ари/* ***йәнә он миң*** *қырнақым һәм бар иди* (43: 19, 20, 21, 23); ***нә*** *иңиндә тун бар* ***нә*** *башында сач* (57: 16)*;* ***йүрүр ирмеш*** *анлар ким халқ ара /* ***йүрүр ирмеш*** *һәрбири мән мән тиүп* (54: 19–20) һ.б.

Шигъри текстта язучы ритм һәм аһәң тудыруда анафораны гаҗәеп оста файдалана. Җөмҗөмә солтан үзенең уенчы музыкантлары хакында сөйләгәндә, *мең* сүзен сүз башында бер ритмик позициядә кабатлап, Хисам Кятиб, хәтта, уен кораллары оркестрының музыкаль яңгырашын укучысына җиткерүгә ирешкән: *һәр йити* ***миң*** *мотрибчыларым бар иди /* ***миң*** *чаң* ***миңи*** *кубучылар иди /* ***миңи*** *натманлар ирди* ***миңи*** *бурғу /* ***миңи*** *табл урар ирди* ***миңи*** *арғу /* ***миңи*** *чалғу чалар ирди* ***миңи*** *дәф / миңи чибмал урар ирди миңи кәф* (44: 5–10).

Әдип җөмләне тәмамлаучы хәбәрне кабатларга ярата. Мондый төр кабатлаулар раслау мәгънәсен алып килә: *көргил анларин ким әүәл* ***кечтиләр*** */ һәм йаман һәм йахшы барча* ***кечтиләр*** (39: 7, 8); *чүнки кәлдүң дөнйайа кетмәк* ***керәк*** */ бар көчин йиткүнчә хәйр итмәк* ***керәк*** (40: 6, 7), *йәнә көрмүш бир қаwем* ***тили йоқ*** */ һәм тақи һәм бир қаwем аҙақ* ***или йоқ*** (55: 7–8) һ.б. Әсәрдә омонимиягә нигезләнгән кабатлаулардан да киң файдалана:

*миңи ат, миңи тәүә, миңи сығыр, миңи* ***қуй***
*өзгә ниғмәт куш куртны әйтмә* ***қуй*** (45: 13–14);
*әсрү йаwуз хәлдә йатдум ол* ***кечә***
*ол билүр ким өз башиндин иш* ***кечә*** (47: 23–24).

Хисам Кятиб мәгънә ягыннан якын торган сүзләрне бер-бер артлы биреп, фикер яңгырашын көчәйтү өчен, градация алымын еш кулланган: *бу кара йир ким көрәрсәң туп тулуғ / адәм уғланларыдур кичик улуғ / һәр қадәм йир үстүнә басарсән / һәр адымда адәм йүзинә басарсән / бу қара туфрақ ичрә нәчәләр / йатурлар түнү күндүз кечәләр / кими солтан кими қул кими әмир / кими хоҗа кими бай кими фәқир /... әмир мискин қул солтан билгүсиз / улуғ кичик бай йуқсул билгүсиз* (40: 8–17, 21–23).

Язучының сурәтләү стилендә гипербола, метафора, метонимия, чагыштыру кебек синтаксик троплар үз урынын алган.

Шагыйрь Җөмҗөмә солтанның кем булганлыгын үзеннән сөйләтә. Е. Бертельс фикеренчә, шул рәвешле Хисам Кятиб ачыктан-ачык Алтын Урда ханнарының тормышын сурәтли. Бу турыда Х. Миңнегулов фикере әһәмиятле: «Әлбәттә, бу рәвештә үк кистереп әйтү бераз бәхәс уята. Шулай да галимнең әсәрдәге күренешләр белән Дәште Кыпчак мәмләкәте арасында охшашлыклар, бәйләнеш күрүе нигезле. Ибне Батута, Ибне Гарәбшаһ һәм күп кенә башка авторлар Алтын Урда шәһәр тормышының алга китүе, мәдәниятнең үсеше, хан сарайларында затлы мәҗлесләр уздыру турында язалар. «Җөмҗөмә солтан»да да без гайре гиперболик планда булса да, шуларга охшаш күренешләр белән очрашабыз» [Миңнегулов, 2014, б. 298]. Әлбәттә, шагыйрь гипербола белән эш итә, күренешләрнең мәһабәтлеген күрсәтү өчен, ул сан күләменә күчерелгән көчәйтүләрдән файдалана, башкаласының буе биш көнлек, иңе өч көнлек юл, вәзирләренең саны 40 мең, 18 мең бәкләр, һәртөрле хезмәтчеләре дә 10 мең булган: *кырық миң вәзирим бар иди* (43: 11); *онсикиз миң мәгтәбәр бикләр камуғ* (43: 13); *он миң ирди җефтем ай күндин ари* (43: 21); *йәнә он миң қырнақым һәм бар иди* (43: 23); *һәр йити миң мотрибчиларим бар иди* (44: 5); *тәмуғда миң түрлү ғазаб* (52: 23); *ир миң һөнәр үгрәнмәк көп дәгүл* (54: 21); *миң һөнәр болса бир ирдә көп дәгүл* (56: 9) һ.б.

Язучы чагыштыруларны күбрәк кешене сурәтләгәндә куллана. Үзенең һәм вәзирләренең көчен арыслан белән, хатыннарының гүзәллеген ай белән чагыштыра: *иллә һәйбәтдә мисл арыслан идим* (44: 18); *хөсн эчендә һәрбири бир маһ иди* (43: 24). Дөньялыкта гөнаһ

кылган адәмнәр тәмуг эчендә төрле ямьсез кыяфәтләрдә чагыштырулар аша белдерелә*: қан куйулмыс тасға биңзәр көзи бар* (48: 20); *бир қаwем көрдим бичин йүзлүк* (54: 14); *һәрбириниң қарны болмыш тағ киби* (54: 24); Билгеле бер ситуацияне каршы куеп тасвирлаганда чагыштыруларга нигезләнә: *бир улуғ сахра болмыш бу җиһан* (48: 18); *ким болуп солтан болғунча бу хақ ир* (59: 4) һ.б.

Метонимия әсәр телендә чагыштырмача аз күзәтелә: *һәр адымда **адәм йүзинә** басарсән* (40: 11) – ягъни туфракка әйләнгән кеше битенә; *ким **камуғ җанлар** табар андин сафа* (49: 14) – ягъни барлык кешеләр; *түштүм ол дәм йиргә **көзем қарайыб*** (47: 17) – ягъни үлдем һ.б. Шигъри юлларда язучы өчен әһәмиятле булган мәгънә көчәйтелешендә поэтик метонимия сизелеп тора.

Әсәрнең төзек, аһәңле булуы синонимнар кулланылу белән дә аңлатыла. Поэмада бер үк төшенчәне белдереп, мәгънә ягыннан бер-берсенә якын сүзләр теркәлгән. Төрле сүз төркеменә караган синонимнарны язучы шактый иркен кулланган. Исем сүз төркеменнән кеше һәм җәмгыять тематикасына кергән синоним сүзләр әсәрдә шактый еш очрый. Аллаһның күркәм исемнәреннән поэмада сигезе чагылыш таба, абсолют синонимнар тәшкил итә. Шунысы игътибарга лаек: Хисам Кятиб гарәпчә атамаларыннан Аллаһның хаклык сыйфатына ия булуын күрсәткән *Хак* исемен 7 тапкыр, *Сәмиг* – «ишетүче», *Мүҗиб* – «дога, үтенечләрне кабул итүче», *Хәким* – «бөтен нәрсәләрне хикмәтле башкаручы» мәгънәле исемнәрен берәр тапкыр кабатланган. Аллаһның төрки чыгышлы дүрт синонимы табылды: *Тәңре, Уган, Изге, Яраткан*. *Тәңре* атамасы әсәрдә кулланылыш ягыннан шулай ук өстенлек алган, 7 тапкыр теркәлгән. Мисаллар: ***Хақға** сығнып нәчә ким қылсаң ғәмәл* (57: 5); *алдылар **Хақ** йиринә тикүрдиләр* (50: 10); *йә **Сәмиғ** йә **Мүҗиб** йә **Хәким*** (60: 24); *андин суңу **Тәңри** фәрмани билә* (42: 13), *аңла ким **Тәңри** сәңа бирди түз* (52: 20), ***Тәңри** мәни ғафу қылғай и әхи* (60: 22); *инанмадуқ Илйасның **Тәңрисинә*** (60: 13); *ол Ғазраил ирмеш **Уған** қойған аты* (48: 22); *кечә күндүз **Иҙиниң** зикерин қыл* (62: 6) *ол **Йаратқанның** хәбиби мостафа* (49: 13) һ.б.

*Адәм ~ кеше* сүзләре әсәр телендә җан иясе, шәхес мәгънәсендә синонимнар буларак кулланыла. *Кеше* – татар теленең үз сүзе, *адәм* – гарәп теленнән кергән, мәгънә төсмерләре аерылмый: ***адәм** угланларыдур кичик улуғ* (40: 9); *ол таш үзрә **адәм** башы* (41: 6); *қани **адәм** Нух ол хәлил* (39: 11); *Җөмҗөмә чүн ол кәдәх **киши** көтәрдиләр* (50: 7); *табмас ирмеш **киши** дөнйадин морад* (62: 3); *һәрбирингә төзмәс иди миң **киши*** (44: 14) һ.б.

Мал, байлык мәгънәләрен белдерү өчен, *мал, мөлкәт, милек* лексемалары синоним буларак кулланылган: *өзгә **малның** саны худ йоқ иди* (44: 15); *қани тун атым йахуд **мал мөлкәтем*** (50: 18); *мунча түрлүк **мал** ниғмәт қойып* (40: 4); *фариғ ким әһл **милек мөлкәтимдим*** (48: 16) һ.б.

Гарәп, фарсы алынмалары *мәлик ~ солтан ~ әмир ~ шаһ ~ падишаһ* текстта синонимик оя хасил итә, *солтан* лексемасы – мөселман

дәүләтләрендә идарә итүче патша мәгънәсендә синонимнар арасында иң еш кулланылганы. Мисаллар: *Җөмҗөмә* ***солтан*** *иди атым бәним* (42: 21); *аты данлу өзи хас* ***солтан*** *иди* (62: 9); ***әмир,*** *мискин қул,* ***солтан*** *билгүсиз* (40: 22); *һәрбири бир* ***падишаһның*** *дөхтәри* (43: 22); *дөнйада һәм ахирәтдә* ***шаһ*** *ирүр* (49: 19); *қани мунча миң нәби* ***шаһлар*** (39: 9); *дөнйада мән бир* ***мәлик*** *ирдүм улуғ* (42: 19); *һәрбиримиз бир* ***мәлик*** *ирдүк бурун* (58: 23); *кими* ***солтан*** *кими қул кими* ***әмир*** (40: 16) һ.б.

Галәмнең бер өлешен, Җир йөзен белдергән *дөнья, җиһан* сүзләре әсәрдә синонимнар, кулланылышы ягыннан *җиһан* сүзе өстенлек итә. Мисаллар: *эшетиң дөнья ишин билиң аны* (39: 2); *сурдым дөнйа ичрә кимләр ирдүңиз* (58: 21); *и җиһан тигән қани бақидур* (39: 1); *ким нәләр кәлди җиһан эчрә мәңа* (42: 18) һ.б.

Предметның билгесен белдереп килә торган сыйфат сүз төркемен язучы чикле кулланган. Текстта синонимик оя тәшкил иткән *дәрwиш ~ мискин ~ ғәриб ~ фәқир ~ гидай*; *сәхи ~ кәрим* сыйфатлары гына очрады. Мисаллар: *көндә миң келсә иди* ***дәрwиш*** *йәтим* (45: 5); *барып* ***мискингә*** *қаты сөзләмиш* (47: 6); *алмамыш алар бир* ***мискин*** *көңлини* (58: 3); *кәшки болғай ирдүк дөнйада* ***фәқир*** (59: 3); *һәм бақар ирди* ***фәқир*** *илә* ***гидайны*** (60: 1); *ир әдәр болса сәхәwәт һәм кәрим* (56: 11) һ.б.

Хисам Кятиб синонимнарны куллануга җитди якын килгән. Кабатлаудан котылу өчен генә түгел, әдәби тел традициясенә нигезләнеп, бер үк билгене, төшенчәне белдерә торган төрки, гарәп, фарсы сүзләре ярдәмендә әсәрендә югары стиль кагыйдәләрен саклаган булырга тиеш.

Әсәр телендә сүзләр мәгънә бәйләнешләре белән генә түгел, мәгънә каршылыклары буенча үзара бәйләнештә яши. Язучы тасвирлауның көчен арттыру өчен, бер күренешне икенчесенә каршы куеп сурәтләү алымыннан файдалана. Антонимлык предметларны белдергәндә: ***дөнйада*** *һәм* ***ахирәтдә*** *шаһ ирүр* (49: 19); *нә сифатлықдур* ***уҗмах*** *йахуд* ***тәмуғ*** (46: 3); *тиң тутар иди* ***йарлыны*** *һәм* ***байны*** (60: 2); әйберләрнең сыйфатын: ***изгә*** *бирлә* ***йаwузны*** *қылғанымыз* (61: 24); *йә* ***ғәзизму*** *ирдүң йә* ***бәдбәхет*** *зәлил* (42: 12); *һәм* ***йаман*** *һәм* ***йахшы*** *барча кечтиләр* (39: 8); *әмир* ***мискин қул солтан*** *билгүсиз* (40: 22); *ики сурәт бири* ***көк*** *вә бири* ***кара*** (51: 10); вакытын: ***кечә күндүз*** *ғадел дад ирдим ишим* (45: 9); *йатурлар* ***түнү күндүз кечәләр*** (40: 15); урын аралыгын: ***ташрадин*** *көрәнләр* ***һәйбәт*** *дир иди* / ***эченә*** *киргүчиләр* ***җәннәт*** *дир иди* (43: 8); ***сағ сул артқары*** *һәм* ***илгәри*** (48: 24); үтәлешен: *чүнки* ***кәлдүң*** *дөнйа* ***кетмәк*** *керәк* (40: 6); *суңра көп* ***истәдим*** *аны* ***табмадым*** (47: 10) ***кетди*** *анлар* ***кәлди*** *аңа гүир йара* (51: 9); *йокса* ***кой*** *бәна сөзин* ***тәрк қыл*** (46: 6) һ.б. белдергән очракларда бирелгән.

Хисам Кятиб кайбер өзекләрен тулысынча шушы алымга кора:

> ***ирму*** *ирдүң дөнйада йә сән* ***тиши***
> ***хуҗаму*** *ирдүң* ***қулму*** *ирдүң айғыл сән*

***бикмү** ирдүң йуқса **йуқсу фәқир***
*йә **шәйхмү** ирдүң сән йахуд **бөхил***
*йә **гәзизмү** ирдүң йә **бәдбәхет** зәлил* (42: 8–12).

Поэмада Хисам Кятиб Урта гасыр язма истәлекләрендә урын алган халык иҗатына хас калыплашкан тезмәләрдән, үз чорының җанлы сөйләм теленнән, фразеологик хәзинәсеннән, мәкаль-әйтемнәрдән иркен файдалана. *Тыңла сөзүм, ишитиң, андин әйди, көрдүм андин, бир күн* һ.б. сүзләр һәм әйтелмәләр укучыны яңа хәбәр кабул итәргә әзерли. Мисаллар: тыңла: *тыңла имди бу сөзимгә бир мәсәл* (40: 23); *андин әйди йа Гайсә тыңла сөзүм* (50: 13); *тыңла имди хәлим әйдәм сәңа* (42: 17); *тыңлагыл ким әйтәйим* (53: 6); *тыңлагыл сән көрдүким шәрх идәйим* (46: 18) һ.б.; әйди: *андин әйди, йа Гайсә тыңла сөзүм* (50: 13); *Гайсә әйди бурун ушбу сөзи* (61: 8); *йәнә Гайсә әйди әйт и баш бизә* (60: 9); *әйдиләр солтан ирдүк һәрбиримиз* (58: 22); *нәчүк алты йүзиң бар әйт мәңа (49: 4); әйдим и җөмҗөмә нә қылдуң қани* (51: 14); *әйдим ким анчақ болур ичмәк йитәр* (52: 10) һ.б.; ишит: *ишитиң дөнйа ишин билиң аны* (39: 2); *ишит андин дәхи нәләрүм бар иди* (43: 2); *йә нәбиулла, ишитгил бу сөзим* (54: 11) һ.б.; көр: *көргил анларын ким әүәл кечтиләр* (39: 7); *көр нәчүк болды ахыры мунлар ишин* (56: 8) һ.б.; бир көн: *Гайсә пәйгабәр бир күн мосафирлық қыла* (40: 25); *олтурур ирдүм бир күн тәхтиндә хош* (46: 15) һ.б.

Материаллардан күренгәнчә, әсәр телендә файдаланылган фразеологизмнар, татар теленең сүз хәзинәсе буларак, телебездә йөри. Әдип иҗатында хис-кичерешләрне белдергән *җан, күңел, йөрәк* сүзләре белән бәйле әйтелмәләр зур урын тота. Мисаллар: ***җан кирди** қайра әсән болды тәни* (61: 4); *ачсам мәгриб халаиқны **җан берүр*** (49: 10); ***җан** нә түрлүк **бердиң** аны сөзләгил* (45: 23); *суңра **җан** қуш сәндин **учысар*** (41: 14); *тутмадылар бир сәгәт **чықты җан*** (50: 12); *һәр йүзем ачып анлардин **җан алысар*** (49: 24); *кити ол мискинниң **көңли йықылды*** (47: 7); ***алмамыш** алар бир **мискин көңлини*** (58: 3); *нә туз икмәк **көңлини билмәмиш** (57: 10); **көңүл йықылды** айруқ қылу* (47: 8); *калды рауан ол **көңүлин баймадым** (47: 9), **йүрәким көйди ичим қайнады*** (52: 8) һ.б. *Көрдим ирсә **титрәмәк тутты** мәни* (51: 13); *йәнә төрт миң тәмугда **чикдим газаб*** (60: 6); *хөснүмә **көз салган** адәм җаны* (44: 21) һ.б. хис-кичерешләрне чагылдыру өчен файдаланылган фразеологик әйтелмәләр кайбер фонетик үзгәрешләр белән хәзерге татар телендә актив кулланыла.

Хисам Кятиб, фәлсәфи фикерен образлырак, тәэсирлерәк итү максатыннан, мәкальләргә дә мөрәҗәгать иткән. Кеше яшәешенең төп мәгънәсен – үзеннән соң изге эш, исем калдыру хакындагы фикерен мәкальләр ярдәмендә әйтеп биргән. Мисаллар: *ким **қалур ирмиш җиһанда иҙгү ат*** (62: 4); *һәрким ирсә **нә иксә ургай аны*** (61: 22); ***қылдың ирсә уш җәзасы көргил*** (51: 8); *бар **көчин йиткүнчә хәйр итмәк кирәк*** (40: 7); ***тәңри биргән ризықың шөкрин қыл*** (62: 5) һ.б. Язучы файдаланган мәкальләр хәзер дә әдәби әсәрләрдә һәм халык сөйләм телендә актив кулланылалар.

Хисам Кятиб сәнгатьчә алымнарның төрлесеннән файдаланып, татар әдәби теленең сәнгатьчә үсешендә мөһим урын токкан әсәр калдырган. «Җөмҗөмә солтан» үзен барлыкка китергән мохит чикләрендә яшәп, Алтын Урда дәүләтенең мәдәният казанышына әверелеп, үз сурәтләре белән алдагы буын әдәби хәрәкәтенә килеп кушылган.

**Әдәбият**


*Алмаз Җ.* Җөм-җөмә дастаны // Әдәби мирас (Өченче китап). Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 42–57.

*Курбатов Х.Р.* Иске татар поэзиясендә тел, стиль, метрика һәм строфика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 164 б.

*Миңнегулов Х.Й.* Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» әсәре // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Б. 292–300.

*Нуриева Ф.Ш.* Атрибуция языка письменных памятников золотоордынского периода. Астана: Изд-во Сарыарка, 2011. 208 с.

Татар әдәби теле тарихы. (XIII гасыр – XX йөз башы) / И.Б. Бәширова, Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Кадыйрова. I том: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. Казан: ТӘһСИ, 2015. 696 б.

Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы) / И.Б. Бәширова, Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Кадыйрова, Р.Ф. Мирхәев. II т.: Морфология. Грамматик категорияләрнең структур-субстанциональ үзенчәлеге һәм функциональ-стилистик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. Казан: ТӘһСИ, 2017. 888 б.

Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы) / И.Б. Бәширова, Г.Ф. Гайнуллина, Х.Х. Кузьмина. III том: Лексика. Лексик-семантик категорияләрнең инвариант парадигма үзенчәлеге һәм контекстуаль-синтагматик мөмкинлеге: язма традиция, норма һәм вариантлылык. Казан: ТӘһСИ, 2019. 642 б.

Татар әдәбияты тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Т. 1. 567 б.

Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 214 б.

*Aysu Ata.* Harezm-Altın Ordu Türkçesi. Ankara: Ankara Universitesi Basımevi, 2014. 186 p.



***Нуриева Фәнүзә Шәкүр кызы,***

*филология фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университетның татар тел белеме кафедрасы профессоры,*

*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 81-112

***Х.Х. Кузьмина***

# КОЛ ГАЛИНЕҢ «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» ПОЭМАСЫНДА МЕТАФОРАЛАР КУЛЛАНЫШЫ

Стиль художественной поэтической литературы отличается эмоциональностью и широким употреблением языковых средств выразительности. Здесь особую роль играют слова переносного значения, издавна употребляемые поэтами для достижения более яркого описания предметов, событий, явлений и для более эмоционального восприятия их читателями. Особенностью художественного стиля поэмы «Кысса-и Йусуф» Кул Гали является широкое употребление образных средств, построенных на антитезе. Метафоры, выбранные автором, зачастую имеют двоякую интерпретацию: через них автор передает как положительные значения предметов, явлений и процессов, так и скрытые оттенки негативного, о которых читатель узнает в ходе повествования.

**Ключевые слова:** стилистика, стилистические категории, слова переносного значения, метафора, «Кысса-и Йусуф».

The style of artistic poetic literature is distinguished by emotionality and the wide use of linguistic means of expression. Here, a special role is played by words of figurative meaning, which have long been used by poets to achieve a more vivid description of objects, events, phenomena and for a more emotional perception of them by readers. A feature of the artistic style of the poem «Kyssa-i Yusuf» is the widespread use of figurative means built on antithesis. The metaphors chosen by the author often have a twofold interpretation: through them the author conveys both positive meanings of objects, phenomena and processes, and hidden shades of negative, which the reader learns about during the narration.

**Keywords:** stylistics, stylistic categories, figurative words, metaphor, «Kyssa-i Yusuf».

Тел белемендә «стилистика» термины берничә яссылыкта кулланыла: беренчедән, структур стилистикада, ягъни функциональ стильләрне өйрәнә торган өлкәдә; икенчедән, сөйләм стилистикасында, ягъни телнең иҗтимагый кулланышындагы сөйләм актларын һәм төрләрен тикшерә торган тармакта; өченчедән, матур әдәбият стилистикасы юнәлешендә [Виноградов, 1963, с. 5]. Әдәби әсәрнең телен өйрәнү – матур әдәбият стилистикасында иң катлаулы һәм авыр бурычларның берсе, чөнки бу очракта тел сөйләм сәнгате формасы, бербөтен сүз-сәнгать рәвеше буларак билгеләнә. Тел белемендә әдәби әсәрнең стилен өйрәнгәндә, аның барлык сәнгати формалары (мәсәлән, жанр, үлчәм һ.б.) өйрәнелми, ә бары үзенчәлекле сурәт барлыкка китерә торган сөйләм чаралары гына тикшерү предметы буларак билгеләнә. Алар язучы тарафыннан уңышлы сайлап алынган булса, әсәрдә образ (сурәт) тулы канлы тормыш белән яши башлый, һәм, киресенчә, уңышсыз

сайланылган тасвир чаралары образның да тоныклануына, югалуына китерә.

Әлеге мәкаләдә XIII гасыр язма истәлеге булган «Кыйссаи Йосыф» әсәрендәге стилистик берәмлекләрдән метафораларның кулланылыш үзенчәлеген ачыклау максаты куела.

Лингвистик стилистика – тел һәм сөйләм стильләре турындагы фән. Ул филологиянең бер тармагы булып тора һәм сөйләм стильләре, стилистик алымнар, җанлы тел чараларының җанлы эчтәлегенә мөнәсәбен өйрәнү белән шөгыльләнә. Ул тел һәм әдәбият фәннәренең уртак өлкәсе дип санала [Әдәбият белеме сүзлеге, 1990, б. 168].

Шигъри әдәби әсәрнең стиле эмоциональлек һәм сәнгати тел чараларының киң кулланылышы белән аерылып тора. Биредә күчерелмә мәгънәдәге сүзләр аеруча зур роль уйный, чөнки предмет, күренеш һәм вакыйгаларны сурәтле итеп, укучы әсәрне укудан ләззәт алырлык итеп тасвирлау өчен, туры мәгънәдәге сүзләр генә җитми, автор һәрвакыт сүзнең яңа мәгънәсенә, яңа бизәгенә омтыла. Күчерелмә мәгънәдәге сүзләр – алар әдәби әсәрнең тел бизәге.

Сүзләрнең күчерелмә мәгънәсе барлыкка килүнең берничә төре билгеле. Хәзерге вакытта стилистика фәнендә күчерелмә мәгънәлелекне билгеләүгә карата төрле карашлар яши, әмма аларны, нигездә, төп өч төргә берләштерергә мөмкин:

1. Охшашлык нигезендә мәгънә күчерү (мәсәлән, *шикәр комы* дигәндә, мәгънә күчерү форма буенча охшашлык нигезендә башкарыла). Бу алым нигезендә, гадәттә, *метафора* барлыкка килә, үз чиратында, ул, образлылык дәрәҗәсе буенча, берничә төргә бүленә.

2. Чиктәшлек буенча күчерү: *өч стакан эчтем* (стакан атамасы стаканда урнашкан эчемлеккә күчә). Әлеге алым *метонимия* барлыкка килүгә нигез булып тора.

3. Объектның бөтенлеген бер өлешкә күчерү һәм, киресенчә, өлештән бөтенгә күчерү: *акыллы баш* (кешенең тән өлеше турында түгел, ә кеше турында әйтелә). Бу алым *синекдоха* ясауга хезмәт итә.

Татар лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы бай фәнни мираска һәм традицияләргә ия. Күренекле галимнәр Х.Р. Курбатов, В.Х. Хаков, С.Ш. Поварисов, И.Б. Бәширова әлеге юнәлештә зур хезмәт куялар.

Туры мәгънәдәге сүзләр ярдәмендә дә сурәт барлыкка килә алу мөмкинлеген истә тотып, стилистикада автологик һәм металогик алымнар турында өйрәтмә барлыкка килгән. «Поэзиядә тасвир һәрвакытта да күчерелмә мәгънәдәге сүзләр – троплар (металогик алым) белән генә бирелми, бәлки тасвир субъекты (лирик персонаж) яки объекты (күренеш, вакыйга, башка бер персонаж) үзе генә дә күңелгә үтеп керерлек икән, ул туры мәгънәдәге сүзләр белән дә башкарыла (автологик алым)», – дип күрсәтә Х.Р. Курбатов [Курбатов, 2002, б. 137]. Сүзнең күчерелмә мәгънәсен Х.Р. Курбатов *чагыштыру,*

*метафора, эпитет, метонимия, перифраз, оксюморон, гипербола* һәм *литота, ирония* төрләренә аерып карый.

«Сүз белән сурәт ясау» монографиясендә И. Бәширова тел һәм сөйләм дихотомиясе проблемаларына теоретик яктан тирән якын килә. Ә гамәли яктан фәнни әйләнешкә, поэтик әсәр микроберәмлеге буларак, *сүз-сурәт* термины кертелә. Биредә сүзнең телдә һәм матур сөйләмдәге мәгънәсе күрсәтелә [Бәширова, 1974, б. 176]. В.Х. Хаков һәм С.Ш. Поварисов хезмәтләрендә дә күчерелмә мәгънә төрләре турында җентекле нәзари һәм гамәли мәгълүмат бирелә [Хаков, 1999; Поварисов, 2011].

Шул рәвешле, татар тел белемендә стилистик категорияләрнең өйрәнелеше шактый күптәннән башланган һәм фәнни мәктәп булдырылган. Бу уңайдан, тарихи язма әдәби әсәрләрнең дә стиль ягыннан өйрәнелешен искәртеп узарга кирәк. Шул исәптән, татар әдәби теленең чишмә башы булган XIII гасыр язма истәлеге «Кыйссаи Йосыф» әсәренең дә тел-стиль чаралары җентекле өйрәнүне таләп итә. Әлеге әсәрнең стиль үзенчәлеге шунда ки: аңарда Көнчыгыш классик сурәтләү алымнары белән җирле төрки шигъри сүз байлыгы бергә үрелеп, үзенчәлекле сурәт барлыкка китерә. Бу сурәт нигезендә капма-каршылык ята, чөнки әсәрнең тасвиры аның эчтәлеге белән тыгыз бәйләнештә тора. Билгеле булганча, иң борынгы дини сюжетларның берсенә нигезләнгән әлеге әсәрдәге геройларның тормышы күтәрелештән һәм кире тормыш төбенә егылулардан тора. Шуларга бәйле рәвештә, автор тарафыннан сайлап алынган сурәтләү чараларында да капма-каршылык гәүдәләнә.

Әлеге язмада күчерелмә мәгънәдәге сурәтләү чараларының иң еш кулланыла торган һәм югары тасвир көченә ия булган төре – метафоралар өйрәнү предметы буларак билгеләнде.

Югарыда әйтелгәнчә, метафора нигезендә аерым предмет һәм күренешкә хас сыйфатларны охшашлык буенча башка предмет яки күренеш яссылыгына күчерү ята. Гадәттә, метафоралар тел метафораларына һәм образ (сурәт) метафораларына бүлеп өйрәнелә. Гади тел метафораларында, поэтик метафоралардан аермалы буларак, образлылык югалган, алар лексик-семантик яки номинатив функция башкаралар. Мондый метафоралар җанлы сөйләмдә бик актив, шулай ук әдәби әсәр тукымасына да бик җиңел килеп керәләр. «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә берничә тапкыр урнашу охшашлыгы нигезендә ясалган гади тел метафоралары кулланыла:

*Йагқуб Йусуфны көндирди, тышра чықды,*
*Бир аз тағның башыйға чықыб бақты.*

[Кол Гали, 1983, б. 62]

Биредә [тағның башыйға] – «тау башы» метафорасы «тауның иң биек урыны» мәгънәсен белдерә, урнашу урыны охшашлыгы нигезендә ясалган метафора буларак карала. Хәзерге телдән аермалы буларак, XIII гасыр теле өчен әлеге метафора төре телдә урнашып,

тотрыкланып җитмәве белән характерлана, моны сүзтезмә эчендәге сүзләрнең икесенең дә килеш кушымчалары алуы, изафә формасы күрсәтеп тора. Поэмада шушы шәкел буенча ясалган тагын берничә метафора очрый: тау аркасына – *Бир қашың арқасина ашурдылар* [Кол Гали, 1983, б. 62], Нил ермагына – *варуб Нилиң ирмағина йақын кәлди* [Кол Гали, 1983, б. 116], Гад коесының башына – *Ғәд қуйусының башыйға тәкүрдиләр* [Кол Гали, 1983, б. 718] һ.б.

Образ метафоралары гади һәм катлаулы төрләргә аерылалар. Бер сүздән торган гади метафоралар «Кыйссаи Йосыф» поэмасында сирәк очрый. Мәсәлән, Йосыф үзенә пычак белән ташланырга әзер торган абыйларын күреп, аларга «арысланларым» дип дәшә:

*Хазир икән бәним бу арысланларым,*
*Қанқый душман бәңа қапсын дидим инде.*
[Кол Гали, 1983, б. 68]

Абыйларын арыслан белән тиңләп, Йосыф ялгышмый: чыннан да, аның абыйлары арыслан кебек көчле, шул ук вакытта арыслан кебек ерткыч, мәрхәмәтсез дә. Авторның бик ерак тарихтан килгән әлеге метафораны куллануы очраклы түгел: бер үк вакытта көч, батырлык, идарә символы булган арыслан образының тискәре мәгънәсен күзаллау Йосыфның абыйларын тасвирлау өчен бик уңышлы табылган тел чарасы булып тора.

Икенче очракта Йосыф агаларына «өмидләрем» һәм «газизләрем» дип дәшә:

*Йусуф әйдүр: қардәшләрим, өмидләрим,*
*Нәтә буйлә қыйлурсыз, ғазизләрим?*
[Кол Гали, 1983, б. 64]

*Өмет* һәм *газиз* сүзләре әлеге контекст эчендә метафорик мәгънәгә ия. *Өмет* сүзенең эчке мәгънәсе киләчәк белән бәйле. Йосыфның үз агаларына өмет дип дәшүе аның иң якын туганнарына – газизләренә – тормышта зур өмет баглавын аңлата.

«Кыйссаи Йосыф» әсәрендә бик кызыклы деталь – «яшерен тел» белән сөйләшү күренеше очрый. Зинданда утырган Йосыф туган якларын бик сагына, атасы Йагкуб, агалары турында хәбәр ишетергә теләп, Мисырга килгән гарәп кешесеннән туганнарының хәл-әхвален сораша. Моны ул «яшерен тел» ярдәмендә эшли:

*Йусуф әйтүр: Қәнғандән кәлүрмүсән?*
*Анда бир қаба йығач билирмүсән?*
*Чүрәсиндә бутақлары көрәрмүсән,*
*Ол бутақлар оникими тәмам инди?*
[Кол Гали, 1983, б. 186]

Әлеге юлларда кулланылган *қаба йығач* метафорасы Йагкуб пәйгамбәрнең нәсел агачын, унике ботак – аның унике улын аңлата. Н.Ш. Хисамов күрсәтүенчә, «Мәхмүт Кашгари *каба* сүзен саңгырау тартык белән – *капа* рәвешендә кулланган һәм биек дип тәрҗемә

иткән» [Хисамов, 1979, б. 91]. *Каба* сүзе «йон эрләү өчен җайланма» мәгънәсендә татар теленең урта диалектында да кулланыла. Биредә дә шулай ук биек мәгънәсе чагыла булса кирәк: қаба йон беркетелә торган шомартылган озын агач таяк яисә яссы такта формасында ясала.

Ибне Йәмин улларының исемнәрендә дә метафорик мәгънә ята. Аларның һәркайсы Йосыфны, аның язмышы белән бәйле вакыйгаларны яисә күренешне истә тотып куелган: *Диңгез, Бүре, Кайгы, Кан, Гүр, Дәрд, Мәгарә, Арслан, Фәрид, Гариб, Кайгы, Кол* [Татар әдәби теле тарихы, 2020, б. 87].

Аерым әдәби вазифа башкаручы персонаж буларак, автор *тәwә (дөя)* образын да метафорик мәгънәдә кулланган: *бутасыный қалған тәwә тик иңрәр имди* [Кол Гали, 1983, б. 62]. Әлеге мисалда баласын югалтудан иңрәгән дөя образы Йагкуб пәйгамбәргә карата әйтелә һәм бу очракта чагыштыру алымы барлыкка килә. Баласын югалткан хайван образы татар халык авыз иҗатында гасырлар дәвамында эшкәртелеп, Идел буе регионына яраклаштырылган һәм шагыйрьләр иҗатында кулланылган.

*Тәwә (дөя)* образы Йосыфка туган иленнән, туганнарыннан, атасыннан хәбәр алып килүче буларак та тәсмерләнә, шуңа күрә дөяне җәберләгән гарәпкә Аллаһ җәза җибәрә, гарәпнең аягын җир тота, урыныннан кузгала алмый: *«Айақымый йир тутди!» – дәйүр имди* [Кол Гали, 1983, б. 186].

Автор биредә Йосыф белән дөя образлары арасында тәңгәллек-метафора төзи: Йосыф агалары һәм Зөләйха тарафыннан җәберләнеп, кол булып сатыла, зинданга утыртыла; дөя исә гаепсезгә хуҗасыннан каза күрә. Нәтиҗә бер үк: җәберләүче тәүбәгә килгәннән соң гына, Аллаһ тарафыннан ярлыкау ала: *ол әграби сөчинә тәүбә қылды, / айакларын йир қойды, нәҗат болды* [Кол Гали, 1983, б. 186].

Поэмада ике яки берничә сүздән торган катлаулы метафоралар еш очрый. Мондый сүзтезмәләрдә, гадәттә, бер компонент туры мәгънәдә, ә икенчесе күчерелмә мәгънәдә килә: *иман әркян* – иман нигезе, *ислам нуры*, *гыйлем кяни* – гыйлем чишмәсе, *дин табибы*, *хикмәт тохымы* – хикмәт орлыгы, *тәуфиқ қапусы* – тәрбия ишеге, *мәгриб-мәшриқ улулары* – Көнбатыш-Көнчыгыш олы затлары һ.б. Әлеге метафораларның күбесендә гарәп-фарсы алынмалары кулланылган, кайберләре турыдан-туры алынма сүзтезмәләр булып тора (*иман әркян, гыйлем кяни* һ.б.). Төрки яки катнаш телле метафоралар да актив. Шул ук вакытта поэмада образлылыгы кимрәк булган, ләкин нигезендә күчерелмә мәгънә яткан сүзтезмә-метафоралар да очрый. Еш кына аларның укучыга тәэсир итү көче югарырак та булырга мөмкин. Мәсәлән, *Ата қаулен бозмаға рәва көрмәс* [Кол Гали, 1983, б. 54] (*ата сүзен бозуны яхшы күрмәс*) җөмләсендә «*ата қауле» (ата* сүзе) тезмәсе, бер караганда, туры мәгънәдә, ягъни Йагкуб пәйгамбәрнең улы Йосыфка әйткән сүзе буларак кабул ителә. Шул ук вакытта «*ата қауле»* тәгъбиренең икенче мәгънәсе – ата-бабадан,

ягъни электән килгән йола, гореф-гадәт, тәрбия-әхлак дип аңларга кирәк. Хәзерге татар телендә ул шушы мәгънәдә кулланыла һәм телдә фразеологик берәмлек буларак яши. XIII гасыр әдәби телендә исә бу метафора тотрыклану процессын кичерә дип уйларга җирлек бар. *Ата хаkын, kардәш миһрен саkлаң имди* [Кол Гали, 1983, б. 74] юлында да *ата хакы, кардәш күңеле* тезмәләрендә метафорик мәгънә калкып чыга.

Поэмада тасвирый сыйфатлама – эпитет нигезендә ясалган метафоралар шактый урын алып тора: *kаты зәгыйф (нык зәгыйфь)* [Кол Гали, 1983, б. 194], *kаты душман (нык дошман)* [Кол Гали, 1983, б. 68], *kаты йүрәк (каты йөрәк)* [Кол Гали, 1983, б. 74], *kаты гыйшыk (каиы гыйшык)* [Кол Гали, 1983, б. 160], *kаты һәйбәт (зур көч)* [Кол Гали, 1983, б. 1068], *kаты ант (ныклы ант)* [Кол Гали, 1983, б. 130], *суыk бәгыр (суык бәгырь)* [Кол Гали, 1983, б. 118], *узаk йолым (озак юлым)* [Кол Гали, 1983, б. 136], *йаwыз доға (явыз дога)* [Кол Гали, 1983, б. 76], *йалан дүш (ялган төш)* [Кол Гали, 1983, б. 64] һ.б. Мәсәлән, поэмада Йосыфны нахакка җәберләгән Кылыч исемле кол-эфиопның әхлакый һәм физик сыйфатларын сурәтләгәндә, эпитет нигезендә ясалган метафоралар куллану күренеше очрый. Аны шагыйрь физик яктан көчле, кырыс, кара тәнле итеп тасвирлый:

*Бир хәбәши kул вар иди, Kылыч адлу,*
*kулларының җүмләсиндән ол һәйбәтлү,*
*kара йүзлү, йаулаk kаты сәйасәтлү,*
*Йусуфый аңа тәслим kыйлур имди*

[Кол Гали, 1983, б. 102].

*(Бер эфиоп кол бар иде, Кылыч исемле, Барлык коллардан да ул көчлерәк, Кара йөзле, бигрәк каты холыклы, Йосыфны аңа тапшыра инде).* Автор әлеге юллардагы *kара йүзлү* метафорасында сәнгатьчә сүз уйната: туры мәгънә аркылы тискәре күчерелмә мәгънәне искәртә һәм моны *һәйбәтлү, сәйасәтлү* сыйфатлары белән тулыландыра. Шагыйрьнең осталыгы шушындый юлларда чагыла да инде.

Йомгаклап әйткәндә, Идел буе Болгар дәүләте язма истәлеге булган «Кыйссаи Йосыф» әсәренең сәнгати сурәтләү чаралары хәзинәсе искиткеч бай. Поэмада язма китап теле һәм сөйләм теле җирлегендә формалашкан, бай һәм камилләшкән сөйләм чагыла. «Кыйссаи Йосыф» – шигъри бизәккә ия, искиткеч матур аһәңле әсәр. Әсәрнең телен баетуда, аны сәнгати югарылыкка күтәрүдә метафоралар аерым урын тоталар.

**Әдәбият**

*Бәширова И.Б.* Сүз белән сурәт ясау. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 176 с.

*Виноградов В.В.* Стилистика. Теория поэтической речи. Поэтика / Акад. наук СССР. Отд-ние литературы и языка. М.: Изд-во Акад. наук СССР, 1963. 255 с.

*Кол Гали.* Кыйссаи Йосыф / Төп текстны (транскрипцияне) әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны, кулъязмаларның тасвирламасын

ясаучы филология фәннәре кандидаты Ф.С. Фәсиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 542 б.

*Поварисов С.Ш.* Сүз-сәнгать илаһияте: уку-укыту әсбабы. Уфа, БДУ нәшр., 2011. 384 б.

Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы) / И.Б. Бәширова, М.З. Вәлиева, Г.Ф. Гайнуллина, Х.Х. Кузьмина; фәнни ред. Ф.С. Баязитова. Казан: ТӘһСИ, 2019. III т.: Лексика. Лексик-семантик категорияләрнең инвариант-парадигма үзенчәлеге һәм контекстуаль-синтагматик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. Беренче кисәк. – 528 б.

*Хаков В.Х.* Татар әдәби теле (стилистика). Казан: Татар. кит. нәшр, 1999. 304 б.

***Кузьмина Халисә Хатыйп кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Габдулла Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенең татар теле белеме кафедрасы доценты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 81′366

***Р.Ф. Мирхәев***

# XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ПРОЗАСЫ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ *-МАК* КУШЫМЧАЛЫ ИСЕМ ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Статья посвящена раскрытию функционально-стилистического потенциала имен действий на *-мак*, зарегистрированных в произведениях татарской просветительской прозы конца XIX – начала XX веков. Как показало исследование, они, будучи одним из традиционных элементов грамматической структуры старотатарского письменного литературного языка, сыграли немаловажную роль в формировании языковой ткани указанных текстов. До настоящего времени в работах татарских ученых по истории татарского литературного языка данные формы глагола описывались лишь фрагментарно. При этом их стилистический потенциал все еще остается вне поля зрения языковедов.

**Ключевые слова:** старотатарский письменный литературный язык, язык татарской просветительской прозы, имена действия, функционально-стилистические особенности.

The article is devoted to the disclosure of the functional and stylistic potential of the names of actions on the *mac*, registered in the works of Tatar educational prose of the end XIX – beginning XX centuries. As the study showed they being one of the traditional elements of the grammatical structure of the Old Tatar written literary language played an important role in the formation of the linguistic fabric of these texts. Until now in the works of Tatar scientists on the history of the Tatar literary language these verb forms have been described only in fragments. At the same time their stylistic potential still remains out of sight of linguists.

**Keywords:** Old Tatar written literary language, the language of Tatar educational prose, action names, functional and stylistic features.

Хәзерге татар тел белемендә исем фигыль исеме астында үзендә фигыль һәм исемнәргә хас үзенчәлекләрне берләштергән, һәм процессны атап, аның исемен белдереп килгән затланышсыз фигыль формасы карала. Фигыль формалары буларак, исем фигыльләр семантик планда эш-хәрәкәт мәгънәсен белдерәләр. Морфологик яктан аларга фигыльләрнең гомуми грамматик категорияләре хас. Аерым алганда, исем фигыльләр үзләренә юклык һәм юнәлеш кушымчаларын алырга мөмкин. Моннан тыш сөйләмдә алар синтетик һәм аналитик юл белән эшнең үтәлү дәрәҗәсен, модаль мәгънәләрне белдереп килә алалар, кайбер ярдәмче фигыльләр белән бергә перифрастик конструкцияләрне төзүдә катнашалар. Әлеге фигыль формаларының исем сүз төркеме белән бәйләнеше аларның сан, тартым һәм килеш категорияләре кушымчалары белән төрләнешендә чагылыш таба.

Хәзерге татар әдәби телендә исем фигыльнең *-у*/*-ү* кушымчасы ярдәмендә ясалган формасы норма буларак аерып чыгарыла [Татар

грамматикасы, 2016, б. 255–257; Тумашева, 1978, б. 158–160; Хисамова, 2015, б. 263–269]. Язма чыганаклардан күренгәнчә, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында әлеге форма белән бергә башка төр исем фигыльләрнең кулланылышы да күзәтелә һәм мәгърифәтче язучыларның әсәрләрендә үзләренең функциональ-стилистик мөмкинлекләре ягыннан иске татар әдәби теленең борынгыдан килгән традицион үзенчәлекләреннән саналган *-мак/-мәк* кушымчалы исем фигыльләр аерым урын тоталар. Алар билгеле бер дәрәҗәдә *-у* кушымчалы исем фигыльләрнең грамматик синонимы булып торалар. Шуның белән бергә текстларда *-мак* кушымчалы исем фигыльләр *-а* кушымчалы хәл фигыльләрне һәм *-ырга* кушымчалы инфинитив формасын да алыштырып киләләр.

Мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-мак* кушымчалы исем фигыльләр ярым тезмә, ярым чәчмә характерда иҗат ителгән дастаннарда, шигъри әсәрләрдә, газета текстларында һәм дини-фәлсәфи хезмәтләрдә кулланылалар [Шамарова, 1990, б. 81, Юсупов, 2006, б. 129–130, Миннуллин, 2012, с. 208–210, Абдулхаков, 2007, б. 22]. Нәтиҗә ясап әйткәндә, алар бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алалар һәм әдәби норма, норма вариантлылыгының бер күрсәткече булып торалар.

Безнең тарафтан каралган язма чыганакларда *-мак* кушымчалы исем фигыльләрнең тартым кушымчалары белән һәм алардан башка баш, юнәлеш, төшем һәм чыгыш килешләрендә килеп, төрле стилистик вазифаларда кулланылуы күзәтелә. Мәсәлән, М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында әлеге исем фигыльләр баш килештә аерым бер зат тарафыннан аның гражданлык позициясе белән бәйле рәвештә башкарылган яисә башкарылачак эш-хәрәкәтләрне һәм аңа хас булган сыйфатларны атап киләләр: *Хәсәдлек кеби бүйүк бәлайә мөбтәлә улан адәме Хисаметдин менла дәгел* ***дошман күрмәк****, билгакес аяр иде* [Акъегет, 1886, б. 5]; *... лазем улан шәй татары фән китабларындан хәбәрдәр идүб* ***уйгатмакдыр*** [Шунда ук, б. 61].

Билгеле бер дәрәҗәдә әлеге үзенчәлек З. Бигиев әсәрләрендә күзәтелә: *Хатыннарның чук* ***егламакы*** *гади шәйдер* [Бигиев, 1887, б. 67]; *Бөйләҗә сөйләшүб унбиш-егерме дакика эчендә* ***йәмәк вә эчмәк*** *тәмам улгач, мөсафирләремез садакаларын вирүб, имам әфәнде ивендән китделәр* [Бигиев, 1890, б. 5].

Алга таба М. Акъегет, үзе яшәгән чорда киң таралыш алган тискәре социаль күренешләр турында сүз алып барганда, баш килештәге *-мак/-мәк* кушымчалы исем фигыльләрне еш кына исем сүзтезмәләр составында атрибутив позициядә файдалана: *Хисаметдин менла шәһәрә килүб авылдашы Мохтарны* ***диләнмәк эшендә*** *күрүб...* [Акъегет, 1886, б. 30]; *Ләкин заманы хәзердә* ***суытмак вә йылытмак, сәвдермәк вә биздермәк һөнәрләре*** *юк идегене вә бөйлә һөнәрләр мөхәл вә там ялганчылык вә шарлатанлык идегене һәрбер зиһенле инсан яхшы белер* [Шунда ук, б. 50].

З. Бигиев атрибутив позициядә килгән бу төр исем фигыльләргә персонажларның шәхси теләк-омтылышларына ачыклык керткәндә мөрәҗәгать итә: *Габденнәсыр әфәнде, номеренә кайткач,* ***чәй эчмәк максуды*** *илә хадимдән самавыр таләб итәдер* [Бигиев, 1887, б. 54]; *Бән ... сезнең рөхсәтләреңездән башка Муса әфәндейә* ***хатын булмак нияте*** *илә бәлдәи Казанга килдем* [Шунда ук, б. 68–69]; *Җиһангир Агиев, хикәямезнең героинясе Маһруй кызның гыйрфанына хәйран вә хөснenә гашыйк улуб,* ***кызы никях идүб алмак фикеренә*** *килүб, ...* [Бигиев, 1890, б. 8].

Текстларда баш килештәге *-мак/-мәк* кушымчалы исем фигыльләр инфинитивның *-ырга/-ергә* формасын да алыштырып киләләр. Бу түбәндәге очракларда күзәтелә:

1) *эстәү* фигыле белән бергә персонажларның теләк-омтылышларын тасвирлаганда: *Яшь әфәнде чукдан бу кеби кеше илә* ***таныш улмак эстийур иде*** [Акъегет, 1886, б. 8]; *Менланың кердегене белүб вә бер* ***күрмәк эстәб*** *Хәнифә туташ эшене куйуб, ...* [Шунда ук, б. 10]; *Бу мәктүбемдә бән сәңа бер йәни вакыйга* ***белдермәк эстәмеш идем*** [Шунда ук, б. 39];

2) *мөмкин, лазем, кирәк, мөхаль* модаль сүзләре белән бергә, билгеле бер шартлар үтәлгәндә тормышка ашуы мөмкин булган, ниндидер сәбәпләр аркасында башкарылырга тиеш булган һәм үтәлеше кешенең ихтыярыннан тормаган эш-хәрәкәтләр турында сүз барганда: *Чүнкә гавам яхшы белер ки, Гали байны тәгъзим итсәң, тупрагыны вә йерене иҗарәйә учуз хак илә* ***алмак мөмкин*** [Акъегет, 1886, б. 12]; *Укымайы* ***сәвмәк лазем*** *дию фикерләнә-фикерләнә Хисаметдин менла гәнә одасында гизмәйә башлады* [Шунда ук, б. 7]; *Сәгать күб икән, бәңа мәктүб* ***язмак кирәк*** [Шунда ук, б. 23]; *Ул бер дакиканы да* ***кире кайтармак мөхаль*** [Шунда ук, б. 64]; *Гәрчә ерткаланмыш улса да, сурәт әҗзаларыны ба тәртиб җәмг кылуб каралса, нә шәкелле сурәт идегене* ***аңламак мөмкин*** [Бигиев, 1887, б. 7]; *Беркач сәгать поездны* ***бәкләмәк лазем иде*** [Шунда ук, б. 42].

Юнәлеш килешендәге *-мак/-мәк* кушымчалы исем фигыльләрне мәгърифәтче язучылар, нигездә, түбәндәге максатларда файдаланалар:

1) *башлау* фигыле белән бергә *-а/ә, -ый/-и* кушымчалы хәл фигыльләр урынында персонажлар башкарырга керешкән эш-хәрәкәтләрне белдерү өчен: *...мәзкүр пычак илә ышпалеры юаш-юаш* ***ярмага башлады*** [Акъегет, 1886, б. 10]; *... чүнкә раст килгән вакытда кыз вә җегет берберенә* ***бакышмага башладылар*** [Шунда ук, б. 20]; *...тәфтишчеләр номерә эчендәге әшьяйы* ***карамага башладылар*** [Бигиев, 1887, б. 7]; *Номерләр сахибе Габдуллин килгәч, господин прокурор Габдуллиндан бу тарика* ***сөаль кылмага башлады*** *...* [Шунда ук, б. 43–44]. *...әсбабларның хакыны бер-бер сораб,* ***хисаб кылмага башладылар*** [Шунда ук, б. 58];

2) инфинитивның *-ырга/-ергә* формасы урынында персонажларның ихтыяры һәм теләк-омтылышларыннан килеп туган эш-

хәрәкәтләр белән кыек объект мөнәсәбәтләрендә торган процессларны бирү өчен: *Бундан бөйлә яшь әфәнде кууҗыйа арабаны чана илә **бәрабәрләтмәгә боеруб**, менлайа хитабән сүзә бөйлә башлады* [Акъегет, 1886, б. 8]; *Һичбер инсан аңа **каршы дормага җәсарәтләнмәз иде*** [Шунда ук, б. 12]; *Һич улмаса милкем улса иде, мәнфәгате исламиямезә һәрвакыт **сарыф итмәгә әзер булыр идем*** [Шунда ук, б. 32]; *Судебный следователь бу тарика **тәфтиш кылмага шөруг кылды*** ... [Бигиев, 1887, б. 5]; *Маһруйны да **язмага вә укымага мән үгрәтдем*** [Бигиев, 1890, б. 29];

3) шулай ук инфинитивның *-ырга/-ергә* формасы урынында персонажлар тарафыннан башкарылган эш-хәрәкәтләрнең максатын ачыклау өчен: *Кичәнең ярылары булгач, Мохтар мөсафирханәйә **кичәләмәгә кәтде*** [Акъегет, 1886, б. 33]; *Ничүн шадланмасын, кызыны мондай байга **сурмага килделәр*** [Шунда ук, б. 34]; *Тарафындан да тәкәллем тәмам улгач, присяжный заседательләр ... икенче бүлмәйә **иттифак кылмага китделәр*** [Бигиев, 1887, б. 46]; *Господин Иванов, йирендән торуб, өстәлдәге кәгазьне **карамага килүб**, ...* [Шунда ук, б. 61].

Төшем килешендәге *-мак/-мәк* кушымчалы исем фигыльләрне авторлар, аерым алганда, М. Акъегет, персонажлар тарафыннан башкарылган эш-хәрәкәтләр белән туры объект мөнәсәбәтләрендә торган процесслар турында язганда файдалана: *Бөйлә аҗы **агламагы ишедүб**, анасы керер* [Акъегет, 1886, б. 6]; *Вә **соранмак-диләнмәкне гакылларына мотабик күрүб** ... хәдисне инкяра калкышдылар* [Шунда ук, б. 17].

Чыгыш килешендәге *-мак/-мәк* кушымчалы исем фигыльләргә язучылар үзләре яисә аерым персонаж ниндидер сәбәпләр аркасында башкарырга теләмәгән эш-хәрәкәтне ачыклап килгәндә мөрәҗәгать итә: *Карьянең әһалисе ике йөз әв кадәр улуб, адыны **фаш итмәкдән чәкинийурыз**, ...* [Акъегет, 1886, б. 2]; *Бунда Гали байлар, Бикбулат менлалар, Хисаметдин менла **сүзләшмәкдән качуб** мәгълүб улды, дийү зийадә мәсрүр улдылар* [Шунда ук, б. 17]; *Ике йә өч көн мөкәддәм әҗәлене эзләб, Маһруй муенына питлә куймыш исә дә, шимди **үлмәкдән гаять дә курыкмайа башлады*** [Бигиев, 1890, б. 55].

Әсәрләрдә *-мак/-мәк* кушымчалы исем фигыльләрнең *өчен // ичүн* һәм *илә* бәйлекләре белән бергә төрле хәл мөнәсәбәтләрен белдерә торган конструкцияләр составында кулланылуы да күзәтелә. Мәсәлән, *-мак ичүн* конструкцияләре персонажлар тарафыннан башкарылган эш-хәрәкәтләрнең максатын ачыклап килә: *Җомга намазыны укыдыкдан соңра Хисаметдин менла атны чанайа йигүб, бәгъзы кирәк шәйләр **алмак ичүн** шәһәрә юлланды* [Акъегет, 1886, б. 7]; *Каравыллык җәһәтендә булынан Хәнифә туташ менланың сүзләрене ишедүб мәмнүн улды вә үз җенесе улан кадынлар хакында даха мәгълүмат **хасыйл итмәк ичүн** диккатене артдыруб колакларыны мөсафирлек бүлмәсенә салды* [Шунда ук, б. 11]; *Әхмәди бай ... җәй фасылыны кымыз эчүб **кәчермәк өчен** бәлдәи Самардан биш-алты чакрым йирдә*

*кира хак илә бер «дача» ялламыш иде* [Бигиев, 1887, б. 53]; *Шимди исә **йимәк-эчмәк ичүн** Җиһангир Агиев, бер чәйханәйә керүб, лазем шәйләре сораб, ашаб-эчүб утырадыр* [Бигиев, 1890, б. 36].

*-мак илә* конструкцияләре исә әсәрләрдә персонажлар тарафыннан башкарылган эш-хәрәкәтләр белән кыек объект мөнәсәбәтләрендә торган процесслар турында сүз алып барганда кулланыла: *Мәзкүр бүлмәсендән мөсафирлек бүлмәсенә бер ярык ясады вә шу ярыкдан егет менлайы **бакмак илә** хушланыр* [Акъегет, 1886, б. 10]; *Чүнкә куәтле вә мөхкәм гыйшык бер-беремезнең тыш вә заһири күренешемезне **белмәк илә** хосулә килмәз, сез заһиремне яратдыңыз* [Шунда ук, б. 25–26]; *Анҗак бу сәтралары сезә **язмак илә** күңелем бераз тәсәлле табды* [Шунда ук, б. 37]; *Бер ярык табды вә шу ярыкдан Муса әфәндейе **күрмәк илә** Хәдичә туташ бәхтияр улды* [Бигиев, 1887, б. 33]; *Мөкаддәм керәнләр мәхкәмәнең бүйүк залында улан агач эскәмияләрнең алдагы софуфларына **ултырмак илә** бәхтияр улдылар* [Шунда ук, б. 37].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, исем фигыльләр татар теленең барлык структур берәмлекләре кебек бай функциональ-стилистик потенциалга ия. Моңа *-мак* кушымчалы исем фигыльләрнең без караган текстларда сәнгатьчә кулланылыш үзенчәлекләре дәлил булып тора.

**Әдәбият**

*Акъегет М.* Хисаметдин менла. Милли роман яки хикәя. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1886. 70 б.

*Абдулхаков Р.Р.* Языковые особенности произведений Мусы Джаруллаха Бигиева: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2007. 24 с.

*Бигиев З.* Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә. Роман. Казан: Типогр. Г.М. Вечеслава, 1887. 77 б.

*Бигиев З.* Гөнаһе кәбаир. Роман. Казан: типогр. Г.М. Вечеслава, 1890. 72 б.

*Миннулин Б.К.* Татарская газета «Борхане таракки». Лингвистические исследования. Казань, 2012. 300 с.

Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 432 б.

Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле. Морфология. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1978. 221 б.

*Хисамова Ф.М.* Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Татар. кит нәшр., 2006. 335 б.

*Шамарова Г.Б.* Язык дастанов А. Уразаева-Курмаши «Кисса-и буз джигит», «Кисса-и Тахир и Зухра»: дис. … канд. филол. наук. Казань, 1991. 166 с.

*Юсупов А.Ф.* Язык произведений Шамсетдина Заки. Морфология. Казань: Казанский государственный университет им. В.И. Ульянова-Ленина, 2006. 204 с.

***Мирхәев Рифат Фирдинат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 81′282

***А.Я. Хөсәинова***

## ТАТАР ДИАЛЕКТАЛЬ КОНСОНАНТИЗМЫН ӨЙРӘНҮНЕҢ КЫСКАЧА ТАРИХЫ

В данной статье рассматривается история изучения звуковой системы диалектов татарского языка, а именно согласных фонем, проводится обзор трудов в хронологической последовательности с начала XIX столетия. Подчеркивается актуальность исследования фонетических особенностей диалектов татарского языка. Делается акцент на необходимости обобщения накопленных диалектных материалов и комплексного изучения фонем татарских диалектов в синхронном аспекте.

**Ключевые слова:** фонетика, диалекты татарского языка, консонантизм, татарская диалектология, согласные фонемы.

This article examines the history of the study of the sound system of the dialects of the Tatar language, more specifically consonant phonemes. The review of works in chronological order since the beginning of the XIX century is carried out. The relevance of the study of phonetic features of the dialects of the Tatar language is emphasized. The emphasis is placed on the need to generalize the accumulated dialect materials and a comprehensive study of the phonemes of Tatar dialects in the synchronous aspect and generalization.

**Keywords:** phonetics, dialects of the Tatar language, consonantism, Tatar dialectology, consonant phonemes.

Татар диалектларының фонетикасын өйрәнүнең шактый озын тарихы бар. Төрле авазлар составы, аерым сөйләшләрнең әйтелеш үзенчәлекләре турындагы кайбер мәгълүматларны XIX гасыр башында басылган материалларда табарга мөмкин.

Татар теленең аваз төзелеше һәм аның классификациясе турында беренче мәгълүматлар С. Хәлфин, И. Гиганов, И. Хәлфин, А. Троянский, М. Иванов, Г. Мәхмүтов, В. В. Радлов һ.б. хезмәтләрендә урын ала. Шуны да ассызыклап үтәргә кирәк: әлеге авторларның хезмәтләре укыту максатын күздә тотып язылган, шуңа бәйле рәвештә аларда татар теленең фонетик төзелешен комплекслы фәнни интерпретацияләү юк.

Бу чорда басылган татар теле дәреслекләре татар теленең көнчыгыш диалектына нигезләнеп язылган. И. Гигановның 1801 елда чыккан дәреслегендә Тобольск ареалы лексикасы гарәп графикасында гына түгел, рус телендә дә бирелгән, бу шул чордагы себер татарларының сөйләм теле өчен хас үзенчәлекләрне күрергә мөмкинлек бирә.

XIX гасырның икенче яртысында татар диалектларын өйрәнүгә багышланган махсус хезмәтләр языла, аларда фонетикага да зур игътибар бирелә (Н.П. Остроумов. «Первый опыт словаря народно-

татарского языка по выговору крещённых татар Казанской губернии», 1876; А.Г. Бессонов. «О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам», 1881). В. В. Радлов үзенең күп томлык «Опыт словаря тюркских наречий» хезмәтендә текстларның транскрипциясен бирә һәм ул татар сөйләшләренең аваз үзенчәлекләрен чагылдыра. А. Воскресенский «Русско-татарский словарь» (1894) дип исемләнгән хезмәтендә татар һәм рус телләрендә авазларның әйтелешендәге үзенчәлекләргә кыскача чагыштырма характеристика бирә.

Татар теленең аваз төзелешен өйрәнүгә К. Насыйри зур өлеш керткән. «Әнмүзәҗ» китабында автор авазлар классификациясенең кайбер принципларын күрсәтә. Галим авазларны сузыкларга һәм тартыкларга аера (тавыш хәрефләре һәм тавышсыз хәрефләр). Тартык авазларны классификацияләгәндә, К. Насыйри бердәм принципка таяна. Шуның нигезендә бер төркем тартыкларны – актив әйтелеш әгъзалары, икенчеләрен пассив әйтелеш әгъзалары катнашуга карап төркемли. Шуңа күрә аның классификациясе бүгенгедән нык аерыла. Шулай ук галим аерым авазларның комбинатор үзгәрешләрен күрсәтә, ассимиляция һәм диссимиляция кебек күренешләрне игътибарсыз калдырмый, татар телендәге сандхи күренешләренә дә туктала.

XX гасыр башында Г. Нугайбәкнең «Төрлек», Г. Ибраһимовның «Татар сарыфы», Җ. Вәлидинең «Татар теленең кагыйдәләре» китаплары дөнья күрә. Бу дәреслекләр татар теле дәреслекләре сыйфатында язылган һәм чыгарылган, шул сәбәпле алар тел гыйлеменең күп кенә тармакларын колачлый. Бу хезмәтләрдә фонетика бүлеге чагыштырмача аз тәкъдим ителгән.

XX гасыр башында татар теленең көнбатыш диалекты сөйләшләрен, касыйм татарлары сөйләшләрен һ.б. чагыштырма-тарихи аспектта өйрәнү үсеш ала (С.Е. Малов. «Из поездки к мишарям (о наречии мишарей Чистопольского уезда», 1903; Е.Д. Поливанов. «Фонетические особенности касимовского диалекта», 1923 һ.б.).

Татар теленең аваз составын өйрәнүнең алга таба үсешенә Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы» хезмәте зур йогынты ясый. Автор элек татар телендә эшләнмәгән проблемаларны тикшерә. Мәсәлән, сингармонизм, ассимиляция, диссимиляция һәм орфоэпия мәсьәләләре кебек фонетик күренешләргә фәнни интерпритация бирелә. Г. Алпаров авазлар классификациясен тәкъдим итә. Әлеге классификациядә авазларның ясалу урыны һәм ысулы, сөйләм аппараты әгъзаларның эше исәпкә алына. Тавыш һәм шауның катнашуына карап, тартыклар яңгырау һәм саңгырауларга бүленә. Беренчеләре – борын, салмак, фрикатив, шартлау төрләренә, ә саңгыраулар – фрикатив һәм шартлагычларга бүленә. Шаулы һәм сонантларга бүленеш юк.

Татар теленең аваз төзелешен һәм башка кардәш телләр белән чагыштырма аспектта сингармонизм кебек фонетик закончалыкларны өйрәнүгә мисалларны В. А. Богородицкий хезмәтләрендә («Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками»,

1934) табарга мөмкин. 30 нчы еллардан башлап төрле төбәкләрдә яшәүче татарларның сөйләшләре махсус оештырылган экспедицияләр вакытында тикшерелә, диалекталь материаллар җыела, программалар буенча сораулар бирелә, һәм 1947 елда беренче тапкыр татар диалектологиясе буенча дәреслек басылып чыга (Җәләй Л. «Татар диалектологиясе», 1947). Анда автор татар теленең урта, көнбатыш һәм көнчыгыш диалектларының фонетик үзенчәлекләре турында мәгълүмат бирү белән генә чикләнми, аваз күренешләренең килеп чыгу сәбәпләрен һәм тарихын да аңлата.

60 нчы елларда татар диалектларын чагыштырма-тарихи яссылыкта өйрәнү яңа юнәлеш ала. Г.Ф. Саттаровның «Татар әдәби теленең һәм диалектларының аваз составын чагыштырып анализлау» дигән хезмәтендә, татар әдәби теленнән аермалы буларак, урта, көнбатыш һәм көнчыгыш диалектларның әйтелеш үзенчәлекләре ачыклана һәм татар телендәге өч диалектның төп фонетик билгеләре күрсәтелгән таблица китерелә. Татар теле диалектларының фонетик закончалыклары шулай ук Г.Ф. Саттаровның «Мәктәптә тел культурасы» китабында да бәян ителә. Ф.Ю. Йосыповның «Җирле сөйләш шартларында фонетика укыту» дигән хезмәтендә татар диалектларының аваз системасы вариантларына ареаль планда күзәтү ясала, авазларның тәңгәл килүләре һәм фонетик закончалыклар тасвирлана. 1984 елда нәшер ителгән татар диалектологиясе дәреслегендә сузык һәм тартыкларның яраклашуына күпсанлы мисаллар китерелә, кайбер аваз күренешләрен аңлату омтылышы ясала. Татар галимнәренең зур тырышлыгы нәтиҗәсе буларак дөнья күргән «Атлас татарских народных говоров Среднего Поволжья и Приуралья и комментарии к «Атласу...» китабында сузык һәм тартык авазлар вариантларының таралыш ареалы, дифтонглар куллану, авазларның яраклашуы күрсәтелгән карталар тәкъдим ителә. Татар сөйләшләренең фонетикасы теге яки бу диалектлар һәм сөйләшләр буенча язылган кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрендә тикшерелде, шулай ук әлеге тема буенча материаллар монографик тикшеренүләрдә чагылыш тапты [Татар халык сөйләшләре, 2008, б. 6].

Диалектологиядә татар теле диалектларын өйрәнүдә эксперименталь юнәлеш тә зур әһәмияткә ия. В.А. Богородицкий (1933), Г.Ш. Шәрәф (1927; 1928), У.Ш. Байчура (1959), Г.М. Сөнгатов (1991) һ.б. фәнни хезмәтләре шуны раслый.

Г. М. Сөнгатов (1991) татар тел белемендә беренче тапкыр себер татарларының тубыл-иртыш диалектына караган саз ягы сөйләше системасын эксперименталь рәвештә тикшерә. «Татар диалектларының фонетикасы» (2000) китабында татар теле диалектларының төп фонетик үзенчәлекләрен өйрәнә.

2008 елда басылган «Татар халык сөйләшләре: ике китап» дигән хезмәттә, башка лингвистик үзенчәлекләр белән беррәттән, татар теле диалектларының барлык сөйләшләре буенча фонетик үзенчәлекләр дә яктыртыла.

2005 елда Т.Р. Рыжикова бараба татарлары теле консонантизмын эксперименталь фонетика методлары белән системалы рәвештә тикшерде [Рыжиков, 2005, с. 4].

Шулай итеп, диалектология буенча язылган хезмәтләр, нигездә, аерым диалектларның һәм сөйләшләрнең лингвистик аспектларын өйрәнүгә багышланган. Диалектларны бербөтен система буларак өйрәнү, диалектларны лингвистик география объекты буларак тасвирлау, генетик һәм структур планда чагыштырма анализ; диасистема үсешенең эчке закончалыкларын билгеләү; тышкы факторларны ачыклау һәм аларны ареаль лингвистика күзлегеннән анализлау һ.б. мәсьләләр бүгенге татар диалектологиясе фәненең актуаль проблемаларын тәшкил итә.

Ареаль лингвистика методлары һәм алымнары диалектларны, катлаулы һәм каршылыклы система буларак, тарихи контекстта өйрәнергә мөмкинлек бирә. Телнең чагыштырмача тотрыклы ярусын – авазлар системасын ареаль аспектта өйрәнү тел һәм халык тарихына кагылышлы күп кенә мәсьәләләрне ачарга ярдәм итәр иде. Шул сәбәпле һәр татар сөйләшенең тел күренешләре үзенчәлекләрен аңлату өчен, тел системасын тәшкил итүче һәр структур элементны анализларга кирәк. Татар әдәби телендәге һәм татар диалектларындагы тартыклар системасы татар милли телен тасвирлаганда кулланыла торган элементларның берсе булып тора. Татар милли теленең консонантизмнар системасын чагыштырып өйрәнү авазларның гомуми һәм төрле билгеләрен ачыкларга мөмкинлек бирә.

Төрки телләрнең тартыклар системасы гомуми планда тулысынча өйрәнелгән. Шул ук вакытта аерым төрки телләрнең консонантизмы, диалекталь материаллар кулланып, тулы һәм җентекле анализлауны таләп итә. Татар диалектлары тартыклар системасының формалашу һәм үсеш проблемалары тулы күләмдә өйрәнелмәгән. Бүгенге көндә, башка төрки телләрдәге кебек үк, татар теленең барлык өч диалекты буенча да бай фактик материал тупланган. Шуңа бәйле рәвештә әлеге материалны комплекслы өйрәнү һәм гомумиләштерү зарурлыгы туа.

Бүгенге тел белемендә фонетик тикшеренүләр, традицион методлар белән беррәттән, эксперименталь мәгълүматлар кертүне таләп итә. Татар теле диалектларын хәзерге халәтендә, синхрон аспектта тасвирлау актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Татар диалектларының авазлар системасын анализлау һәм саклау – бик әһәмиятле юнәлеш, чөнки аларны өйрәнү һәр сөйләшнең үз телен яхшы белгән вәкилләре булганда гына мөмкин, ә андыйларның саны кими бара.

**Әдәбият**

*Алпаров Г.* Шәкли нигездә татар грамматикасы. Казан, 1925; 2 басма. Казан, 1926. 164 б.

*Байчура У.Ш.* Звуковой строй татарского языка. Ч. I. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1959. 185 с.

*Гиганов И.* Грамматика татарского языка. СПб.: Императорская Академия наук, 1801. 188 с. + 75 с.

*Насыйри К.* Әнмүзәҗ. Казан, 1895; Казан, 1975. 213 б.

*Рыжикова Т.Р.* Консонантизм языка барабинских татар: сопоставительно-типологический аспект. Новосибирск: Изд-во СО РАН, 2005. 266 с.

*Саттаров Г.Ф.* Мәктәптә тел культурасы. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1965. 151 б.

*Саттаров Г.Ф.* Сопоставительный анализ звукового состава татарского литературного языка и диалектов // Вопросы татарского языкознания. 1965. С. 120–146.

*Сунгатов Г.М.* Фонетическая система заболотного говора тоболо-иртышского диалекта сибирских татар (экспериментально-фонетическое исследование): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1991. 23 с.

*Сөнгатов Г.М.* Татар диалектларының фонетикасы. Казан, 2000. 44 б.

Татар халык сөйләшләре: Ике китапта / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. Казан: Мәгариф, 2008. Беренче китап. 463 б.

*Шараф Г.* Палятограммы звуков татарского языка сравнительно с русскими. Казань, 1927. 40 с.

*Шараф Г.* Сонорная длительность татарских гласных // Вестник научного общества татароведения. Казань, 1928. № 8. С. 180–265.

***Хөсәинова Алинә Ямил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82.091

***И.Г. Закирова,***
***С.Б. Даутова***

# АЛТЫН УРДА ЧОРЫН ЧАГЫЛДЫРГАН ТАРИХИ РОМАННАР: АВТОР КОНЦЕПЦИЯСЕ

## (В. Ян һәм И. Есенберлин иҗатлары мисалында)

В статье раскрывается художественные особенности авторских концепций истории и личности эпохи Золотой Орды. Несмотря на значимость эпохи Золотой Орды, в общественном сознании существует противоречие, связанное с мало исследованностью этой темы. Историческое мышление писателя также несет в себе влияние идеологического контекста. Автор воссоздает события прошлого, опираясь на исторические источники, факты, не противореча научно-объективному изображению истории.

**Ключевые слова:** Золотая Орда, исторический роман, В. Ян, И. Есенберлин, исследование творчества.

The article reveals artistic features of the author's concepts of history and personality of the era of the Golden Horde. Despite the importance of the era of the Golden Horde there is a contradiction in the public mind associated with the little research on this topic. The historical thinking of the writer also bears the influence of the ideological context. The author recreates the events of the past, relying on historical sources, facts, without contradicting the scientific and objective depiction of history.

**Keywords:** Golden Horde, historical novel, V. Yan, I. Esenberlin, creativity research.

Тарихи әсәрләрнең һәм тарихның багланышлары, мөнәсәбәтләре – катлаулы күренеш. Җәмгыять тормышына йогынты ясап, әдәбият тарихи-иҗтимагый аңны формалаштыра. Тарихи әсәрләр укучыны халыкның тарихы, үткәндәге вакыйгалар белән таныштыра. Язучы, тарихи вакыйгаларны һәм геройларны бүгенге күзлектән, үз чорыннан торып сурәтли. Шул рәвешле, тарихи картинада хәзерге чор авторының рухи тәҗрибәсе, әхлакый потенциалы да чагыла. Тарихи әсәрләрдә тарихи шәхес соңгы чорлар әхлак-әдәп позициясеннән кабул ителә, тарихи үткәннең проблемалары хәзерге заман күзлегеннән бәяләнә. Ягъни, бер яктан, автор ерак үткәннәрне XX гасыр позициясеннән яктырта, укучы аны үзенең дөньяга карашы аша кабул итә. Тарихи роман жанрына даими кызыксыну шуның белән дә аңлатыла. Шул ук вакытта тарихи романнарның гаять көчле идеологик корал булуын да онытырга ярамый. Ягъни тарихи роман – ул авторның үткәннәрне торгызуы гына түгел, бүгенге көндә дә актуальлеген җуймаган проблемаларның чыганакларын, тарихларын өйрәнү дә. Алтын Урда чорын яктырткан тарихи әдәбиятны өйрәнү халыкның тарихи

хәтерен, аның рухи кыйммәтләрен һәм милли традицияләрен саклап калуга, аның милли аңын уятуга хезмәт итә.

Югарыда әйтелгәннәргә бәйле рәвештә, язма чыганакларны һәм аларның әдәби интерпретациясен чагыштырма аспектта өйрәнү шактый кызыклы күзәтүләргә юл ача. Монгол-татарлар һәм аларның тарихлары, Урта гасыр дәүләтләре, аларның мәдәнияте, икътисады, сәясәте турында сөйләүче әдәбият, барыннан да элек, тарихи чыганакларга таяна. Ләкин алдан ук шуны искәртеп китү урынлы булыр: язма чыганаклар үзләре дә, хәтта вакыйга эзеннән иҗат ителүләренә карамастан, гаять субъектив, документаль характерда булудан бигрәк, матур әдәбиятка яки фольклорга тартым.

Тарихи романнарның әһәмияте шунда: алар билгеле бер вакыйгалар яки тарихи шәхесләр турында мәгълүмат биреп кенә калмый, ә халыкта фикер формалаштыра. Алтын Урда турындагы мәгълүматны үз эченә алган тарихи документлар укучыларның киң даирәсенә мәгълүм түгел, күбесе үзгәртеп кору елларыннан соң гына дөнья күрә.

Әлеге мәкаләдә ике трилогия – Василий Янның «Монгол явы» («Нашествие монголов»), И. Есенберлинның «Алтын Урда» («Золотая Орда») трилогияләре анализлана. В. Янның «Монгол явы» трилогиясе «Чыңгыз хан» (1939), «Батый» (1942), «Соңгы диңгезгә» («К последнему морю») (1955) романнарыннан тора; И. Есенберлинның «Алтын Урда» трилогиясе «Алты башлы Айдахар» (1982), «Айдахарның башы» («Голова Айдахара») (1985), «Айдахарның һәлакәте» («Гибель Айдахара») (1985) романнарын үз эченә ала.

В. Янның «Монгол явы» трилогиясе нәшер ителгән елларда ук халыкта популярлык казана. Трилогиянең беренче «Чыңгыз хан» китабы 1942 елда Дәүләт премиясенә (ул вакытта Сталин премиясе дип йөртелә) лаек була. И. Есенберлин трилогиясе Казакъстанда гына түгел, аннан читтә дә таныла. Әлеге романнарның хәзерге вакытта популярлыгы халыкның тарихи үткәннәргә кызыксынуы арту белән дә бәйле.

Романнарда китерелгән күпсанлы тарихи мәгълүматларга караганда, авторлар язма чыганакларны яхшы белгән, монгол, гарәп, фарсы чыганакларына, рус елъязмаларына таянып эш иткән талантлы әдипләр булып ачылалар. Тарихны тирәнтен белүе белән автор укучының мәхәббәтен казана, әмма трилогияләрдә Алтын Урда тарихын, әлеге чор вакыйгаларын берьяклы гына яктырту, еш кына бозып күрсәтүләр дә очрый, бу очракта авторларның тарихка чорның идеологик постулатлары белән бәйле мөнәсәбәте турында сүз бара. Алтын Урда халыклары тарихы кебек фальсификациягә дучар ителгән тарих аздыр. Бу дәүләт идеологиясенең берьяклы булуы белән бәйле иде. Озак вакытлар Алтын Урда тарихын өйрәнүдә шундый караш өстенлек итеп, бары СССР таркалганнан соң гына, күп кенә мәсьәләләр, шул исәптән Алтын Урда тарихы да, объектив өйрәнелә башлады.

Совет идеологиясе Алтын Урда чорын бары тискәре яктан гына бәяләп, әлеге дәүләткә карата әйтелгән уңай фикерне беркайчан да

уздырмады. Совет чоры язучылары татар-монголлар, аларның дәүләтчелеге, югары дәрәҗәгә ирешкән икътисады, мәгърифәте һәм күренекле галимнәре, дипломатлары, танылган полководецлары турында уңай фикер әйтеп, аларга объектив бәя бирә алмыйлар иде.

Русь һәм Алтын Урда арасындагы мөнәсәбәтләр, шулай ук бу ике дәүләт халыкларының үзара мөнәсәбәте белән дә эш шулай тора. Алтын Урданың бөтен тарихы дәреслектән дәреслеккә күчеп кабатланган ике сүзгә сыюын да онытырга ярамый. Монголлар (соңрак татарлар да) рәхимсез, кыргый халык буларак тасвирланып, аларга карата «Татарское иго» дигән термин кулланышка керә. Әлеге терминның сәяси яктан корректлы булмавы турында күп сөйләргә мөмкин. Бу зур бер халыкны ихтирам итмәү генә түгел, ә «Казан тарихы»нда әйтелгәнчә, Казан ханлыгының Иван Грозный тарафыннан алынуын да аклый : «осироте бо тогда и обнища великая наша Русская земля, и отъяся слава и честь ея, но не вовеки, и поработися богомерску царю и лукавнейшю паче всеа земли, и предана бысть, яко Иерусамлимъ в наказание Навоходоносору, царю вавилонскому...»[1] [Казанская история, с. 45]. Казан тарихында исә монгол басып алучыларына мөнәсәбәттә «ярмо» термины кулланыла [Казанская история, с. 57]. Бу термин әйләнешкә кергән вакытта рус җирләренең Алтын Урдага бәйле булмавын да истә тотарга кирәк. Алтын Урдага мөнәсәбәттә «иго» терминын беренче тапкыр 1479 елда поляк тарихчысы Ян Длугош куллана: «excusso iugo barbaro» («Свергнув варварское иго») [loannis Dlugossii, p. 697]. Рус телле чыганакларда термин соңрак урын ала. Үзенең «История государства Российского» дигән хезмәтендә Н.М. Карамзин бу терминнан Русьның Алтын Урда бәйсезлегеннән котылуын тасвирлаганда файдалана: «государи наши торжественно отреклись от прав народа независимого и склонили выю под иго варваров» [Карамзин, с. 32–33].

Урынлы сорау туа: бу «иго» булганмы соң? Алтын Урда булмаса, һәм ул Русьны яулап кына калмыйча, күрше дәүләтләрнең агрессив басып алуыннан да сакламаса, Россия тарихы нинди булыр иде? СССР халыкларының тормышына, тарихына һәм рухи мәдәниятенә әлеге «иго» турындагы тәгълиматның йогынтысы нинди?

В. Янның трилогиясе И.В. Сталин идарә иткән, «Сталинның шәхес культы» еллары буларак танылган чорда языла, 1939 елда – беренче романы, 1942 һәм 1955 елларда соңгылары нәшер ителә. Бу чор вакыйгалары фонында язылган роман, әлбәттә, шул чор идеологиясен генә яктырта ала, В. Янның Алтын Урда тарихын берьяклы, тискәре яктан гына яктыртуы – закончалыклы күренеш. Трилогия монголтатарларның тышкы кыяфәтенә, кием-салымына, гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә, көнкүрешенә, теленә нәфрәт белән сугарылган, автор әлеге халык белән бәйле һәр күренешне мәсхәрә белән тасвирлый,

[1] Кайбер цитаталарны, мәгънәне төгәл тапшыру өчен, оригиналда калдырабыз, яки рус телендә бирәбез.

шул рәвешле бөтен бер халыкның кешелек сыйфатларын таптый. Нәкъ менә шундый тарихи әсәрләр шовинистик идеяләргә яшәргә ярдәм итә дә.

И. Есенберлинның «Алтын Урда» трилогиясе 1979 елда языла башлап, 1983 елда тәмамланган. Әлеге трилогиянең басылып чыгуы казакъ халкы өчен генә түгел, ә Алтын Урда варислары булган башка халыклар өчен дә көтеп алынган вакыйгага була. Бу трилогия Совет дәүләтенең «посттоталитар» чорында иҗат ителә. Әлеге чор, француз тарихчысы Фюре Франсуа язганча, «төрмә һәм психушкаларны башкача уйлаучылар белән тутыру өчен җитәрлек дәрәҗәдә репрессив, әмма бөтен халык тел яшерерлек курку тудырырга да сәләтле түгел» [Фюре Франсуа, с. 540]. Автор Алтын Урданың чәчәк ату һәм җимерелү дәверен сурәтли, бу гадәттән тыш катлаулы чорга караган тарихи материалларны системалаштыра, тарихи вакыйгаларны төгәл тасвирларга омтыла, шул чор шәхесләренең якты образларын тудыра. Шул ук вакытта язучы, чор идеологиясенә бәйле рәвештә, Алтын Урданың төрки халыклар этногенезын үстерүдәге һәм аларның киләчәк дәүләтчелеген булдырудагы ролен бик тыйнак билгели.

И. Есенберлин, совет чоры язучысы буларак, әлбәттә, чор идеологиясенә буйсынырга мәҗбүр була, шуңа күрә бөек ханнарның явызлык, рәхимсезлек һәм мәкерлелек кебек сыйфатлары алгы планга чыга. Шул ук вакытта автор әлеге хөкемдарларның күпчелеге идарә иткән чорда бердәм дәүләт төзелү, фән, мәгариф, мәдәният, һөнәрчелекнең үсүе, ислам диненең ныгуы, шәһәрләр төзелү, төрле территорияләрнең берләшүе кебек күренешләрне дә игътибарсыз калдырмый.

Ханнарның гаилә әгъзалары, балалары белән мөнәсәбәтләрен, мәхәббәт тарихларын тасвирлаган вакыйгалар артында трилогиянең төп фикере дә югалып калмый, Бөек империяне – чәчәк аткан Алтын Урда дәүләтен булдырган ханнарның җимерүчеләр түгел, ә төзүчеләр булуы аңлашыла. Тарихи роман авторы буларак, И. Есенберлин тарихи чыганакларга һәм тарихи белешмәләргә таяна. Тарихи хакыйкать идеологик постулатлардан көчлерәк булып чыга.

Трилогия башында бирелгән Алты башлы Айдахар турындагы хикәя романнарда бәян ителәчәк вакыйгалардан хәбәр бирә. Үзәкләштерелгән хакимият булмау, рус кенәзлекләренең таркаулыгы, алар арасындагы канкойгыч бәрелешләр бу зур территорияләрнең яулап алынуында гына түгел, соңрак та хәлиткеч роль уйный. Русь кенәзлекләре арасында көрәш туктаганчы, аерылган территорияләр берләшкәнче, алар Урда ханнары кулы астында калган. Шул рәвешле, Алты башлы Айдахар бердәмлекнең булмавын символлаштыра.

И. Есенберлинның бердәмлек мотивына тукталуы очраклы түгел. Бер яктан бу сюжет Чыңгыз хан турындагы риваять-легендаларга да керә.

Әлеге риваять-легендаларда бердәмлек һәм тугрылык идеяләре беренче планга чыга, төп кыйммәт булып санала. Бердәмлек мотивы

легендар Алан-гуа образы белән бәйле риваятьтән үк башлана һәм Чыңгыз хан образы урын алган һәр легенда-риваятьтә кызыл җеп булып сузыла. «Юань-чао би-ши» әсәрендә, ягъни «Монголларның яшерен тарихы»нда Алан-гуаның улларын бердәмлеккә чакыруы, үгет бирүе тасвирлана: «Һәм бервакыт яз көне сап-сары итеп сакларга дип какланган бәрән пешерде, улларын янәшә утыртты, ... һәм һәрберсенә сындырыр өчен берәр чыбык бирде. Тегеләр берәр чыбыкны бик җиңел генә сындырдылар. Ул аларга яңадан сындырыр өчен бергә бәйләнгән бишәр чыбык бирде. Бишесе дә бергәләп алып, учларына кысып, сындырырга тырыштылар. Шулай да сындыра алмадылар. Шуннан соң Алан-гуа улларына болай дип үгет бирде: «Сез бишегез дә минем бер карынымнан тудыгыз һәм сез әлеге биш чыбык кебек. Әгәр һәрберегез үзегез өчен генә гамәл кылса һәм эшләсә, әлеге биш чыбык кебек, сез теләсә кем тарафыннан җиңел генә сындырылырсыз. Әгәр бәйләнгән биш чыбык кебек бердәм һәм дус булсагыз, кемгә булса да, җиңел генә табыш булырсызмы?» [Козин, § 19–22]. Бердәмлек идеясен күтәргән әлеге сюжет татар халкында да борынгыдан ук мәгълүм һәм хәзерге вакытка кадәр популяр. Җәләлетдин Ата-Мәлик Җүвәйни бу сюжетны Чыңгыз ханның үзенә бәйле вакыйга буларак бәян итә. Чыңгыз хан улларын янына җыеп, алар алдында садактан бер ук алып сындыра, аннары ике ук ала, аларны да сындыра. Шулай итеп, ул алган саен берәр укка күбрәк ала башлый һәм кулында баһадирлар да сындыра алмаслык ук бәйләме җыела. Шуннан соң улларына түбәндәге үгетне бирә: «Йомшак ук башка уклар белән бергә генә ныгый, хәтта көчле сугышчылар да аны сындыра алмыйлар. Сез дә, бер-берегезгә булышканда, берегез икенчегезгә ярдәм иткәндә, дошманнарыгыз нинди генә көчле, куәтле булсалар да, сезне җиңә алмаслар» [Джувейни, с. 29].

Җүвәйни версиясендә риваятьнең дәвамы да бар. Чыңгыз хан исән-имин булыр өчен бердәмлекнең генә җитмәвен, ә киңәшләре белән дөрес юл сайларга ярдәм итүче, кирәкле күрсәтмәләрен бирүче, ягъни бердәмлекне тәэмин итүче юлбашчы кирәк булуын күрсәтә. Юлбашчысы булмаган халык күп башлы еланга тиң, ди ул. «Бервакыт төнлә бик каты салкын була. Еланның башлары, суыктан качып, өнгә керергә телиләр, әмма бер-берсенә комачаулап, берсе дә керә алмый, барысы да катып үлә. Ә башы бер генә булган елан өнгә керә, аның бөтен гәүдәсе-койрыгына да урын табыла [Джувейни, с. 29].

И. Есенберлин үзенең трилогиясенә лейтмотив итеп алган бердәмлек идеясен шушы легендага таянып уздыра. Әсәрнең дәвамында тема башка яктан ачыла.

Чыңгыз хан да үзе төзегән бөек империянең бердәмлек булмау аркасында юкка чыгуыннан бик нык курка. Каты куллы, харизмага ия, нык үзәкле хөкемдар тәхеттә утырганда, Алтын Урда гөрләп чәчәк ату чорын кичерә. Алтын Урда тәхетенең Чыңгыз нәселеннән булган варислары арасындагы шул ук таркаулык, үзара дошманлык һәм тәхет өчен көрәш, ахыр чиктә, дәүләтнең дә таркалуына китерә.

Шушы ук бердәмлек мотивына В. Ян да кат-кат мөрәҗәгать итә. Бу яктан авторларның фикерләре аерылмый. Трилогия авторлары таркаулык, бердәмлек булмау мәсьәләсенә берничә тапкыр әйләнеп кайталар. Рус кенәзләренең үзара дошманлашуы, туктаусыз һөҗүмнәре Руська монгол яуларыннан да артык зыян китерә. Монголларны бөтенләй күрмәгән, аларга турыдан-туры кагылышы булмаган рус халкы, үз кенәзләре аркасында, күбрәк иза чигә.

В. Ян бу турыдагы фикерен үзенең геройларыннан әйттерә. Мәсәлән, рус ратникларының диалогында монголларны түгел, ә үз кенәзләрен гаепләү сизелә: «Греясь у костра, ратники говорили:

– Хорошо, что наконец Великий князь Владимирский отбросил свое долгое раздумье!

– Он теперь самый сильный из князей, пора ему встать во главе русского войска. Давно надо было так поступить, при первом слухе о татарах!.. Он сам тогда оплошал, не поддержал рязанцев…

– Теперь время упущено, сколько русских людей напрасно полегло!..

– Всем миром надобно подняться на лютого врага, только тогда одолеем его…

– Эх, из-за княжеской розни, ссоры да которы гибнет русская земля!..» [Ян, Батый, с. 324].

«Батый» романындагы икенче геройның сүзләре дә алдагы фикерне куәтли. Гади халык монголлардан гына түгел, Русьның үз эчендәге яулардан да нык зыян күргән:

«Князья промеж себя не поладили: сидеть ли во Владимире князю Георгию Всеволодовичу или его родному брату Константину Ростовскому? Брат на брата с ножом полез. Каин Авеля хотел зарубить. Заставили братья за себя биться простых мужиков. Нам-то не все ли равно, какой брат будет сидеть на нашей спине: Константин или Георгий? Так князья мужиков не пожалели, и покатились глупые крестьянские головы! О татарах тогда и не слыхивали, а братья резались хуже татар» [Ян, Батый, с. 250].

В. Ян бу очракта тарихи дөреслекне – халыкның монголлардан да, үз кенәзләреннән дә күп газап күрүен бәян итә. В. Ян трилогиясе турында сүз барганда, чор вазгыятен истә тотып, автор бу әсәрен башкача яза да алмас иде, дигән фикер туа. Ул, әлбәттә, монгол басып алучыларның вәхшилеген дә күп тасвирлый. Әмма вәхшилек күренеше ул чор басып алу сугышларының теләсә кайсысы өчен хас күренеш булуын да онытырга ярамый.

Шулай итеп, Алтын Урда барлыкка килгәч тә, Русьтагы тынычлык үзара дошманлашып кына калмаган, бәлки монголлар ярдәмендә бер-берсен яулап алган, бер-берсен юк итәргә әзер торган кенәзләрнең сәясәтенә һәм дипломатиясенә бәйле булып чыга. Алар, үз мәнфәгатьләрен генә истә тотып, ханнарга ярарга омтылганда, туган халкын корбан итәргә дә әзер булалар. Һәрберсенең төп максаты – кенәзлек итү өчен хан ярлыгын алу була. Бу турыда В.О. Ключевский: «XIII и

XIV века были порой всеобщего упадка на Руси, временем узких чувств и мелких интересов, мелких, ничтожных характеров. Люди замыкались в кругу своих частных интересов и выходили оттуда только для того, чтобы попользоваться за счет других», – дип яза [Ключевский, с. 51–62].

Бераз соңрак яулап алучылар белән буйсындырылган халыклар арасында чагыштырмача тыныч мөнәсәбәтләр урнаша. Русь бу вакытта ныгый һәм киләчәктә басып алучыларга каршы көрәшү өчен көч туплый. Рус кенәзләренең сәяси һәм икътисади хәле турында кайгыртуны исә Алтын Урда ханнары үз өстенә ала. Мәсәлән, Үзбәк хан яулап алынган җирләрдә тынычлык саклауны да үзенең бурычы саный. Тынычлык булганда гына яулап алынган халыклар иген игә, һөнәрчелек белән шөгыльләнә, шәһәрләр сала ала.

XIV гасырда Алтын Урда белән талантлы дәүләт эшлеклеләре идарә итә, дәүләт бөтен яктан зур үсешкә ирешә. Үзбәк хан исә бүтәннәрдән талантлы оештыручы, хөкемдар булуы белән аерылып тора, Ул идарә иткәндә Алтын Урда алгарыш кичерә, үзара яу-ызгышлар туктатыла.

И. Есенберлинның трилогиясендә беренче планга көчле харизмага ия булган хөкемдар образы чыга. Аның башкаларның омтылышларын һәм гамәлләрен тиешле максатка юнәлдерә алуы сәяси политогенезның асылын тәшкил итә [Лобин, с. 105].

«Алтын Урда» трилогиясендә вакыйгалар Бату хан дәверен тасвирлау белән башлана һәм алга таба аның балалары, оныклары, тәхеткә килергә омтылган чыңгызыйлар белән бәйләнештә дәвер вакыйгаларына күзәтү ясала. Ягъни бу вакытта Чыңгыз хан дөнья куйган була инде. Әмма әсәрдәге образга һәм вакыйгага Чыңгыз хан күзаллавы аша бәя бирелә. Чыңгыз хан образы оныклары Бату һәм Бәркә ханнарның хәтере һәм истәлекләре аша тудырыла. Ханнар үзләренең һәр гамәлен бөек бабаларының эшчәнлеге белән чагыштырып, аларның Чыңгыз хан кануннарына ни дәрәҗәдә туры килүе турында уйланалар. Чыңгыз ханның иң элек Бөек империяне ныгытуга юнәлтелгән законнары һәм васыятьләре хан оныкларына үз максатларын, юнәлешләрен билгеләргә ярдәм итә. Мәсәлән, Бату хан үзенең улына бабасы Чыңгыз ханның киңәшләрен тотып яшәве турында сөйли: «Бабай кайчагында миңа киңәшләрен бирә иде. Аларның өчесе, якты йолдыз булып, тормыш дигән төн караңгысында минем юлымны яктырттылар. Канлы, дәһшәтле яулар вакытында Чыңгыз хан киңәшләре минем йөрәгемне җылытты, ышаныч һәм көч бирде» [Есенберлин, с. 14].

Әлеге трилогияләрдә Чыңгыз ханның тормышка мөнәсәбәте, дөньяны күзаллавы аның кануннары – Яса аша тасвирлана. Чыңгызыйларның да, аның варисларының да гамәлләре шушы кануннарга бәйле рәвештә бәяләнә: «Чыңгыз хан кушканча», «Чыңгыз хан кануннары буенча», «Чыңгыз ханның сүзләре шундый иде», «Чыңгыз хан васыятьләрендә әйтелгәнчә». И. Есенберлин, башка ханнарга карата

ачыктан-ачык уңай фикер әйтә алмаса да, Чыңгыз хан трилогиядә зирәклек символы булып ачыла, бөек стратег образы тудырыла.

Монгол яулары, һичшиксез, кырыс, рәхимсез һәм канкойгыч булган. В. Ян трилогиясендә Чыңгыз хан образы да, Бату хан да бары шушы канкойгыч яуларның башында торган ерткыч табигатьле ханнар булып ачыла. Төгәлрәге, трилогиядә ике образ да үлем символы буларак күрсәтелә, алар катнашындагы һәр эпизод бу шәхесләрнең ерткычлыгын раслауга хезмәт итә.

Чыңгыз хан хөкемдар гына түгел, тере кеше дә. Картлыктан курку, кече улына булган сентименталь мәхәббәте дә аңа гади кешелек сыйфатлары ят түгеллеген күрсәтә. Хан «Монгол явы» трилогиясендә бөек һәм куркыныч кеше буларак ачыла. В. Ян аның бөеклеген тирә-юньдәгеләргә, бөтен халыкка һәм кешелеккә карата кылган вәхшилеге аша ача.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, һәр автор Алтын Урданы һәм әлеге заман вакыйгаларын, тарихи шәхесләр образларын үз чоры идеологиясен истә тотып сурәтли. В. Ян шәхес культы елларында иҗат ителгән һәм басылып чыккан «Монгол явы» трилогиясендә бу образларны һәм вакыйгаларны башкача сурәтли дә алмас иде. Автор Алтын Урда ханнары образы аша, юк ителгән авыл-шәһәрләр, халык, мәкер һәм икейөзлелек кебек сыйфатлар турында язганда, «шәхес культы» еллары вәхшилекләрен дә истә тотмадымы икән, дигән сорау туа. И. Есенберлин «Алтын Урда» трилогиясен совет чорының соңгы елларында иҗат итә. Әмма бу вакытта да совет идеологиясе, ул кабул иткән постулатлар көчле була әле. Шулай да, И. Есенберлин, Алтын Урданың бердәм, гөрләп чәчәк аткан зур дәүләт булуын да, ханнарның пассионар табигатен дә, харизмасын, шул ук вакытта аларның еш кына шәфкатьлелек, кешелеклелек кебек сыйфатлардан ерак булуын да күрсәтә.

**Әдәбият**

loannis Dlugossii senioris canonic. Cracoviensis opera. T. 14. Cracoviae. 1878, 697 p.

*Джувейни Ата-Мелик.* Чингизхан. История завоевателя мира, записанная Ала-ад-Дином Ата-Мелик Джувейни / Перевод с текста Мирзы Мухаммеда Казниви на английский язык Дж.Э. Бойла. С предисловием и библиографией Дэвида О. Моргана. Пер. с анг. Е.Е. Харитоновой. М.: Магистр-Пресс, 2004. 690 с.

*Есенберлин И.* Золотая Орда. Роман-трилогия. Шестиглавый Айдахар. Шесть голов Айдахара. Гибель Айдахара. Алматы: ТОО «Издательство Книжный клуб, 2021. 620 с.

Казанская история / Подгот. текста, вступ. ст. и примеч.: Г.Н. Моисеева. М.; Л.: Изд. АН СССР, 1954. 195 с.

*Ключевский В.О.* Курс русской истории. Соч. в 8 т. Т. 2. М., 1957. 468 с.

*Козин С.А.* Сокровеное сказание. Монгольская хроника 1240 г. под названием Mongjol-un nijuca tobciyan Юань чао би ши. Монгольский обыденный изборник / Институт востоковедения АН СССР. – М.-Л : Изд-во АН СССР, 1941. Т. I: Введение в изучение памятника, перевод, тексты, глоссарии. 618 с.

*Лобин А.М.* Концепции истории и формы их художественной репрезентации в русской литературе начала XXI века: дис. … д-ра филол. наук. Саратов, 2018. 399 с.

*Карамзин Н.М.* История государства Российского. Т. IV. СПб.: Издательство: Тип. Н. Греча. 1819. 556 с.

*Фюре Франсуа.* Прошлое одной иллюзии. М.: Ad Marginem, 1998. 640 с.

*Ян В.Г.* Чингис-хан. Батый. К последнему морю. Исторический роман: в 3-х книгах. Элиста: Джангар, 1993. 320 с. + 318с. + 384с.

*Публикация статьи осуществлена в рамках выполнения научно-исследовательского проекта AP0 9261068 «Идея государственности и концепция исторической личности эпохи Золотой Орды в контексте художественной литературы»*

*Мәкалә «Әдәбият контекстында Алтын Урда чорының дәүләтчелек идеясе һәм тарихи шәхесе концепциясе» AP0 9261068 фәнни-тикшеренү проектын үтәү кысаларында әзерләнде*

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

***Даутова Сауле Баттал кызы,***
*филология фәннәре докторы, Казакъ милли педагогия университеты профессоры*

УДК 82.091

***М.М. Хәбетдинова***

# ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ӘДӘБИЯТЛАРЫНДА ГАЗАП ЧИГҮЧЕ ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЛАРЫ

В сфере нашего научного интереса находится изучение функционирования женского образа в произведениях современной татарской и башкирской литератур, посвященных насильственной христианизации мусульман Урала и Поволжья. Материалом для исследования послужили трагедия Р. Зайдуллы «Үлеп яратты» (2005), художественно-документальный роман «Баһадиршаһ» (2006), исторический роман «Гөләйза» (2018) Ф. Байрамовой, рассказ М. Буракаевой «Кисәкбикә» (2006), повесть С. Абузара «Кисәнбикә юлы» (2018), пьеса М. Башкирова «Киҫәкбикә. Риүәйәт» («Сказ о Кисякбике)» (2021). В рамках исследования выявлена специфика внешних и внутренних характеристик образов мучениц за веру, роль художественной детали в раскрытии портретных характеристик, внутреннего мира и др. Доказано, что татарские и башкирские писатели опираются на традиции фольклора (идеал преданной супруги и заботливой матери) и просветительской литературы (идеал женщины-матери нации). Воссоздавая исторический фон, они акцентируют внимание на противостоянии имперской власти с татарами и башкирами-инородцами. Характерная черта – описание героизма женщины, оставшейся без поддержки мужа. Чаще всего образы мучениц разрешены в романтическом ключе, чтобы подчеркнуть недолжное состояние мира, несправедливость власти к народу. Писатели подчеркивают связь женских образов с мусульманской этикой, сами женские образы выступают образцами благочестивости. В произведениях доминируют тексты молитв, цитат из Корана. Размышляя о предназначении человека, героини придерживаются мусульманской антропологии. Писатели воспевают подвиг и самопожертвование героинь во имя веры.

**Ключевые слова:** политика насильственной христианизации, мученичество в исламе, мученица за веру, татарская литература, башкирская литература.

In the sphere of our scientific interest is the study of the functioning of the female image in the works of modern Tatar and Bashkir literature devoted to the forced Christianization of Muslims of the Urals and the Volga region. The material for the study was the tragedy of R. Zaidulla «Immortal Love» (2005), the fiction and documentary novel «Bahadirshah» (2006), the story of M. Burakayeva «Kisyakbike» (2006), historical novels by F. Bayramova's «Exodus» (2017), «Gulyayza» (2018), S. Abuzar's novel «The Way of Kisyanbike» (2018), M. Bashkirov's play «Kiәakbik. Riuyet (The Tale of Kisyakbik)». The study revealed the specifics of the external and internal characteristics of the image of martyrs for the faith, the role of artistic detail in revealing portrait characteristics, inner world, etc. Developing the image of a martyr for the faith Tatar and Bashkir writers rely on the traditions of folklore (the ideal of a devoted spouse and caring mother) and educational literature (the ideal of a woman-the mother of the nation). They recreate the historical background, focusing on the confrontation of the imperial power with the Tatars-foreigners. A characteristic feature is the description of the heroism of a woman left without the support of

her husband. Most often the images of martyrs are resolved in a romantic way to emphasize the improper state of the present, the injustice of the authorities to the people. The writers emphasize the connection of female images with Muslim ethics, the female images themselves are models of piety. The texts of prayers and quotations from the Koran dominate in the works. Reflecting on the destiny of man the heroines adhere to Muslim anthropology. Writers glorify the heroism and self-sacrifice of heroines for faith.

**Keywords:** policy of forced Christianization, martyrdom in Islam, martyr for the faith, Tatar literature, Bashkir literature.

Идел буе һәм Урал мөселманнарын көчләп чукындыру, Рус Православие чиркәвенең миссионерлык эшчәнлеге формалары, XVIII гасырның соңгы утыз еллыгы – XX гасыр башында дини агарту эшләренең эволюциясе темалары хәзерге вакытта тарихчылар тарафыннан җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелгән (А. Хрусталев [Хрусталев], Н. Руновский [Руновский], Ф. Ислаев [Ислаев], Р. Исхаков [Исхаков], Д. Макаров [Макаров], К. Харлампович [Харлампович] һ.б.).

Бу темалар язучыларның да игътибарын җәлеп иткән (Г. Исхакыйның «Зөләйха» трагедиясе (1912) [Исхакый], М. Галәүнең «Болганчык еллар» (1930), «Мөһаҗирләр» (1934) дилогиясе [Галяу], Р. Зәйдулланың «Үлеп яратты» (2005) трагедиясе [Зәйдулла], Ф. Бәйрәмованың «Баһадиршаһ» (2006) художестволы-документаль романы [Бәйрәмова, 2006], М. Буракаеваның «Кисәкбикә» хикәясе (2006) [Бураҡаева], Ф. Бәйрәмованың «Һиҗрәт» (2017) [Бәйрәмова, 2017], «Гөләйза» (2018) [Бәйрәмова, 2018] тарихи романнары, С. Әбүзәрнең «Кисәнбикә юлы» повесте (2018) [Әбүзәр], М. Башкировның «Киҫәкбикә. Риүәйәт» пьесасы (2021) [Башкиров] һ.б.).

Барлык монотеистик диннәрнең уртак бер ягы бар. Ул – газап чигү элементы. Ислам динендә газап чигүчеләр шәһитләр дип атала. Ватанын, илен яклап, көрәштә гаепсезгә вафат булганнар да шәһитләр исемлегенә керә. Ил өчен кан коеп вафат булу оҗмахка кертә торган гамәл буларак кабул ителә. Исламда газап чигү концепциясе христиан диненә караганда киңрәк. Ислам динендә газап чиккән беренче хатын-кыз булып Мөхәммәд пәйгамбәрнең алты көрәштәшенең берсенең әнисе Сөмәйя бине Хәят санала, аны дошманнары ерткычларча җәзалап үтерәләр. Мөхәммәд пәйгамбәр тарафыннан Мәккәгә җибәрелгән өч вәкил дә иманнарыннан ваз кичмичә башларын сала (тулырак карагыз: [Большаков]). Исламда газап чигүче культы җиһад (хак дин, ягъни ислам дине өчен көрәш) концепциясе белән тыгыз бәйләнгән. Мөселманнар өчен Кербельдәге фаҗига чын мәгънәсендә тетрәнү була, анда Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Хөсәен һәм аның улларының каны коела (680 ел). Өммәвиләр хакимлеге вакытында бу газап чигүчеләрне яшертен генә искә ала торган булсалар, 750 елдан соң, искә алу чаралары зурлап үткәрелә башлый. Шигыйларда газап чигүчеләр культы шулай формалаша. Рус сәүдәгәре А. Котов әлеге йоланы үзенең «Хожение»сында язып калдыра. Ул дөя өстендә шәрә

килеш («койрыкка таба йөз белән карап») утырып йөргән кешеләрне күреп шакката. Ул кешеләр урам буйлап бәрхеткә төрелгән, бакыр һәм кургаш белән бизәлгән «табут» алып баралар, үзләрен үзләре җәзалыйлар (Тулырак карагыз: [Котов]). XVIII гасыр урталарыннан «газап чигүчеләр турындагы кыйссалар» уку традициясе (Тазийе) үсеш ала. Гарәп (Әбү Михнаф. «Китабу Мактал-и Хөсәен»; Исфахани. «Макатилу'т-Талибин»), фарсы (Хөсәен Ваизи Кәшифи. «Равзату'ш-Шухада»), төрек (Чәләби. «Мактал-и Ал-и Рәсүл»; Госман Кәмал Әфәнде. «Мәрсия Имам-и Хөсәен»; Фөзули «Хадикату'ш-Шуеда») әдәбиятларында, Хөсәеннең үлеменә багышлап, мәрсия жанры формалаша. Татарларда үзенең тамырлары белән әрвахлар рухына табыну культына барып тоташкан изгеләр культы билгеле. Ул беренче ислам миссионерларының каберләрен зиярәт итүдә чагыла («Сәхабәләр кабере», «Изгеләр кабере», «Ялгыз кабер», «Әүлия кабере») [Дәүләтшин, б. 55]. Татар бәетләрендә болгар кызларының, Сөембикә-ханбикәнең, дәүләтчелекне югалту фаҗигалары мәңгеләштерелгән.

Татар әдәбияты гыйлемендә көчләп чукындыру темасының сәнгати рецепциясе үзенчәлеген чагылдырган хезмәтләр шактый ([Akhmetzyanova, Zakirzyanov, Sheyanova, Motigullina; Заһидуллина; Faezova, Khabutdinova, Gaynyllina; Каскинова, Хадыева; Khabutdinova, Zamalieva, Motigullina; Миннуллина; Насипов, Хабутдинова; Хайруллина; Мусин; Хабутдинова; Хәбетдинова] h.б.). Безнең тикшеренүнең яңалыгы – XXI гасырда татар һәм башкорт әдәбиятларында иман өчен газап чиккән хатын-кыз образларын өйрәнүдә. Тикшеренү материалы – Р. Зәйдулланың «Үлеп яратты» пьесасы (2005) [Зәйдулла], Ф. Бәйрәмованың «Баһадиршаһ» художестволы документаль романы (2006) [Бәйрәмова, 2006], М. Буракаеваның «Кисәкбикә» хикәясе (2006) [Буракаева], Ф. Бәйрәмованың «Гөләйза» тарихи романы [Бәйрәмова, 2018], С. Әбүзәрнең «Кисәнбикә юлы» повесте (2018) [Әбүзәр], М. Башкировның «Киҫәкбикә. Риүәйәт» пьесасы (2021) [Башкиров].

Г. Исхакый «Зөләйха» драмасында [Исхакый] патша хөкүмәтенең рус булмаган халыкларга карата колониаль сәясәтен фаш итә. Татар милләте язмышындагы әлеге драматик чор ире Сәлимҗаннан һәм балаларыннан мәҗбүри рәвештә аерып алынган, монастырьда көчләп чукындырылган, исерек рус иренә кияүгә бирелгән татар хатыны Зөләйха язмышы аша күрсәтелә. Татар язучысы үзенең драмасында шул чорда яшәгән татарларның рухи халәтен күрсәтеп биргән. Персонажларның сүзләрендә тулы бер халык фаҗигасы чагыла: иманына тугрылык саклаган өчен Әхмәдине, Куян авылыннан хәзрәтне Себергә сөрәләр, Миңнисаны рус кешесенә сатып җибәрәләр, Садрины төрмәгә ябалар. Өметсезлеккә бирелгән татарлар патша һәм хәлифәдән (Фәхретдин белән Әхмәтҗан диалогын карагыз) яклау эзли. Драма пространствосында персонажларның иман турында фикер алышулары күп урын ала. Хәзрәт мәхәллә лидеры буларак бирелә, ул мәхәллә әгъзаларын үзенең вәгазьләре белән ныклы рухлы

булырга өнди. Персонажлар системасында антитеза өстенлек итә: хәзрәт – поп, Зөләйха – Пётр, халык – становой, поп, сакчылар исеменнән хакимият. Героиняның динилеге аның догалардан, Аллаһка сыгынудан гыйбарәт булган монологларында, диндәшләре белән диалогларында ачыла. Г. Исхакый мөселман хатынының рус гаиләсендә мәсхәрәләнүләрен җентекләп сурәтли. Пётр «татар этенә» өйләнергә ризалыгын попның архиерейдан «бүләк» вәгъдә итүе белән аңлата. Гаиләдәге дини каршылык Зөләйханың Пётрны үтерүе белән чишелә, хатын бу җинаяте өчен егерме елга сөргенгә озатыла. Финалда газап чиккән хатын иманы хакына вафат була, аны фәрештәләр үз канаты астына ала. (Бу әсәр татар әдәбиятчылары тарафыннан нык өйрәнелде. Г. Исхакыйның библиографиясен карагыз [Заһидуллин]).

Р. Зәйдулланың «Үлеп яратты» (2005) [Зәйдулла] драмасында 1937 елда мәгърифәтче татар хатын-кызы, кызлар мәдрәсәсенә нигез салган Мөхлисә Бубиның (1869–1937) үлеме тасвирлана. Ул «Мөселманнарның Үзәк Диния нәзарәте эше» кысаларында Үзәк Диния нәзарәтенең казые буларак кулга алына һәм хөкем ителә. Ф. Миңнуллина фикеренчә, «драманың үзәк темасы шуннан гыйбарәт: иман адәм баласына рух ныклыгына ирешергә ярдәм итә. Мөхлисә ханым Аллаһка ышанырга өнди, иманда үзенә көч таба. Аның яшәү белән үлем арасындагы халәтен тасвирлаганда, максаты милләтне, аның көчле һәм иң аңлы лидерларын юк итү булган явызлык дөньясының моделе торгызыла» [Миннуллина, с. 99]. Әдәбият белгечләре пьесаның тарихи нигезен, сюжет үзенчәлекләрен, социаль конфликтның үзенчәлеген өйрәнделәр: шәхес – тоталитар хакимият, М. Буби фаҗигасын һәм батырлыгын ачканда, символик, метафорик детальләрнең потенциалын ачыкладылар [Akhmetzyanova, Zakirzyanov, Sheyanova, Motigullina].

Р. Зәйдулла пьесасында иман өчен газап чиккән хатын-кыз образының үзенчәлекләре галимнәр игътибарыннан читтә калган. Татар хатын-кызының милли идеалын эзләгәндә, драматург XIX–XX гасырлар чигендә татар әдәбиятында формалашкан милләт анасының мәгърифәтчелек идеаллары белән тыгыз бәйләнгән фидакярлек һәм милләткә хезмәт итү темасына мөрәҗәгать итә. Сюжет традицион мәдәни-тарихи баганаларның шәхси рухи тәҗрибә белән бәрелешенә нигезләнә. Сиксәненче еллар язучысы Р. Зәйдуллага антиномик фикерләү рәвеше хас. Тоталитар хакимият вәкилләренең рухи таркалу процессы иман өчен батырлык кылган хатын-кызның тирән кичерешләре җирлегендә күрсәтелә. Трагедиядә төп урынны иман белән имансызлыкның драматик каршылыгы алып тора. Мотив һәм образлар Аллаһка иман китерү идеясенә берләштерелә.

Трагедиянең лирик доминантасы баш героиняның үз кызы һәм асрамага алган кызлары турында кайгыртучан ана буларак кичерешләре белән бәйле. Мәгърифәтче үзен газаплаучылар турында да аналарча кайгыртучанлык күрсәтеп, алардан өстен күтәрелә. Сүз һәм кул хәрәкәтләре арасындагы бәйләнеш трагедиядә характерны ача торган мөһим деталь булып тора. Баш героинясы образының бөтенлеген

тәэмин итү өчен, Р. Зәйдулла аларның эчке бәйләнешен ассызыклый. М. Буби язмышына ышана, Аллаһ аның ныклыгын кыенлыклар аша сыный дип саный, шуңа да зарланмый, сукранмый. Аның әйткән сүзләрендә һәм монологларында вәгазьләү һәм мәгърифәтчелек рухы өстенлек итә. М. Буби татар халкын мәгърифәтле итү өчен шәхси тормышын корбан итә, үзенең ышануларын яклап, төрмәдә һәлак була.

Драматург бинар оппозицияләргә мөрәҗәгать итә. Мөхлисә үзе азатлыкны гәүдәләндерә. Аңа каршы «коллар» тора: Корбанов, Дәүләтов һәм башка чекистлар кыяфәтле дәүләт системасы шөрепләре. Р. Зәйдулла трагедиядә рухи хыянәт феноменын тикшерә. М. Буби хатирәләренә таянып, трагедиядә 1911 елның гыйнварында Иж-Бубыйдагы ирләр мәдрәсәсен тар-мар итү (бераз соңрак хатын-кызлар мәдрәсә-училищесы да ябыла) белән 1930 еллардагы репрессияләр арасында эчке бәйләнеш ачыклана (империя – татарлар).

Героиняның холкын ачыкларга сөйләм стихиясе ярдәм итә. М. Буби сүзен уйлап әйтә, әңгәмәдәшләрен бүлдерми, үпкәләтердәй сүзләр әйтми, һәркем белән, социаль статусына карамыйча, ихтирамлы мөнәсәбәттә сөйләшә. Аның сөйләмендә Аллаһка мөрәҗәгатьләр, догалар мулдан урын ала. М. Буби үзенең дошманнарын иманлы һәм юаш сүзе белән акылга китерергә тырыша.

Трагедиядә иман хакына корбан итү мотивы психологик интерпретациягә ия. Газап чигүче хатын образының лирик өлеше дога кылганда, Аллаһ белән аралашканда, аның хаҗ кылу турындагы хыялларында чагылыш таба. Мәгърифәтчегә, динилеге белән бергә кушылганлыктан, вакыйгаларның метафизик мәгънәсе ачыла. М. Буби Россия империясенең дә, СССР хакимиятенең дә бөтен гөнаһларын күреп тора. Тышкы драматик конфликт – иман белән имансызлыкның бәрелеше – М. Буби образында психологик гәүдәләнеш таба, аның иман хакына газап чигүче хатын-кыз булуы холкының драматик доминантасын ассызыклый. Трагедиядә мәгърифәтченең үз халкын үлемсез ярату белән яратуына һәм үз-үзен корбан итәргә әзер булуына басым ясала. Аллаһка ышану пьесада гармониягә илтүче башлангыч булып тора.

Трагедиядә иман хакына газап чигеп һәлак булу турындагы сюжетның үстерелешендә җырлар зур роль уйный. Намаз вакытында фәрештәләрнең җырлавы М. Буби образын сакральләштерүгә хезмәт итә. Аның 1919 елда кызылармияче кулыннан һәлак ителгән кызы Миңнемөнҗиянең җырына канатлары белән илне сакларга тырышучы аккош образына әверелгән ак яулык метафорик образы килеп керә. Дини дискурста мөһим рольне мөнәҗәт жанрындагы җырлар уйный, алар ай яктылыгы (иман нуры) һәм караңгылык (явызлык), әл-видаг (хатын-кызлар мәдрәсәсендә укучы кызларның хушлашу җыры) антитезасына нигезләнә. Бу җырлар белән Гражданнар сугышының гаепсез корбаны Миңнемөнҗиянең җыры арасында бәйләнеш күзәтелә. Соңгы ике җырда автор аучы һәм шамакай образлары аша тоталитар системаның «шөрепләре»ннән, аларның төпсезлеген-

нән әче көлә, алар үзләренең тормышын зинданга әйләндергән, ди. Аллаһны, кавемен мәңгегә яратуы аркасында, М. Буби хәтта төрмәдә дә ирекле булып кала.

2006 елда Ф. Бәйрәмова көчләп чукындыру темасына «Баһадиршаһ» дигән художестволы-документаль романын бастырып чыгарды. Биредә иман өчен газап чигүче ролендә Россия империясенең колониаль сәясәтенә каршы күтәрелгән Татар-Башкорт фетнәсенең идеологы һәм башлыгы Батырша хәзрәт сурәтләнә (тулырак карагыз: [Бәйрәмова, 2005; Батырша җитәкчелегендәге баш күтәрү...; Батырша, 1993; Заһидуллина, б. 171–172]). Фетнәне бастыргач, ул Шлиссельбург төрмәсенә эләгә, шунда императрица Елизавета Петровнага мөрәҗәгать итеп, үзенең данлыклы «Тахриз-намә»сен яза: «...Әгәр дә без бер патшаның анты астында яшибез икән, һәм әгәр дә ул падишаһ үзенең антына һәрдаим тугрылык саклый икән, ул чагында без, шәригать кушканча һәм безнең изге Китапта язылганча, үзебезнең башыбыз һәм гомеребез белән корбан китерергә тиешле. Әгәр дә патша үзенең подданныйларын кыерстыулардан яклау буенча вазифаларын үтәүне тәэмин итми, әгәр дә бурычлар туктаусыз үзгәреп тора һәм аларга яңалары өстәлә икән, мөселманнар берләшергә һәм шәригать кушканча иманны югары күтәрергә тырышу турында дин кардәшләренә ярдәм итәргә тиеш...» [Батырша, б. 93–94]. Әлеге документ татар һәм башкорт әдәбиятларында иман өчен газап чигүче образының әдәби традицияләрен формалаштыру өчен нигез булып тора. Ф. Бәйрәмова үзенең романында Екатеринбургта мәйданда тереләй яндырылган татар Тойгелде Җүләковның батырлыгына дан җырлый (тулырак карагыз: [Анисимов, с. 542–543]). Ф. Бәйрәмова романында Батыршаның шәкертләр белән бергә кулга алынган хатыны Зөлхәбирә образы аерым игътибарга лаек. Башта ул Уфада зинданга ябыла, аннан соң Санкт-Петербург төрмәсенә озатыла. Газаплы сорау алулардан соң, хөкем карары чыгарыла: мөселман диненә кайту мөмкинлеге калдырмаслык итеп, балалары белән бергә «Кызлар монастырена» ябарга. Роман авторы Зөлхәбирә образы Г. Исхакыйның Зөләйхасы белән янәшә хатын-кыз образлары галереясында лаеклы урын алырга тиеш дип саный [Бәйрәмова, 2006].

2008 елда Ф. Бәйрәмова «Утта яндырылган татар хатыны» дигән мәкалә яза, анда ул көчләп чукындыру сәясәтенең корбаны булган Кисәнбикә/Хөснибикә Байрасованың биографиясен торгыза [Бәйрәмова, 2008, Утта яндырылган...]. Архив документлары белән эшләгәндә, татар тарихчысы рәсми документларда әлеге хатын-кызның татар дип теркәлүенә игътибар итә, ләкин соңрак документларга үзгәрешләр кертелә һәм ул башкорт дип йөртелә башлый. Ф. Бәйрәмова Кисәнбикәнең туган җире, аны көчләп чукындыру, качуы турындагы материалларны системага сала. Мәкаләсендә тикшеренүче архив документларыннан өзекләр китерә. Мәсәлән, хөкем карарында мондый юллар бар: «Пойманную татань-башкирку, которая была крещена и дано ей имя Катерина, за три побега и что она, оставя Закон

Христианский, обасурманилась, за оное извольте приказать на страх другим казнить смертию – сжечь, дабы впредь, на то смотря, другие казнились» [ГАСО. Ф. 24. Оп. 1. Д. 818. С. 243–245]. Кисәнбикә Байрасова фаҗигалы рәвештә 1739 елның 30 апрелендә һәлак була [Бәйрәмова, 2008, Туран иле, б. 114–118].

Ф. Бәйрәмова «Гөләйза» романында да шулай ук иман хакына газап чиккән хатын-кыз батырлыгына дан җырлый. Г. Хисамиев Кыр Шонталысы (хәзерге Алексеевский районы) авылында туып үскән бу хатын-кыз Г. Исхакыйның Зөләйха образының прототибы булган дип раслый [Хисамиев]. Ф. Бәйрәмова әсәрне иҗат иткәндә, бер яклап, татар тарихындагы «ак таплар»ны бетерергә, мөселманнарның иман хакына кылган батырлыкларын мәңгеләштерергә, икенче яклап, тарихның фаҗигалы чорларында иманын, телен һәм халык буларак үз йөзен саклап калган ата-бабаларыбызны олыларга омтылуын белдерә. Героиня үлеменең хәл-шартларын ачыклап, язучы Чистай өязен, бер гаиләнең портретын тасвирлау белән генә чикләнми, ә бөтен бер ил-империядә яшәүче мөселман халыкларын көчләп чукындыру фаҗигасын ачып бирә. Колониаль изү шартларында илдә динны унификацияләүгә ирешү өчен хакимият тарафыннан күрелгән чараларның кырыслыгына язучы аерым игътибар бирә. Романда татарларның иман мәсьәләләрендә ни дәрәҗәдә ныклык күрсәтүләре хакында мисаллар китерелә: «алар бозлы суга батып, тереләй утта янып үләләр иде» [Бәйрәмова, 2018, б. 12], рус авылларына сөргенгә җибәрелә, көчләп христианнарга кияүгә бирелә һ.б. Намаз укучылар бары бер Аллаһка өмет баглый: «аларның таянычы – бары тик Аллаһ кына» [Бәйрәмова, 2018, б. 13]. Геройларның хатирәләре аша көчләп чукындыру сәясәте романда динамикада ачыла. Сюжет 1838 елгы вакыйгалардан башланып китә. «Вакыйгаларның вакыты Николай I патша булган елларга, Екатерина II дин иреге хакында игълан иткәннән соң күпләп исламга кайта башлаган керәшен татарларны кабат православие динендә ныгыту өчен алып барылган канлы һәм күз яшьле каршылык көннәренә алып китсә дә, анда Казан ханлыгы егылганнан соң мөселманнарга каршы җәелдерелгән чукындыру сәясәте турында сүз бара, географиясе ягыннан да, гомумән, татарлар яшәгән һәм сөйләшүләр вакытында да, хикәяләүченеке булган лирик, фәлсәфи, тарихи, күбрәк сызланулы чигешләрдә дә калкып чыга» [Заһидуллина, б. 179].

Р. Зәйдулла кебек үк Ф. Бәйрәмова антиномик фикерләү рәвешенә өстенлек бирә. Персонажлар системасында татар-мөселманнар – попларга, урядникларга; мөселман Гөләйза – керәшен Нәчтүккә (Нәгыймә), мөселман гаиләсе – керәшен гаиләсенә, мөселман авылы Кыр Шонталысы – керәшен авылы Актауга каршы куела. Д. Заһидуллина күзәтүенчә, «Ф. Бәйрәмованың мөселман һәм православие каршылыгының бер ягында торучыларга гына түгел, капма-каршы персонажларга карата психологизм алымнары куллануы шулай ук вакыйгаларны төгәлрәк аңларга ядәм итә» [Заһидуллина, б. 180]. Язу-

чы роман текстына татарлар патшага юллаган үтенеч язуларын да кертеп җибәрә.

Романда номинативлар мөһим роль уйный. Романда героиняның «Минем исемем Гөләйза!» дигән репликасы рефрен булып кабатланып килә. Баш героиняның күз алдына ата-бабалары килә, алар: «Исемеңне онытырга юл куйма, иманыңа хыянәт итмә!» – дип мөрәҗәгать итә [Бәйрәмова, 2018, б. 48].

Романдагы артефактларның да мәгънәви вазифасы бар. Мәсәлән, хөкем вакытында Гөләйза антын Библиядә түгел, ә Коръәндә бирүне хуп күрә. Ант иткәндә, ул үзенең дини генә түгел, ә милли тәңгәллеген дә ассызыклый: «Кулымны Коръәнгә куеп әйтәм: мин – мөселман хатыны! Минем исемем Гөләйза! Мин Пелагея түгел, рус хатыны түгел, мин – татар хатыны» [Бәйрәмова, 2018, б. 56]. Судта ул үзен вәкарь белән тота, аның җаваплары да уйланган, һәр сүзен ашыкмыйча әйтә.

Ф. Бәйрәмова, суд эпизодын язганда, Чистайның мөселман образын өяз хөкемдары ноктасыннан торып сурәтли. Язучы татар-мишәрләрне берләштергән көч – диндә бердәмлек булу турында уйлана. Ф. Бәйрәмова аларның дөньяга карашлары формалашуда суфичылыкның ролен ассызыклый.

Персонажлар системасында дин әһелләренә мөһим роль бирелә, алар халык массаларына дога сүзе, вәгазьләр (Моратбакый абзыйның Болгар белән Биләр шәһәрләрен мөселман диненең үзәге буларак торгызу турындагы вәгазе) мөрәҗәгать итә һ.б. [Бәйрәмова, 2018, б. 85–87]. Берләштерүче көч буларак, мөселманнарның йола-гадәтләре, аерым алганда, Ураза, Корбан гаетләре зур роль уйный.

Икенче өлештә татарлар һәм рус авылына әйләндерелгән Биләрнең побы арасындагы каршылык әһәмияткә ия. Бу исә роман авторына татарларны көчләп чукындыруны, татар дәүләтчелеге тарихын җентекләп сурәтләргә мөмкинлек бирә. Романның композициясендә билгеле бер симметрия күзәтелә. Икенче өлештә укучы Ишмөхәммәт Уразманов морзаның судтагы каршылыгын күзәтә. Төрмәдәге эпизодлар колониаль сәясәт аркасында интегеп яшәгән татар халкының коллектив портретын тудырырга ярдәм итә. Роман авторы аерым шәхесләр язмышын тулы бер халык язмышына үреп бирергә омтыла. Ф. Бәйрәмова мөселман диненә кайту өчен үзләрендә көрәшерлек көч, кыюлык тапкан татарларга дан җырлый. Прозаикның игътибар үзәгенә 1827–1864 еллар арасындагы чор алына. Язучы төгәл саннар белән эш итәргә тырыша. Мәсәлән, Чистай тирәсендә андый мөселманнарның саны өч меңнән артып китә.

Өченче өлештә Ф. Бәйрәмова Гөләйзаны иман хакына газап чигүче хатын-кыз итеп сурәтли. Әлеге образ приставның Гөләйзаны кыйнау эпизоды аша драмалаштырыла. Ф. Бәйрәмова укучысын героиняның күрәзәле төшләре аша сюжетның фаҗигалы чишелешенә әзерли. Гөләйзаны хөкем итү картинасы империя тарафыннан татарларга карата мөнәсәбәтнең гаделсезлегенә иллюстрация буларак кабул ителә:

мөселман хатынын яклап әйтелгән утыз күрсәтмә попның бер чыгышы белән сызып ташлана. Сюжетта христиан һәм мөселман диннәре арасындагы каршылык героиняның фаҗигалы үлеме белән генә бетми әле: аны нинди йола буенча күмү турындагы бәхәсләр мәхәлләне тагын бер тетрәндереп ала.

Романны йомгаклап, Ф. Бәйрәмова Гөләйзаның якыннарының ничек эзәрлекләнүе турында кыскача мәгълүматлар бирә: сорау алулар, йөзгә-йөз очраштырып сорау алулар, янау-куркытулар. Дәүләт системасы муллага да, попка да төрмә җәзасы бирә. Героиняның балаларын керәшеннәр гаиләсенә тәрбиягә бирәләр. Чистай морзалары Ишмөхәммәт морзаны яклап, аны төрмәдән азат итүгә ирешәләр.

Әкълимә әбинең дисбесе көчләп чукындыру сәясәте корбаны булган төрле буын татар-мөселманнарның бердәмлек символы булып тора. Финалда дисбе образлары үзләренең дини ышануларын яклап һәлак булган меңнәрчә татар кешеләре турындагы хәтерне саклаган йолдызлыкка әверелә. Шәһитләр, үз динен саклап һәлак булган газап чигүче кешеләр темасы шул рәвешле дә ачыла.

Шулай итеп, төп героиняның тәрҗемәи хәлен иман хакына газап чигүче итеп тасвирлап, Ф. Бәйрәмова игътибарны татар халкы тарихыннан якынча мәгълүматларга юнәлтә: бу җирләргә болгар татарларның килеп урнашуы, татарларның ислам динен кабул итүе, дәүләтчелек югалту фаҗигасы, көчләп чукындыру сәясәте. Язучы мисаллар нигезендә Гөләйза гаиләсенең берничә буын дәвамында мөселман диненә тугрылыгын күрсәтә. Героиняның биографиясен язып, Ф. Бәйрәмова аның мәгърифәтчелеккә, мөселман дине йолаларын үтәргә омтылуын раслаган фактлар китерә. Әсәрдә көчләп чукындыру сәясәтенең идеологлары һәм аны гамәлгә ашыручылар белән каршылык тәфсилләп сурәтләнә.

Шәхси һәм социаль конфликтны колониаль яссылыкта күрсәткән хөкем итү эпизодлары мөһим роль уйный. Героиня мөселман диненә тугрылыгын саклый, христиан дине йолаларын үтәүдән баш тарта. Аннан соң җәзалау, үлем һәм үлгәннән соң чынбарлыкта аңлатып була торган могҗиза: дин кардәшләре Гөләйзаны мөселман йолалары буенча җирли, шуңа да поплар кабердә аның җәсәден тапмыйлар. Иман өчен газап чигүче белән аны газаплаучылар арасындагы мөнәсәбәтләр суд, газаплы үлем эпизодлары аша күрсәтелә. Ф. Бәйрәмованың газап чигүче герое язмыш сынауларын ныклык белән үтә, чөнки ул мөселман динендә үзенә таяныч таба. Д. Заһидуллина фикеренчә, «язучы гап-гади бер татар хатынының, балаларын, динен, милли асылын саклап, көрәшчегә әйләнү юлын тергезә» [Заһидуллина, б. 181].

2018 елда Кисәкбикә батырлыгына үзенең «Кисәнбикә юлы» дигән повестенда Салават Әбүзәр дан җырлый [Әбүзәр]. Башкорт әдәбияты белгечләре повестька М. Буракаева хикәясе белән чагыштырып анализ ясаган (тулырак карагыз: [Каскинова, Хадыева]).

2021 елда Михаил Башкиров, Мәрьям Буракаева хикәясенә нигезләнеп, «Киҫәкбикә. Риүәйәт» пьесасын яза. Иман өчен газап

чигүче образын сурәтләгәндә, драматург французларның 1920 елда изгеләр рәтенә кертелгән героинясы Жанна д'Арк белән параллельләр үткәрә. М. Башкиров шәхеснең – мохит, «бәләкәй кеше»нең империя белән каршылыгына мөрәҗәгать итә. Франция образы клавесин музыкасы, сарай дамаларының париклары, костюмнары аша ирелә. Боларның барысы да безгә XI–XII гасырларда Көнбатыш Европаның мөселман һәм православие динендәгеләргә каршы хәрби тәре походлары ясаган христиан дөньясы образын хәтерләтә. Әлеге походлар яулап алынган территорияләрне колонияләштерү белән тәмамлана. Бу исә драматургка, төбәк тематикасы чикләреннән чыгып, күләмле империя – колония антитезасын тудыру мөмкинлеге бирә.

Безгә милли рухы көчле булган герой турындагы традицион романтик әсәр тәкъдим ителә. Сөйләк башлангычы әкиятче хатын образы аша гамәлгә ашырыла, аның тавышы билгеле бер вакытка бәйләнмәгән, ул халык хәтерен, халыкның рухи кыйммәтләрен гәүдәләндерә. Аның авызыннан без кайчандыр бу җирдә хөкем сөргән идиллия, әле бик ерак үткәндә булмаган «алтын гасыр» турында ишетеп беләбез. Башкорт халкының яшәеше бүреләр нәселеннән булган гаилә образы аша күрсәтелә.

Спектакльнең баш герое рус романтик әдәбиятының иң яхшы традицияләрендә «әсир» итеп бирелә: гадәти булмаган герой гадәти булмаган шартларга куела. Без геройның мохит белән каршылыгын күрәбез. Романтизмның әлеге сыйфатлары күпләргә мәктәп программасыннан ук таныш (А.С. Пушкинның «Кавказ әсире», М.Ю. Лермонтовның «Кавказ мәхбүсе», Байронның «Шильон мәхбүсе» әсәрләре).

Драматург әсирлек мәдәни кодын һәм башкортларның ирек сөюче халык булуы турындагы эстетик идеалын уңышлы куллана. Алгы планга балаларына нәсел традицияләре турындагы хәтерне кайтаручы, туган илгә мәхәббәт һәм аның язмышына карата җаваплылык хисе тәрбияләүче милләт анасының мәгърифәтчелек идеалы чыгарыла. «Курку», «куркак», «курыкма» рефреннары бөтен текст буйлап кабатланып бара.

Колониаль теманы күтәргәндә, драматург рус сатирасының иң яхшы традицияләренә мөрәҗәгать итә (М.Е. Салтыков-Щедринның «Ташкентлы әфәнделәр» очеркларын искә төшерегез). Империянең «вариссыз калган пространство»сы картинасын тудырганда, ул карнавал эстетикасын уңышлы куллана. 1720 елларда башкорт җирләрендә заводлар төзелеше өчен уңайлы урыннар эзләгән Василий Татищев Петербургтан килгән яшерен киңәшченең прообразы булып тора. Аның бөтен тормышы – йә югары вазифалар биләү, йә булмаса казематлар дәрәҗәсенә мәтәлү. Халыкта аңа Тать – юлбасар дигән кушамат тагалар. Ул үзенең рәхимсезлеге һәм чиста куллы булмавы белән дан тота.

Кисәкбикә шәхесе явызлык башлангычын гәүдәләндергән яшерен киңәшче образы белән каршылыкта ачыла. Ул геройларның күңеленә коткы, вәсвәсә сала, аларның рухи ныклыгын сыный.

Кисәкбикәнең балалары, язмыш кушуы буенча яшерен киңәшчегә тәрбиягә бирелеп, үз-үзләренә хыянәт итәләр, исемнәрен югалталар. Халык эпик традицияләре кысаларында драматург «үзе турында сөйләүче исем» алымын куллана. Туганда бүре ыруы вәкилләре балаларына яңгырашлы исемнәр бирә торган була. Сынбулат исеме – «тимер кебек ныклы булсын», Акчура – «үз-үзен корбан итәргә сәләтле» дигәнне аңлата. Нәдерша гарәп телендә «кыйммәтле, сирәк очрый торган» дигән мәгънәгә ия. Пансионатта аларга яңа исемнәр бирәләр, димәк ки, төрки гадәт буенча аларның язмышын күчереп язалар. Шулай итеп, Сынбулат туган җирен дә, әнисен дә сатарга әзер вак сәүдәгәр Василийга әйләнә. Акчура исә – күңеле рәхимсезлек һәм комсызлыктан таш булып каткан күзәтүче Пётрга. Нәдерша Иван исемен ала, сугыш кырыннан куркып качкан яугир була. Исемнәрен югалтуга алар үзләренең тәңгәллеген, нәселләре белән элемтәләрен өзәләр.

Жанр кануннарына ярашлы, бу көрәштән Кисәкбикә җиңүче булып чыга. Ул явызлыкка каршы торып, үз-үзенә тугрылык саклый, чөнки анда нәсел-ыруының хәтере исән. Ул милләттәшләрендә дә шушы хәтерне уятырга тырыша: «Нәрсә булды сезнең белән, халкым минем, сез кемгә әйләндегез?», «Сез – рухы азат кешеләр, сездән өстә бары Аллаһ кына», «Азатлык булмагач, яшәүнең нигә кирәге бар?».

Балалары белән булган сәхнәләрдә Кисәкбикә кайгыртучан ана буларак ачыла, киңәшче белән көрәштә – кыю, горур хатын-кыз. Шәрехләгәндә, корбанчылык идеясенең әйдәүче икәнлеге ачыклана. Ялкын әсирлек тышауларын яндыра. Кисәкбикәнең үлеме аның тормышының иң югары ноктасы булып аңлашыла. Бу образ спектакльдә ике планда чишелеш таба: иман өчен газап чигүче хатын-кыз һәм милләт анасы. Дини дискурста спектакльнең авторлары Аллаһ кануннарыннан язган икейөзле хакимиятне фаш итәр өчен фарс алымына мөрәҗәгать итә. Менә ни өчен сарай тирәсенә елышкан кешеләр марионеткаларны һәм кәмитчеләрне хәтерләтә.

Милләт анасы дини-мистик планда шәрехләнә. Кисәкбикә – туган җиргә мәхәббәтнең гәүдәләнеше. Ул – А. Горькийның үз үлеме белән киләчәк буыннарга юл күрсәткән Данкосының башкорт варианты.

Хәзерге заман татар һәм башкорт әдәбиятларында иман хакына газап чиккән хатын-кыз образларын анализлап, без шундый нәтиҗәгә килдек: язучылар әлеге темага үзләренең милли-эстетик идеалын, дәвер җилләренә каршы тора алырдай, гадәти булмаган язмышлы героен эзләп мөрәҗәгать итә. Әдәбиятның төрле төрләренә караган әлеге әсәрләр төрле жанрларда язылган. Сюжет күп яклап охшаш: иман хакына газап чигүче шәхесе аның мохит һәм хакимияткә каршылыгында ачыла. Фаҗигалы үлеме аша аның образы сакральләштерелә. Язучылар халыкка милли идеал турында искә төшерә алырдай милләт анасы образын куллана. Иман хакына газап чигүче милләт образы язучыларга милли тарихтагы «ак таплар»ны бетерү, тарихи материалның олы бер катламын күтәрү мөмкинлеге бирә. Геройларының эчке дөньясын сурәтләгәндә, язучылар игътибарны геройларның диниле-

генә һәм тәкъва булып яшәү рәвешенә юнәлтә. Романтик рухлы әлеге әсәрләрдә героиняларның ныклыгына, иман, милләт өчен үз-үзләрен корбан итәргә сәләтле булуларына дан җырлана.

**Әдәбият**

*Анисимов Е.В.* Дыба и кнут: политический сыск и русское общество в XVIII веке. М.: Новое литературное обозрение, 1999. 719 с.

*Әбүзәр С.* Кисәнбикә юлы. Уфа: [б. и.], 2019. 105 б.

*Башкиров М.* «Киҫәкбикә. Риүәйәт» («Сказ о Кисякбике») (2021) // URL: https://www.youtube.com/watch?v=rDMxirRJrqo (мөрәҗәгать итү датасы: 28.09.2021).

Батырша. Письмо Батырши императрице Елизавете Петровне. Уфа: УНЦ РАН, 1993. 252 с.

Батырша җитәкчелегендәге баш күтәрү һәм XVIII йөз татар җәмгыятендә иҗтимагый-мәдәни торыш. Фәнни-гамәли конференция материаллары (2005 елның 17 мае, Казан шәһәре). Казан: ТФАнең Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2007. 368 б.

*Бәйрәмова Ф. Ә.* Баһадиршаһ. Казан: «Аяз» нәшр., 2006. 303 с.

*Бәйрәмова Ф. Ә.* Батырша җитәкчелегендә милли-азатлык көрәше. Яр Чаллы: «Аяз» нәшр., 2005. 64 б.

*Бәйрәмова Ф.* Гөләйза. Казан: «Аяз» нәшр., 2018. 312 б.

*Бәйрәмова Ф.* Ә. Һиҗрәт. Казан: «Аяз» нәшр., 2017. 480 б.

*Бәйрәмова Ф.Ә.* Туран иле. Казан: «Аяз» нәшр., 2008. 335 б.

*Бәйрәмова Ф. Ә.* «Утта яндырылган татар хатыны» // Мәдәни җомга. 2008. 30 май (№ 21). 18 б.

*Большаков О.Г.* История Халифата. Т. I. Ислам в Аравии. 570–633. М.: Наука, 1989. 310 с.

*Бураҡаева, М.С.* Көҙгө ысыҡ: хикәйәләр. Өфө: Инеш, 2011. 182 б.

*Галяу М.* Муть. Мухаджиры. Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. 460 с.

*Дәүләтшин Г.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Тат. кит. нәшр., 1999. 512 б.

*Заһидуллин А.* Библиография // Гаяз Исхакый: тарихи-документаль җыентык. Казан: Җыен, 2011. Б. 739–915.

*Заһидуллина Д.Ф.* Фәүзия Бәйрәмова // Татар әдәбияты: 8 томда. 8 т. Казан: Фолиант, 2021. Б. 151–184.

*Зәйдулла Р.* Саташкан сандугач. Пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 487 б.

*Ислаев Ф.Г.* Ислам и православие в Поволжье XVIII столетия: от конфронтации к терпимости. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2001. 214 с.

*Исхаков Р.Р.* Очерки истории традиционной культуры и религиозности татар-кряшен (XIX – начало XX вв.). Казань: Изд-во «Центр инновационных технологий», 2014. 332 с.

*Исхакый Г.* Зөләйха. Казан: [б. и.], 2019. 98 б.

*Каскинова Г.Н., Хадыева И.А.* Башкорт әдәбиятында Кисәкбикә образы // Проблемы гуманитарных наук и образования в современном мире: Сборник научных статей по материалам V Всероссийской научно-практической конференции (21–22 марта 2019 г.) / под. ред.: Р.М. Латыповой, Н.А. Ласыновой. Сибай: Сибайский информационный центр – филиал ГУП РБ Издательский дом «Республика Башкортостан», 2019. С. 83–84.

*Котов Ф. А.* Хожение купца Федота Котова в Персию. М.: Изд-во вост. лит., 1958. 111 с.

*Макаров Д.М.* Самодержавие и христианизация народов Среднего Поволжья (XVI–XVIII вв.). Чебоксары: [б.и.], 2000. 272 с.

*Миннуллина Ф.Х.* Жанр драмы в татарской драматургии рубежа XX–XXI веков. Казань: ИЯЛИ, 2019. 144 с.

*Мусин Ф.* Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр, 1998. 199 с.

*Насипов И., Хабутдинова М.* Религиозный дискурс в повести А. Йылдырым «Бегущие к свету» и романе Ф. Байрамовой «Һиҗрәт» («Исход») // Филология и культура. Philology and Culture. 2021. № 3. С. 128–133.

*Руновский Н.* Очерк истории христианского просвещения инородцев Волжско Камского края в связи с историей переводов на их языки до половины XIX столетия // Симбирские епархиальные ведомости. 1901. № 2. С. 49–57; № 4. С. 128–135; № 7. С. 237–243; № 10. С. 337–345; № 11. С. 383–392; № 12. С. 417–423.

*Хайруллина Д. М.* Образ женщины в русской и татарской литературе 1890–1917 годов: На примере творчества Г. Исхаки и М. Горького: дис. ... канд. филол. наук: 10.01.02. Уфа, 2005. 222 с.

*Хәбетдинова М.М.* Ф. Бәйрәмованың «Һиҗрәт» (2017) романында татар эмиграциясе темасы / М.М. Хәбетдинова // Фәнни Татарстан. 2019. № 2. Б. 35–45.

*Хабутдинова М.М.* Кисекбике // Звезда Поволжья. 2021. № 48. С. 1, 4.

*Харлампович К.В.* Казанские новокрещенские школы: (К истории христианизации инородцев Казан. епархии в XVIII в.): [Доложено в общ. собр. О-ва археологии, истории и этнографии 28 апр. 1903 г.]. Казань: типо-лит. Имп. ун-та, 1905. 91 с.

*Хисамиев Г.* Гөләйза кыйссасы. Фәнни-популяр басма. Казан: Отечество, 2015. 286 б.

*Хрусталев А.* Очерк распространения христианства между иноверцами Казанского края / Миссионерский противомусульманский сборник: Тр. студентов Миссион. противомусульм. отд-ния при Казан. духов. акад. Вып. 5 / Соч. студента Казан. духов. акад. 3 учеб. курса (1845–1850 гг.) Александра Хрусталева. Казань: Унив. тип., 1897. 105 с.

*Akhmetzyanova G., Zakirzyanov A., Sheyanova S., Motigullina A.*, «Presentation of historical personalities in modern tatar literature (on the basis of r. Zaidulla's plays)», Turkish Online Journal of Design and Communication, April 2017, DOI NO: 10.7456/1070ASE/119

*Khabutdinova M.M., Zamalieva L. F., Motigullina A.R.* Ideological and Artistic Originality of Monodrama «Mikulaj» (2019) by Mansour Gilyzov // Materials of the International Conference «Scientific research of the SCO countries: synergy and integration» – Reports in English (July 31, 2019. Beijing, PRC)Beijing, China 2019, p.105–111.

*Faezova L.R., Khabutdinova M. M., Gaynyllina G.R.* The Emigration Theme In Tatar Literature // Modern Journal of Language Teaching Methods. 2018. Vol. 8, Is. 9. P. 66–71.

***Хәбетдинова Миләүшә Мөхәммәтҗан кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*

УДК 82.09

***Л.Ш. Галиева***

# ФӘИЗ ЗӨЛКАРНӘЙ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Статья представляет собой обзор трудов литературного критика и поэта Фаиза Зулькарная (1951–1997), в которых он высказывается о литературной критике, ее функциях, об истории татарской литературной критики. Будучи сторонником критики в жанре эссе, Ф. Зулькарнай размышляет о роли критика в литературе, о взаимоотношениях писателя, критика и читателя, пропагандирует творчество татарских поэтов-новаторов, предлагает свое видение развития татарской литературной критики.

**Ключевые слова:** Фаиз Зулькарнай, татарская литература, литературная критика, эссеистика, образ критика.

The article is a review of the works of the literary critic and poet Faiz Zulkarnay (1951–1997), in which he speaks about literary criticism, its functions, and the history of Tatar literary criticism. Being a supporter of criticism in the essay genre F. Zulkarnay reflects on the role of a critic in literature, on the relationship between a writer, critic and reader, promotes the work of innovative Tatar poets, offers his vision of the development of Tatar literary criticism.

**Keywords:** Faiz Zulkarnay, Tatar literature, literary criticism, essay, the image of a critic.

Әдәбият дөньясына бәйләнеше булган һәр каләм тибрәтүче әлеге өлкәгә караган төшенчә, терминнар белән эш итә, аларның асылы турында уйлана. Билгеле, бу юнәлештә аның үз фикер-карашлары туа, күзәтүләре барлыкка килә, һәм ул аларны укучысы белән бүлешергә ашыга. Узган гасырның 80–90 нчы елларында татар әдәбияты мәйданында актив эшчәнлек алып барган тәнкыйтьче, шагыйрь, публицист, әдәбият белгече Фәиз Зөлкарнәй (1951–1997) – әдәбият, шигърият, иҗат, тәнкыйть һ.б. хакындагы уйланулары белән татар әдәбияты тарихында лаеклы урын алган шәхесләребезнең берсе. Ул әдәбиятка 1970 еллар ахырында килә. Аның беренче әдәби тәнкыйть әсәре – шагыйрь Р. Фәйзуллинның иҗат портреты – 1977 елда «Идел» альманахында дөнья күрә. Шуннан бирле Ф. Зөлкарнәйнең яшь һәм урта буын шагыйрьләр иҗаты, хәзерге прозаның, тәнкыйтьнең торышына багышланган мәкалә, эссе һәм рецензияләре «Идел» әдәби альманахында, «Идел», «Казан утлары» журналларында даими рәвештә басылып торган. Әдипнең тәнкыйди һәм публицистик язмалары, шигырь теориясенә багышланган эзләнүләре дүрт китапта – «Кешем, асылың кем?» (1984), «Әверелеш» (1988), «Чакма чакмый ут чыкмый» (1991), «Күләгә күбәләге» (2001) – һәм күпсанлы мәкаләләрендә урын алган. Әлеге мәкалә кысаларында әдипнең әдәби тәнкыйтькә карата туган кайбер фикерләренә күзәтү ясала.

Әдәбият галиме Флүн Мусин: «Тәнкыйтьне стиль ягыннан яңартуга 70 нче елларда әдәбиятка килгән тәнкыйтьчеләрдән Мансур Вәлиев, Ринат Мөхәммәдиев, Салих Маннапов, Әхмәт Сәхапов, Фәиз Зөлкарнәев һәм башкалар аеруча зур игътибар бирделәр», – дип белдерә [Мусин, б. 479]. Мансур Вәлиев әлеге тәнкыйтьчеләр иҗатында «...җанлы итеп, хис белән язу омтылышы»ның хәтта тулы бер юнәлеш төсен алуын билгели [Вәлиев, б. 200]. Язучы һәм шагыйрь Марат Закир исә әдәби тәнкыйтьне эссе жанрына тарту, аны нәфис әдәбиятка әверелдерү омтылышы иң элек Ф. Зөлкарнәй тарафыннан эшләнә, дигән фикердә тора [Закир, б. 179]. «Эссеистик тәнкыйть»кә өстенлек бирүе хакында Ф. Зөлкарнәй үзе дә язып чыга: «80 нче елларда әдәби тәнкыйть, жанр буларак, Көнбатыш әдәбиятлары үрнәгендә эссе жанрына тартылу кичергән иде. Аны нәфис әдәбият төренә әйләндерергә омтылу иде бу. Мин үзем шул юнәлештә эшләдем. С. Маннапов шундый әсәрләрдән гыйбарәт бер-ике китап чыгарды. Наис Гамбәр шуның кызыклы мисалларын бирде. Кызганыч, бу омтылышлар ул чакта әдәби күренеш буларак ныгып, канунлашып бетә алмадылар. Ләкин ничек кенә булмасын, киләчәктә бу юнәлеш әдәби тәнкыйть үсешенең төп тармакларыннан булыр дип ышанам мин, аны язучылар үзләре эшләргә мәҗбүр булачаклар. Икенче шундый тармак академик өслүбтәге тәнкыйть булып, анысын әдәбиятчы галимнәр үстерәчәк» [Зөлкарнәй, 2000, б. 128]. Тәнкыйтьченең «Өлешеңә тигән көмешең», «Милли гамь ярында уйланулар» дигән хезмәтләре – эссе жанрының асыл үрнәкләре.

Әдипнең барлык фикерләре аның «эссеистик тәнкыйть» тарафдары булуын раслап тора. Мисал өчен, аның «Чакма чакмый ут чыкмый» китабында урын алган «Сүз шатлыгы» исеме белән бирелгән парчаларына игътибарны юнәлтик. Бирелә Ф. Зөлкарнәйнең тәнкыйть төшенчәсенә биргән аңлатмасы белән танышу мөһим. Аның күзаллавында «тәнкыйть – әдәбиятның үзаңы ул» [Зөлкарнәй, 1991, б. 138]. Ф. Зөлкарнәй әлеге зур вазифаны нинди дә булса аерым тәнкыйтьче генә яки тәнкыйтьчеләр төркеме генә башкарып чыга алмый, дип саный. Әдәби тәнкыйть дигән күренешне, тәнкыйтьчеләрдән тыш, әдип фикеренчә, язучы, шагыйрьләрнең әйткән, язган фикерләре дә, гади укучылар тарафыннан җиткерелгән сүзләр дә тәшкил итә.

Ф. Зөлкарнәй үзенең хезмәтләрендә әдәби тәнкыйтьнең ике вазифасын аерып чыгара: 1) ул әдәби әсәрне укучыга аңлата, шәрехли; 2) поэтик һәм социологик анализ нәтиҗәләренә таянып, әсәрләргә эстетик һәм идеологик бәя бирә. Шул ук вакытта, тәнкыйтьче фикеренчә, тәнкыйть укучы өчен ориентир гына булып тора, ул хөкем карары түгел. «Ягъни ул, бер яктан, матур әдәбиятка бәйле, аңа өстәмә кебегрәк; икенче яктан, ул – матур әдәбиятның үз-үзен камилләштерү инструменты, аның үзаңы» [Зөлкарнәй, 1991, б. 140]. Билгеле бер дәрәҗәдә идеаль, ягъни «журналистлык шаукымыннан, конъюнктура зәхмәтеннән азат булган» тәнкыйть турында уйланып, Ф. Зөлкарнәй аны чын мәгънәсендә интеллектуаль жанр, дип саный [Зөлкарнәй, 1991, б. 144]. Ләкин әлеге интеллектуаль жанр, тәнкыйтьче фикеренчә,

«неблагодарный» хезмәт, әдәбиятның «кара эше», «кәсеп тә була алмый торган, хобби булырга да бик җайсыз нәрсә» – намус, абруй эше дә. Һәм менә шушы намус эшен башкаручы тәнкыйтьченең әдәбияттагы роле хакында уйланып, Ф. Зөлкарнәй аның казый, хөкемдар вазифасын башкармавын ассызыклый, тәнкыйтьчене судья урынына күрүгә каршы чыга [Зөлкарнәй, 1991, б. 138]. Матур әдәбият турында язган каләм әһелләренә ул хөрмәт белән карый, аларның хезмәтен фидакярләр эшенә тиңли: «Турысын әйтик, әдәби тәнкыйть – бүгенге көндә фидаиләр эше, Газинур Гафиятуллин кебек амбразура капларга сәләтле каләм ияләре генә тәнкыйть яза хәзер» [Зөлкарнәй, 1994, б 166]. Тәнкыйтьчене соңгы елларда әлеге авыр хезмәткә алынган каләм әһелләренең кимүе дә борчый. Мәсәлән, 1994 елда язылган «Фидаиләр эше» дигән мәкаләсендә Ф. Зөлкарнәй соңгы биш елда басылып чыккан әдәби тәнкыйть һәм әдәбият тарихына караган китапларны барлый. Әлеге исемлеккә ул ун хезмәтне, тугыз автор-тәнкыйтьчене кертә. Әлбәттә, тәнкыйтьче, китапка караганда, көндәлек матбугат битләрендә дөнья күргән әдәби тәнкыйть мәкаләләрен кирәклерәк саный. Шулай да, ул китап булып басылып чыккан хезмәтләрнең исемнәрен аерым атап үтүне дә кирәк таба.

Әдәби тәнкыйтьтә Ф. Зөлкарнәй яңалык алып килүчеләрне хуплый, аларны яклап чыга: Равил Фәйзуллин, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Җәүдәт Сөләйманов һ.б. Яңача шигырь формасы, ритмикасы, традицион шигырьдәгегә охшамаган үзгә фикерләүне Ф. Зөлкарнәй сөенеп кабул итә, Рәдиф Гатауллин (Гаташ), Гәрәй Рәхим, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт, Эдуард Мостафин, Харрас Әюп, Марсель Галиев иҗатларына аерым мәкаләләр багышлап, тәфсилле анализ ясый, һәр шагыйрьне бер яки берничә сүз белән сыйфатлап бирергә тырыша. Әлеге шагыйрьләр иҗатын өйрәнеп, аны алга сөреп, Ф. Зөлкарнәй үзе дә әдәби тәнкыйтькә яңа калыплар кертә. Аяз Гыйләҗев һәм Рафаэль Мостафин фикерләрен үстерә төшеп, ул «Чакма чакмый ут чыкмый» дип исемләнгән үз әдәби бәхәсен тәкъдим итә. «Бездә бит язучы иҗаты, әсәрләре хакында берәр вакыйга яки дата уңае белән генә язу гадәткә кергән... чын тәнкыйтькә урын да калмый. Бездә хәзер әдәбияттагы күренешләр, аның сыйфатлары, проблемалары турында түгел, ә әдәбияттагы шәхесләр турында язу өстенлек итә. Иҗат портретлары, күзәтүләр (алар да күп чакта төрле әдипләрнең исемнәрен санап чыгудан узмыйлар) торышы хакында, аның эчке структур сыйфатлары хакында исә сүз сирәк әйтелә. Төп игътибар ул структураның аерым элементларына гына юнәлтелгән. Комплекслы күзаллау, колачлы анализ юк» [Зөлкарнәй, 1991, б. 58–59]. Әнә шундый нәтиҗәгә килеп, Ф. Зөлкарнәй әдәби тәнкыйть язмасының асылы турында да сүз йөртә. «Бүген генә түгел, теләсә кайсы заманнарда да яңача дип саналган әдәби тәнкыйть әсәрләренең көче исә бүтәндә: аларны катып калган фикер калыбы түгел, ә бәлки фикер үзе, җанлы, үз чикләрен үзе билгели торган ирекле фикер хәрәкәте бөтен итеп тота» [Зөлкарнәй, 1991, б. 143]. Әлеге «фикер хәрәкәте» бигрәк тә

тәнкыйтьченең шигырь парадоксларына багышланган «Әверелеш» дип исемләнгән хезмәтендә урын ала. «Максатка ни илтә?» мәкаләсендә Ф. Зөлкарнәй әдәби тәнкыйть талантлы язучының һәр яңа китабына, яңа сүзенә бәясен бирергә, талантлы каләм иясе бигрәк тә кыенлыклар, тынгысыз эзләнүләр кичергәндә дөрес юлны күрсәтергә тиешле, дип саный [Зөлкарнәй, 1984, б. 69]. Шуңа күрә, Ф. Зөлкарнәй әдәби тәнкыйтьчеләрне иң элек талантлар турында язарга чакыра. Аның уйлавынча, тәнкыйтьнең графоманнар белән көрәшүеннән бернинди файда да юк.

Язучы, тәнкыйтьче һәм укучының үзара мөнәсәбәтләре турында уйланганда, Ф. Зөлкарнәй аларның өчесен гомумиләштереп карарга тәкъдим итә: әдәбият (язучылар), тәнкыйть (тәнкыйтьчеләр) һәм җәмгыять (укучылар). Һәм менә шул ноктадан торып, ул аларның бер-берсенә тәэсир итүләре турында сүз йөртә.

Ф. Зөлкарнәйнең татар әдәби тәнкыйтенә карата әйтелгән фикерләре шактый кискен яңгырый. «Татар әдәби тәнкыйте электән дә инде, турысын әйтик, әллә ни куәт иясеннән булмады. Ул, вакыты белән, ачлык елда күтәрмәгә калган арык атны хәтерләтә иде хәтта. Хәзерге дуамал заманда аның өрлеккә бәйләп куйган арканнарын кисеп төшерүгә, ул идәнгә ишелеп төште. Әдәби тәнкыйтьне үлеп ята дисәк тә була. ...Эзлекле, ныкышмалы, киң колач белән иңләп бара торган әдәби тәнкыйть агымы юк хәзер. Рецензия жанры «Казан утлары» тырышлыгы аркасында гына юкка чыгып бетми әле. Әдәбиятны күзәтүләр, иҗат портретлары, проблемалы мәкаләләр аз, бик аз. Әдәби тәнкыйтьнең калган егермеләп жанры турында әйтеп тә тормыйм инде – юк алар» [Зөлкарнәй, 1994, б. 166]. Соңрак язылган мәкаләләренең берсендә әдәби тәнкыйтьне ул хәтта үлде, дип белдерә. Һәм шуңа бәйле татар әдәбиятында «уртакуллар баскынчаклыгына» юл ачыла, дип саный [Зөлкарнәй, 2001, б. 126–127]. Татар әдәби тәнкыйтенең мөшкел хәленә борчылып, әдип әлеге хәлдән чыгу юлларын да эзли сыман. Ф. Зөлкарнәй чын, эстетик таләпләр яктылыгында әдәбиятны анализлый торган әдәби тәнкыйть мәкаләләре шактый кимеде, дип исәпли. Аның фикеренчә, тәнкыйть бары тик үзара макташуга кайтып кала. «Чын әдәби тәнкыйть үлгәч, әдәбият мәйданында кайбер мәсьүли затларга хезмәт күрсәтү тәртибендә язылган язмалар гына торып калды шул. Боларны һәм язучыларның юбилейлары уңаеннан дөнья күргән язмаларны әдәби тәнкыйть дияргә тел бармый... Үзендәге яхшы, яман якларны даими ачыклап бармаса, үз бәясен үзе белмәсә, әдәбият яши алмый» [Зөлкарнәй, 1991, б. 144].

Язучы Ркаил Зәйдулла белдергәнчә: «Зөлкарнәй өчен иң беренче – милләт мәсьәләсе иде, әлбәттә» [Зәйдулла, б. 47]. Татар әдәбиятының төп милли үзенчәлекләрен ачыклау, яклау максатыннан язылган мәкаләләр, нигездә, Ф. Зөлкарнәйнең «Чакма чакмый ут чыкмый» җыентыгында урнаштырылган. Китапның беренче битләреннән үк тәнкыйтьченең калыплашкан фикер-сүзгә каршы килүе – протесты – сизелә: ул татар матбугатында еш телгә алынган «яңарыш»

атамасы белән килешми, яшьләр иҗатын кискен тәнкыйтьләүгә каршы чыга. Ф. Зөлкарнәй, конкрет мисалларга таянып, чордаш каләмдәшләрен дә тәнкыйтьли. Аерым алганда, ул М. Вәлиев, Р. Мостафинның кайбер фикерләре белән килешми. Ф. Зөлкарнәй тарихи гаделлек урнаштыру, әдәбиятның тулы канлы, табигый үсеше хакына бик күп каләм осталарының иҗатын яңабаштан карап чыгарга, элекке бәяләргә шактый төзәтмәләр кертергә кирәклек турында уйлана. Мисал өчен, ул производство, эшчеләр темасына багышланган өчен генә макталган, премияләргә лаек булган кайбер әсәрләр, озын-озын поэмалар турында «дәлилле хөкем сүзен» ишетәсенә өметләнә [Зөлкарнәй, 1991, б. 20–21].

Гомумән, Ф. Зөлкарнәйнең тәнкыйть мәсьәләләренә карата язып калдырган фикерләре шактый кызыклы, алар уйландыра. Үзенең тәнкыйди язмаларында Ф. Зөлкарнәй, иң беренче чиратта, нәкъ менә иҗатчы буларак сүз ала, һәм бу аның эссеистик тәнкыйтькә якынлыгын тагын бер кат исбатлый. Тәнкыйтьче өчен фикер сөреше, уйлар агышы мөһим. «Ф. Зөлкарнәй мәкаләләренең фәннилеге, фикри җегәре, фактик материалның байлыгы белән аерылып торуын да билгеләп үтү кирәк», – дип яза галим һәм тәнкыйтьче Әлфәт Закирҗанов [Закирҗанов, б. 255]. Чыннан да, Ф. Зөлкарнәйнең язмалары үз заманында да, соңрак чорда да югары бәяләнә. Бу исә, һич икеләнмичә, аның татар әдәбияты тарихында үз урыны булуы турында сөйли.

**Әдәбият**

*Вәлиев М.Х.* Күңелем кошы. Казан: Мәгариф, 2004. 220 б.

*Гайнанова Г.* Хушлашу // Идел. 2011. № 12. Б. 42.

*Закир М.* Игелек иясе // Казан утлары. 2011. № 12. Б. 178–179.

*Закирҗанов Ә.М.* Татар әдәбият белеме: традицияләр һәм үсеш тенденцияләре. Казан: ТӘһСИ, 2018. 352 б.

*Зәйдулла Р.* Аның турында // Идел. 2011. № 12. Б. 47.

*Зөлкарнәй Ф.* Кешем, асылың кем?: әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм парчалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 128 б.

*Зөлкарнәй Ф.* Сабыр төбе алтыным // Күләгә күбәләге: шигырьләр, әдәби тәнкыйть мәкаләләре, публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 160 б.

*Зөлкарнәй Ф.* Фидаиләр эше // Казан утлары. 1994. № 8. Б. 165–166.

*Зөлкарнәй Ф.* Чакма чакмый ут чыкмый. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 184 б.

*Куракова Ч.* Фәиз Зөлкарнәй тәнкыйтенең кайбер үзенчәлекләре // Төрки халыклар әдәбияты һәм сәнгате Шәрык һәм Гареб мәдәнияте контекстында: Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары җыентыгы (17–19 октябрь, 2013 ел) / Р.Р. Җамалетдинов редакциясендә. Казан: Отечество, 2013. Б. 190–192.

*Мусин Ф.* Әдәбият фәне һәм тәнкыйть // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда: 6 том: 60–90 еллар әдәбияты. Казан: Раннур, 2001. 544 б.

***Галиева Ләйсән Шәүкәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82.512.1 – 131

***Г.Р. Хөсәенова***

# ТАТАР РОМАНИК ДАСТАНЫ: ӘДӘБИ-СӘНГАТИ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ
## («Ләйлә белән Мәҗнүн» дастанының кулъязма варианты мисалында)

Статья посвящена исследованию некоторой художественной специфики дастанов романического характера в истории литературы и фольклора. На конкретном материале, хранящимся в архивных фондах ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ автор демонстрирует богатство дастанного письменного наследия татар; текстологически обрабатывает и анализирует художественно-выразительные средства одного из национальных вариантов «Лейли и Маджнуна». В статье выявляются качественные признаки жанра дастан, тесно связанные с этно-культурными традициями татарского народа, устанавливаются связи между эпическим фольклором и татарской литературой Средневековья. Обобщенный вывод, сделанный автором, сводится к тому, что татарские романические эпос-дастаны, в том числе и популярные произведения на сюжет о Лейли и Маджнуне, возникли и формировались под влиянием знаменитых поэм древнетюркской поэзии, но в своем развитии приспособились религиозно-мифологическому мировоззрению этноса и к татарской культуре своего времени.

**Ключевые слова:** романический дастан, эпический фольклор, религиозно-мифологическое представление мира, историко-литературный процесс, поэзия Средневековья.

The article is devoted to the study of some artistic specifics of dastans of a romantic nature in the history of literature and folklore. Based on specific material stored in the archival funds of the IYALI named after G. Ibragimova Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan the author demonstrates the richness of the dastan written heritage of the Tatars; the artistic and expressive means of one of the national versions of «Leyli and Majnun» textually processes and analyzes. The article reveals the qualitative features of the dastan genre, closely related to the ethno-cultural traditions of the Tatar people, establishes links between epic folklore and Tatar literature of the Middle Ages. The generalized conclusion made by the author comes down to the fact that Tatar romantic epic dastans, including popular works on the plot of Leyli and Majnun arose and were formed under the influence of the famous poems of ancient Turkic poetry but in their development they adapted to the religious and mythological worldview of the ethnic group and to the Tatar culture of his time.

**Key words:** romantic dastan, epic folklore, religious and mythological representation of the world, historical and literary process, poetry of the Middle Ages.

Дастаннар – татар халык иҗатының да, шул ук вакытта әдәбиятның да тикшеренү объекты булырлык кызыклы өлкә. Халыкның борынгы заманнардан алып яшәеше чагылыш тапкан бу төр әсәрләрдә фольклор стиле, эпик мотивлар сакланган, алар күп вариантлы

булулары белән игътибарны җәлеп итәләр. Шул ук вакытта дастаннар Борынгы һәм Урта гасыр төрки әдәбияты чалымнарын да үзләштергәннәр, алга таба татар классик әдәбияты формалашуга зур йогынты ясаганнар. Фарсы теленнән кергән әлеге терминның төрки телләрдә «тарих», «хикәя», үткән эшләр хикәясе мәгънәсендә йөргәнлеге мәгълүм [Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 5].

Татар әдәбияты белемендә һәм фольклористикада *дастан* сүзенә синоним буларак *эпос* төшенчәсе дә кулланыла. Асылда эпосның берничә төрле мәгънәсе яшәп килә. Беренче мәгънәсе – аның нинди дә булса вакыйганы хикәяләүгә, сурәтләүгә нигезләнгән, әдәбият һәм фольклор әсәрләрен үз эченә алган әдәби төр булуын күздә тотса, икенче мәгънәсе шактый тар – ул фольклорда һәм әдәби әсәрләрдә халык тормышын киң планда тасвирлаган, героик һәм романик характерга караган жанр буларак билгеләнә. Татар эпосын да дастан дип атау, һичшиксез, дөрес, чөнки алар эчтәлеге һәм формасы белән халык дастаны терминының гомуми мәгънәсенә, Урта Азия һәм Көнчыгыш халыклары әдәбият һәм фольклорында таралган дастан жанры билгеләренә туры киләләр.

Татар дастаннары хәзерге көндәге яшәеш формалары һәм башкарылу үзенчәлекләре, сюжет составы һәм поэтикасы, функцияләре һәм характеры белән эпос жанры тарихына хас табигый бер этапны күрсәтеп тора. Бу этапта безнең дастаннарның күбесе гомумтөрки эпос традицияләрен саклый. Шул ук вакытта дөнья халыклары әдәбияты, әдәби сюжетларның да татар дастаннарына йогынтысы зур булган. Башка халыклар иҗатында махсус эпик кануннар, иҗади факторлар көчле булса, татар дастаннарын күбесенчә китаби традицияләр тәшкил иткәнлеге мәгълүм.

Эпос-дастан билгеле бер халыкның үткәнен, тарихта эз калдырырлык мөһим вакыйгаларны тасвирлый. Биредә бу җирлектә яшәүче кешеләрнең ышанулары, табыну идеаллары, төгәлрәк әйткәндә, әкияти-мифологик, тарихи-героик, дини-героик, ә кайвакыт мәхәббәт маҗарасына нигезләнгән сюжетлар да урын ала. Мәгълүм булганча, ике гашыйкның мәхәббәт тарихын сурәтләүгә багышланган татар дастаннары романик дастаннар төркемен тәшкил итә. Татар романик дастаннары арасында аеруча «Таһир белән Зөһрә», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Бүз егет», «Йосыф китабы» популяр булган. Мавыктыргыч сюжеты, традицион романтик образлары белән генә түгел, күп канкойгыч сугышлар күргән, коллык, ярлылыктан интеккән гади халык өчен матур, мавыктыргыч мәхәббәт тарихына нигезләнгән бу әсәрләр юатучы, илһамландыручы ролен үтәгән.

Татар романик дастаннары билгеле бер вакыйганы сөйләп бирү белән генә чикләнмичә, геройларның хис-тойгыларын, күңел кичерешләрен ачып бирә. Героик дастаннардан аермалы буларак, биредә төп геройның кылган батырлыклары арткы планга күчә, тик шулай да кайбер дастаннарда геройның тылсымлы туу, төш күрү элементлары саклана. («Таһир белән Зөһрә», «Сәйфелмөлек кыйссасы» һ.б.).

Мәхәббәт маҗарасына корылган дастаннарның асылында – бөек мәхәббәт хисенен көче, үлемсезлеге идеясе ята. Романик дастаннар сәяси мотивлар, тарихи вакыйгалардан шактый ерак, фәкать кайберләрендә генә реаль геройлар, сәяси проблемалар күренеп ала («Таһир белән Зөһрә»). Татар романик дастанында халыкның мифологик-фәлсәфи фикерләве чагылыш табу да бик кызыклы.

Борынгы һәм Урта гасыр Көнчыгыш әдәбияты традициясендә илаһи мәхәббәткә дан җырлаган әсәрләр татар дастаннарының иң зур өлешен алып тора [Мухаметзянова, 2014, с. 161–163]. Романик дастаннар һәркайсы диярлек үзләренең чагыштырмача күләмле булулары белән аерыла. Татар романик китаби дастаннарын Урта Азиядә мәгълүм «Рөстәмхан», «Сәят-Хәмра», «Асли-Кәрәм» һ.б. кебек саф романик әсәрләр дип әйтеп булмый. Татар телле дастан алардан шигъри эшләнешенең күбесенчә тезмә аралаш чәчмә булуы, күләменең чагыштырмача кечкенәлеге, бер яки берничә сюжет сызыгыннан гына торып, төгәл структуралы булуы, милли җирлек чагылыш тапкан сюжет үзенчәлекләре һ.б. сыйфатлары белән аерылып тора. Идел буе татарлары романик дастаннары, нигездә, барысы да китап стиленә тартыла. Бу төркем дастаннарда әдәби сюжетлар, әдәбиятның поэтик формалары фольклор стилендә үзләштерелгән. Персонажлар сөйләмендә дә «тере» башкарылуга хас билгеләргә караганда әдәби телгә якын нейтраль тел өстенлек итә.

Идел буе татарлары язма фольклорындагы мәхәббәт дастаннарында, шул ук сюжетка жанрның «тере» традицион төре белән чагыштырганда, әлбәттә, динамикалык, башкарудагы киң диапозон, телдән хикәяләүдә очрый торган энергия инде юылган, шигырь төзелешендә халык стиле буларак куланылып килгән силлабикага нигезләнү дә бик нык кимүгә йөз тоткан. Романик дастаннарда кайвакыт героика чалымнары чагылып китә. Әйтик, «Сәйфелмөлек», «Бүз егет», хәтта «Ләйлә белән Мәҗнүн»дә дә бу ачык күренә. Ә менә атаклы «Түләк», гәрчә ул мәхәббәт дастаны булса да, үзенең архаиклыгы белән һәм алыплар турындагы хикәятләргә якынлыгы ягыннан күбрәк каһарманлык дастаннары төркеменә якын.

Алга таба Ләйлә белән Мәҗнүн сюжетлы татар дастанына киңрәк тукталырбыз. Урта гасыр язма мәдәниятендә зур урын алып торган бу ядкяр татар халкында XVIII гасырдан башлап (бәлки аннан да иртәрәктер) бик популяр булган, халкыбызга аның берничә мөстәкыйль варианты мәгълүм [Мухаметзянова, 2013, с. 76–80]. «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең татар версиясе – башка романик эпос-дастаннар кебек үк, татар халык иҗатының әдәбият белән чиктәш әсәрләреннән. Анда Урта гасыр төрки әдәби традицияләре татарларга хас җирле мәдәният һәм дини-мифологик карашлар белән керешкән.

Дастан вариантларының берсе – 1973 елда Казанда табылган кульъязма. Ул Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә саклана [Ләйлә белән Мәҗнүн, колл. 39]. Текст «Хикәйәти Ләйлә белән Мәҗнүн будыр» дип

башланып китә. Ләйлә белән Мәҗнүннең Зәед исемле остаздан белем алулары, икесенең дә «бигаять (чиксез. – *Г.Х.*) назнин (назлы. – *Г.Х.*), зифа, күркәм» булулары, башлап Ләйләнең Мәҗнүнгә гашыйк булып, мөзәйинәдән (бизәндерүче. – *Г.Х.*) үзен зиннәтләттерүе, таңгача Аллаһтан үзенең кыяфәтен шушы зиннәтле килеш калдыруын ялварып чыгуы, аннан соң Мәҗнүннең, Ләйләне күреп, гашыйк булуы, мәхәббәтеннән тилереп, сәхрәгә чыгып китүе, Ләйләнең аны эзләп барып та, Мәҗнүннең хәлен күреп, өенә кайтып китүе, хәсрәтеннән вафаты, Мәҗнүннең, аны эзләп килеп, юлда очраган кызчык белән сөйләшүе, Ләйлә каберен табып, үзенең дә мәгъшукасы киткән дөньяга китеп баруы дастанда бик җентекләп тасвирланган.

Кулъязмада Зәеднең төшендә Ләйлә белән Мәҗнүнне оҗмах бакчасында күрүе турында хәбәр ителә. Остазлары алардан: «Әй, сезләр, бер-берегезгә кавыштыгызмы?» – дип сорый. Ләйлә белән Мәҗнүннең җавабы биредә гаять фәлсәфи яңгырый: «Әй, остаз, безләргә бу йир-күк бозылмаганча кавышмакга әмер юкдыр. Аның өчен безниң туемызга бу йирне күтәргән үгезне суеп туй кылыныр». Шул рәвешчә, әсәрдә Ләйлә белән Мәҗнүннең кавыша алмаулары сәбәбенә зур мәгънә салына. Димәк, бу икәүнең кавышуы кыяматкәчә мөмкин хәл түгел. «Әгәр безләр дөньяда кавышырга улсак иди, харап улып ирди. Адәмләргә мәкян (торыр урын, торган җир. – *Г.Х.)* калмас», – диләр алар. Дөньяда дигәндә, монда ислам мифологиясендәгечә теге һәм бу дөньялар күздә тотыла. Кыямәт көненә кадәр («йиркүк бозылмаганча») бу икәү кавыша алмый, чөнки моның ахыры начар бетәчәк.

Ә инде җирне күтәреп тора торган үгез – дөнья картинасын космогоник күзаллауда очрый торган бик борынгы мифологик образ. Дөнья халыклары мифологиясендә Җирне үзенең мөгезендә күтәреп торган үгез турындагы миф еш очрый [Мифы народов мира, 1991, с. 67]. Борынгы заманда кешеләрнең Җирне хәзерге шикелле түгәрәк шар формасында дип түгел, ә бәлки үгез мөгезендә торган тигез, яссы урын дип күзаллаулары, ә үгез үзе очсыз-кырыйсыз суда йөзеп йөри торган балык мыегына беркетелгән дип уйлаулары мәгълүм [Урманче, 2011, б. 151].

Мондый борынгы ышанулар белән бәйле мифологик легендалар безнең борынгы ата-бабаларыбызда да сакланып калган. Дөньяны мифологик күзаллау картинасы кыйпылчыкларын татар халкында әле соңгы чорда да очратырга мөмкин. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институның 2013 елда Мамадыш районы татар авылларына үткәрелгән фольклор экспедициясе вакытында, мәсәлән, филология фәннәре докторы Л.Х. Мөхәммәтҗанова Ишки авылында Мөхәммәтханова Флёра Зиннур кызыннан (1939 елгы) түбәндәге мифологик хикәятне язып алган. «Җир өч китта тора икән, дип сөйлиләр иде. Өч кит өстендә – бәк зур үгез. Шул үгез Җирне тотып тора икән. Җир читенә барып чыксаң, су башлана. Китлар бетеп, су башланган урынга барып чыккан

буласың инде. Китлар иксез-чиксез суда, имеш. Җир читеннән су, океан башлана. Бәләкәй вакытта ишеткән нәрсәләр инде бу. Төрле кешедән ишетеп, башка шулай кереп калган. Әкият бит инде». (Информант – Мамадыш районы Түбән Ушмы авылында яшәгән Ибраһимов Мөбәрәкша Ибраһим улы, һөнәре белән комбайнчы-механизатор, 1931 елгы, 83 яшендә вафат.) Яисә шул ук темага түбәндәгечә сөйләнә: «Үгез Җирне менә шулайттырып (информант ике кулын башы өстенә күтәреп, бармакларын тырпайтып күрсәтә. – *Л.М.*) күтәреп тора иде дип сөйләгәннәр. Мөгезенә куеп. Үгез үзе нәрсәдә торгандыр, белмим. Җир үгез мөгезендә торган, яссы булган. Әкият инде бу. Бездән көлә торган булмасын. Элекке кеше сөйләгән бит» [Миллимәдәни мирасыбыз, 2017, б. 194].

Мондый хикәятләрне татарларның бүгенге көндә дә сөйләве – дөнья һәм тирәлек турында халык күзаллауларының тамыры бик тирән булуны дәлилли. Әлеге фәлсәфи-мифологик карашларның XVIII гасырда популяр татар романик дастаннары белән тәңгәллеге милли-мәдәни фикерләүдә эзлеклелек һәм тотрыклылык саклану турында хәбәр итә. Моңа охшаш хикәятләрне халык үзе «әкият инде» дип билгеләүгә карамастан, аларның нигезендә бик борынгы мифологик ышанулар ятканлыгы шик уятмый. Үзенең фәнни монографиясендә И.Г. Закирова да безнең халыкта Каф тавы белән уратып алынган Җирне үгез мөгезендә, үгезне – балык өстендә, балыкны – суда, суны исә һавада эленеп тора дип күзаллауның традицион космогоник концепция булуы хакында искәрткән иде [Закирова, 2003, б. 53]. Гомумән борынгы төркиләрдә үгезне изгеләштерү, үгез культы булган. Бу тема Г. Дәүләтшин хезмәтендә шактый тәфсилле яктыртыла [Дәүләтшин, 1999, б. 199]. Профессор Ф. Урманчеев мифологик үгез образының килеп чыгышын борынгы Авеста белән бәйләп карый, русчага Первозданный бык дип тәрҗемә ителә торган бу җан иясенең Авестада Ахура-Мазда тарафыннан барлыкка китерелгән булуы турында яза. Борынгы Шәрыкта, бигрәк тә зәрдөштлек хөкем сөргән илләрдә (Көнчыгыш Иран һәм Урта Азия, б.э.к. XII–X гасырлар), – ди галим, – Үгез, бигрәк тә Күк Үгез культы, аны изгеләштерү, аллалар дәрәҗәсенә күтәрү, аның килеп чыгышын, формалашуын һәм төп вазифаларын Галәм белән бәйләү югары дәрәҗәдә була» [Урманче, 2011, б. 154].

Ләйлә белән Мәҗнүн турындагы татар дастанына фәлсәфи-легендар үгез образының килеп керүе – дастанның татар версиясе үзенчәлеге. Җирне күтәреп торган үгезнең һәлакәте белән Коръәндә һәм ислам мифологиясендә тасвирланган Кыямәт көнен бергә бәйләп карау татар эпосында фәлсәфи-мифологик фикерләүнең булуын күрсәтә. Мондый фикерләү фольклорга гомумән хас. Бу очракта Җирне күтәреп торган үгезнең дастанга килеп керүе – гади халыкның дөньяны мифологик күзаллавы белән бәйле космогоник мифнең әсәрдә чагылышы, дөнья картинасын дини-мифологик сурәтләү үрнәге ул.

Ә инде Ләйлә белән Мәҗнүннең теге дөньяда да һаман кавышмаулары – әсәрдә суфичыл карашның бер чагылышы. Төп игътибарның илаһи мәхәббәткә бирелү тенденциясе Низами Ганҗәви поэмасында да бар: Зәед күргән төштә бу икәү оҗмах бакчасында ике фәрештә булып, гаять тә бәхетле яшиләр. Низамида Ләйлә белән Мәҗнүннең мәхәббәте – иң беренче чиратта Аллаһка мәхәббәт.

Весь мир земной – всего лишь тлен и прах,
А чистота и вечность – в тех мирах [Низами, 1986, с. 304], –

ди поэма авторы, Ләйлә белән Мәҗнүннең илаһи мәхәббәтләрен тасвирлап.

Татар кульъязмасына килсәк, биредә әсәр Урта гасыр язма поэзиясе өчен характерлы булган суфичыл юнәлешне генә алга сөрүдән бик ерак тора. Текст ахырында Ләйлә белән Мәҗнүн мәхәббәте турында сөйләгән кыйссадан нәтиҗә чыгарыла (текстта ул «кыйссадан хисса» дип аерымланган). Дастанның бу өлешендә гашыйклыкның өч төрле булуы аңлатылган: аның беренчесе – гыйшык әгъла, ягъни Аллаһка гашыйк булудан гыйбарәт иң бөек хис, икенчесе – гыйшык оста, ягъни Ләйлә белән Мәҗнүннең гыйшкы кебек гыйшык, ә өченчесе – гыйшык әдна – дөньялыкка хас шәһвәти гыйшык. Дастан адәм балаларында бу өч төрле гыйшыкның өчесе дә булырга мөмкин, дигән фикергә урын калдыра, димәк, әсәр һич кенә дә тулысынча суфичыл мәхәббәткә дан җырлауга гына кайтып калмый.

Шулай итеп, Урта гасыр Көнчыгыш авторлары поэмалары тәэсирендә барлыкка килүенә карамастан, татар язма эпосы үз чорына хас җирле карашларны үткәрә, җирле күзаллауларга бәйле рәвештә, «Ләйлә белән Мәҗнүн» хикәятендә дөньяның (ә бәлки дөньяларның яисә ике дөньяның дип әйтү дөресрәктер) үзенчәлекле дини-мифологик картинасын тудыра. Җир-күкне күтәреп торган гигант үгез бар, ул үгезгә кыяматкәчә бердәнбер бурыч йөкләнгән, әмма үгез үзе дә, башка барлык җан ияләре кебек үк, Аллаһ ихтыярында, тәкъдиргә буйсынган. Ләйлә белән Мәҗнүн, бу дөньядан китеп, теге дөньяда «бер олуг бостан эчендә» бергә булсалар да, аларга әлегә «кавышмага әмер юк». Ләйлә дә, Мәҗнүн дә язмышларына буйсынганнар. Алар теге дөньяда кавышу сәгатен көтәләр, әмма бу кавышу – Низами поэмасындагыча Аллаһ белән кавышуга омтылу түгел, җир кешесе аңына хас чынбарлык гыйшкы, тексттагы сүзләр белән әйткәндә, «гыйшык оста», ягъни әгъла гыйшкы белән әдна гыйшкы арасында торган, ике җенестәге кешеләргә хас бөек хис. Хикәятнең төп максаты – укучыга әнә шул бөек хис турында тәэсирле итеп сөйләп бирү, бөтен кешелек исәнлеге өчен бу ике гашыйкның корбан ителүенә укучыны кызгандыру. Әлеге максат дастан вариантында фольклор мотивлары, дөньяны дини-мифологик күзаллау, шулай ук әдәби сюжет һәм чаралар катнашында тормышка ашырылган.

Татар романик дастаннары Көнчыгыш әдәбияты тәэсирендә туганнар һәм озак гасырлар дәвамында шул әдәбият йогынтысында

формалашканнар, шул сәбәпле аларда Борынгы һәм Урта гасыр Көнчыгыш әсәрләреннән килә торган консервативлык традицияләре үзен сиздерә. Шул ук вакытта татар романик эпос-дастаннарында заман таләпләрен канәгатьләндерерлек дөньявилык, Европа культурасына, әдәбиятына, фәненә омтылыш идеяләре дә бөтенләй юк түгел. Татар әдәбиятын һәм мәдәниятен борынгыдан азыкландырып килгән Шәрык мәдәнияте һәм аның аша романик дастаннарыбызга үтеп кергән идеяләр, стиль үзенчәлекләре билгеле бер чорга кадәр милләтебезнең табигатенә гаять ярашлы булган. Романик дастаннарның һәркайсында, шул исәптән, «Ләйлә белән Мәҗнүн» дастанында да, әдәбият кануннары белән фольклор кануннары табигый үрелештә чагылыш табуын күзәттек. Романик характердагы дастаннарыбызның татар дастаны дигән специфик бөтен барлыкка китерүдә дә роле зур. Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар халкында Урта гасыр иҗат методы традициясендә әсәрләр язу бик киң таралган була. Бу метод мәгълүм сюжетка корылган мәшһүр бер әсәргә ияреп язу, аны тулысынча яки өлешләп тәрҗемә итү, шул сюжеттан илһам алып, яңа җирлектә өр-яңа әсәр иҗат итү, ул әсәрнең халыкта популярлашып, әллә ничә вариантта таралуы аша туган ядкярләрдә тормышка ашырылган. Һәрхәлдә татар халкында, аерым алганда, Идел буе татарларында, әлеге методның нәкъ менә шундый – чагыштырмача иркен стильдәге юнәлеше өстенлек иткән. Татар халык иҗатында, шушы гаять күпкырлы һәм масштаблы күренешнең бер чагылышы буларак, «Ләйлә белән Мәҗнүн» кебек популяр дастаннар формалашкан. Халыкта борынгы чорларда ук киң таралган мондый сюжетлар татарларда XX гасыр башынача актив яшәгән. Татар телендә ярым әдәби, ярым фольклор текстларны төзегән иҗатчы-күчерүчеләр китап теленә, китаби гыйбарәләргә һәм образларга мөрәҗәгать иткәннәр, шул рәвешле романик дастаннарда фольклор катыш әдәби стиль ныгыган. Татар романик дастаннары эпик фольклорның зур өлешен алып тора, әдәби процесста актив катнашуы ягыннан да алар гаять әһәмиятле.

**Әдәбият**

*Дәүләтшин Г.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 512 б.

*Закирова И.Г.* Болгар чоры халык иҗаты. Казан: Фикер, 2003. 144 б.

Ләйлә белән Мәҗнүн. ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИнең Язма мирас үзәге, колл. 39, сак. бер. № 5015.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Мамадыш. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән, уникенче китап). Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2017. 344 б.

Мифы народов мира: Энциклопедия в 2-х т. 2-е изд. М.: Сов. энцикл., 1991. 719 с. һ.б.

*Мухаметзянова Л.Х.* Соотношение индивидуального и традиционного в романическом книжном дастане татар «Лейля и Маджнун». Вестн. Челяб. гос. ун – та. Филология и искусствоведение. Вып. 76. № 10 (301) 2013.

*Мухаметзянова Л.Х.* Тематическая классификация татарского эпоса: романические и героические книжные дастаны // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота. 2014. № 6 (36). Ч. 2. С. 161–163.

*Низами Гянджеви.* Собрание сочинений в пяти томах. Т. 3. Перевод с фарси Т. Стрешневой. М: Худ. литер., 1986. 366 с.

Татар халык иҗаты. Дастаннар. Томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы Ф.В. Әхмәтова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 384 б.

*Урманче Ф.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. 3 т. (С – Я). Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 216 б.

***Хөсәенова Гөлнира Рәзиф кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге*
*аспиранты*

УДК 398

***Р.Ф. Сафиуллина***

# ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫН РУС ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Статья затрагивает проблемы перевода жанров татарского фольклора на русский язык. Автором упомянуты сборники татарского фольклора, которые изданы на русском языке, начиная с 20-х годов XX века до настоящего времени. Этот краткий обзор позволяет сделать вывод о том, что татарский фольклор издавался на русском языке в недостаточном количестве. Проблемы количественного характера повлияли и на качество: не были разработаны теоретические вопросы перевода; отсутствовала школа переводчиков фольклора; наблюдался застой в переводе отдельных жанров.

Современные подходы предполагают, что перевод фольклора воспроизводит не только смысл, но должен передавать культуру и мировоззрение целого народа. Это требует особого внимания к переводу фольклора, что на данном этапе и выполняется учеными-фольклористами Академии наук Республики Татарстан. В качестве примера последовательного решения данной проблемы автор рассматривает издание мунаджатов на русском языке.

**Ключевые слова:** русскоязычные издания татарского фольклора, жанр, мунаджаты, эквивалентность, поэтический перевод.

The article studies the problems of translating Tatar folklore genres into Russian. The author mentions collections of Tatar folklore published in Russian from the 1920s till present time. This brief review allows us to conclude that very little of Tatar folklore was published in Russia. Problems of a quantitative nature also affected the quality: theoretical issues of translation were not developed; there was no school for translators of folklore; there was a stagnation in the translation of certain genres. Modern approaches suggest that the translation of folklore reproduces not only the meaning but must convey the culture and worldview of an entire people. This requires special attention to the translation of folklore, which at this stage is carried out by folklore scientists of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. As an example of a consistent solution to this problem the author considers the publication of munajats in Russian.

**Keywords:** Russian editions of Tatar folklore, genre, munajats, equivalence, poetic translation.

Татар фольклорының рус теленә беренче профессиональ тәрҗемәләре XX гасырның егерменче елларында басылып чыга башлый. (Моңарчы нәшер ителгәннәренең тарихы XIX гасыр азагында башланса да, әлеге эш берән-сәрән һәм очраклы характерда алып барылган, фәнни нигезгә салынмаган була. Шул сәбәпле бу мәкаләдә игътибарга алынмый). 1921 елда Казан шәһәрендә Халык мәгарифе комиссариаты каршында Академик үзәк ачыла. Әлеге үзәк барлыкка килү белән, «Татар фольклоры үрнәкләрен башка телләргә тәрҗемә

итү буенча эш җәелдерелә» [Ямалтдинов, б. 50]. Гадәттә, яңарак төр фәнни юнәлешләр шома гына башланып китми: тыштан бәя биргәндә процесс каршылыксыз һәм җайлы кебек күренсә дә, төрле мәсьәләләр дә туып кына тора.

Совет чорында рус телендә чыккан беренче татар фольклор җыентыгы – М. Васильевның «Памятники татарской народной словесности. Сказки и легенды» китабы Казанда 1924 елда нәшер ителгән. Китапка барлыгы 53 татар халык әкияте һәм 7 риваять кертелгән.

1930 еллар ахырында татар дастаннарын тәрҗемә итүгә нигез салына. Мәскәү шагыйре Семён Липкин «Идегәй» дастанын басмага әзерли. Әмма «ханнар-феодаллар эпосы» дигән сәяси-идеологик тамга салыну аркасында, атаклы «Идегәй»не рус телендә бастыруны 1990 елга хәтле туктатып торалар.

1920–1970 елларда татар халык иҗаты әсәрләреннән риваятьләр – 2, мәзәкләр 1 мәртәбә рус телендә нәшер ителгән. Фольклор әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итүдә совет чорында хәтта әкият кебек популяр һәм идеологик яктан «хәвефсез» жанрда да кайбер тоткарлыклар күзәтелгән. 1920–1970 еллар арасында рус телендә татар әкиятләре җыентыгы нибары 4 тапкыр басылып чыккан. Җыр китапларын тәрҗемә итү мәсьәләсенең яхшырак куелганлыгын күрәбез: шушы ук аралыкта 10 җыентык дөнья күргән. Татар халык җырлары басмаларының рус телендә чагыштырмача күп булуы аларның кечкенә күләмлелеге (15–20 текст) һәм пропагандистик эчтәлеге (Ленин, Сталин, партия темалары һ.б.) белән дә аңлатыладыр.

СССР да милли фольклор китапларын рус теленә тәрҗемә итү аларны берьюлы союздаш республикалар телләрендә һәм кайбер дустанә илләрнең телләрендә бастыруга юл ачкан. Мәсәлән, 1953 елда Мәскәүдә нәшер ителгән татар әкиятләре җыентыгы кытай, венгр, әрмән, литва, молдаван, украин, үзбәк, төрекмән, казакъ, монгол, болгар һ.б. телләрдә дөнья күрә [Ямалтдинов, б. 159], ләкин мондый массакүләм тәрҗемәләр бүтән эшләнмәгән, аерым телләргә генә тәрҗемәләр басылган.

Әлеге кыскача күзәтүдән күренгәнчә, татар фольклорын совет чорында русча бастыру эше җитәрлек күләмдә булмый. Мәсәлән, русча нәшер ителгән фольклор җыентыклары арасында 1980 еллар ахырына кадәр бәетләр, мөнәҗәтләр, шигъри дастаннар һ.б. жанрлардан рус теленә бер генә тәрҗемә дә юк. Мондый төр фольклор тәрҗемәләре Татарстанда үзгәртеп кору елларында һәм аннан соңгы чорда гына чыга башлый.

Совет чорында татар фольклорының рус теленә сыйфатлы тәрҗемәләренә кытлыкны фольклор әсәрләре белән эш итә алырлык квалификацияле тәрҗемәчеләр, тәрҗемәчелек мәктәбе булмау, тәрҗемәнең теоретик мәсьәләләре ахыргача эшләнмәгәнлек белән дә бәйләп карарга кирәк.

Теләсә кайсы телгә тәрҗемәләр, бигрәк тә шигъри калыптагылары, тәрҗемәченең профессиональ әзерлеген һәм тәҗрибәсен, аерым

сәләткә ия булуын таләп итә: «...Тәрҗемә эше катлаулы, ул оригиналның эчтәлеген һәм формасын чагылдыру өчен тел чараларын даими эзләүдән гыйбарәт. Бу эзләнүләр һәм бу сайлау иҗади характерны күздә тота, актив эш таләп итә. Нәфис әдәбиятка һәм фольклор әсәрләренә килгәндә, аларны тәрҗемә итү... әдәби осталыкка ия булуны сорый. Мондый төр тәрҗемәләр сәнгать өлкәсенә карый» [Федоров, с. 16].

СССР халыклары телләреннән русчага тәрҗемә итү һәм тәрҗемәчеләр әзерләү буенча Татарстанда гына түгел, хәтта ил күләмендә оештырылган үзәк булмый. «Бары тик XX гасыр уртасыннан башлап кына тәрҗемәчелек эшчәнлегенең барлык төрләре моңарчы күрелмәгән колач ала...» [Федоров, с. 21]. Гомумән алганда, СССРда тәрҗемә эшенең теоретик базасы узган гасырның 60 нчы елларында гына фәнни системага салына. Татар фольклорын рус теленә тәрҗемәләп чыгару эше 70 нче елларда активлаша башлый.

1972 елда М. Горький исемендәге Әдәбият институты каршында татар теленнән рус теленә тәрҗемәчеләр курслары оештырылган [Габдрахманова, 34 б. ]. Әлеге курсны беренчеләрдән булып тәмамлаучылар арасында прозаик Солтан Шәмси, шагыйрәләр Роза Баубекова-Кожевникова, Фирдәвес Әһлия һ.б. бар. Әмма алар алдына татар фольклорын тәрҗемә итү бурычы куелмаган. Моннан тыш, нәфис әдәбият тәрҗемәчеләре – прозаиклар һәм шагыйрьләр – фольклор текстлары белән эш итәргә әзер булмыйлар әле. Фольклорны тәрҗемә итү – халык иҗатын тирәнтен белүне яки фольклорчы галим башкарган юлга-юл тәрҗемәләрдән сакчыл файдалануны күздә тота торган үзенчәлекле, четерекле өлкә ул.

Үзгә тел системасына кертелгән фольклор әсәре оригиналдагы төп мәгънәне генә тапшырып калмый – ул халыкның рухи байлыгы, дөньяга карашлары, архетиплары һ.б. белән дә таныштырырга тиеш. Фольклор текстлары еш кына архаик, үзенчәлекле сәнгати, тел-бизәкләү чаралары белән тулган; алар күп мәгънәле, катламнарга ия һәм сакраль, шуның аркасында мондый төр әсәрләрне үзгә телдә трансляцияләү тиешенчә әзерлеккә, осталыкка, тәҗрибәгә ия булмаган кешенең кулыннан килмәскә дә мөмкин.

Совет чорында чәчмә жанрларны рус теленә күчерүчеләр булган, әмма алар фольклорның поэтик жанрларын тәрҗемә итәргә алынмаган. Рус теленә шигъри тәрҗемәләр башкаруга рус телендә камил язган Мәскәү шагыйрьләрен җәлеп итәргә туры килгән, бу исә татар фольклор җыентыкларын рус телле укучыга җиткерү эшен акрынайткан яки билгесез срокка кичектергән.

Әлеге проблема чишелешенең бер юлы – ул фольклорның шигъри жанрларын тәрҗемә итү проектларына ике телне дә камил белгән шагыйрьләрне җәлеп итү. Андыйлар оригинал һәм тәрҗемә ителәсе телләрне белә, икесендә дә яки соңгысында шигырь язу потенциалына ия. Шулай да бу очракта тәрҗемәченең шигырь язу осталыгына гына түгел, ә фикерле тәрҗемәгә (вдумчивый перевод) сәләтле булуы

шарт. Киресенчә булганда, оригинал белән охшаш, ләкин эквивалентсыз тәрҗемәгә генә ирешелә.

Сыйфатлы тәрҗемә, иң элек, фольклор текстын максималь дәрәҗәдә төгәл итеп тапшыру мәсьәләсен хәл итәргә бурычлы. Үзгә телгә трансляцияләнәсе текст берәмлекләренең семантик, стилистик, синтаксик, мәдәни-тарихи, фольклористик һ.б. эквивалентларын табу – гаять катлаулы, дәвамлы процесс [Лиморенко, с. 17]. Сирәк очракларда тәрҗемә объектив һәм субъектив сәбәпләр аркасында төгәл эквивалентлылыкка ирешүне максат итеп куймаска да мөмкин. Монда алмаштырырга мөмкин вариантлар – аналогларны табу таләп ителә. Икенче телдә оригинал текстның мәгънәсен генә тапшырырга кирәк булган очракта «шартлы тәрҗемә» төшенчәсе дә кулланыла. Тәрҗемәченең эшен эчке һәм текст астындагы аңлатмалар, оригинал телдәге текстка фәнни комментарийлар, искәрмәләр [Федоров, с. 60], глоссарий, архаизмнар сүзлеге әзерләү дә җиңеләйтә ала.

Татар фольклоры жанрларын һәм аерым әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү мәсьәләләренең күбесе – гомуми характерда. Аларны, нигездә, илдәге башка халыкларның милли фольклорлары өчен дә уртак дип билгеләргә мөмкин булыр иде. Шулай ук халык иҗатының аерым жанрларын үзгә телгә трансляцияләгәндә очрый торган, ягъни эчке мәсьәләләр дә туып тора. Алар, билгеле, һәр конкрет очракта жанрлар тәрҗемәсе эчендә аерым карауны сорый.

Татар фольклорының рус телендәге конкрет басмасын эшләү процессыннан бер характерлы мисал китерәбез. Поэтик жанрларны тәрҗемә итүгә аерым игътибар бирү сорала, чөнки ул – катлаулы һәм гаять күп көч таләп итә торган процесс. Әлеге эштәге тәҗрибәнең чәчмә жанрларны русчага трансляцияләү белән чагыштырганда аз булуы да теманы җентекләп ачуга этәрә. 1990 еллар азагы – 2000 еллар башында мөнәҗәтләрне рус теленә тәрҗемә иткән белгечләр (фольклорчы галимнәр һәм тәрҗемәчеләр) тәҗрибәсе, алар очраткан кыенлыкларны белү кызыклы.

Иң беренче мәсьәлә: мөнәҗәтнең атамасын рус теленә төгәл тәрҗемә итү мөмкин түгел, чөнки рус фольклорында да, байтак термин һәм төшенчәләре калькалаштыру юлы белән татар теленә кертелгән Европа халыклары иҗатында да да мөнәҗәткә тәрдәш жанр юк. «Мөнәҗәт» – гарәп сүзе, татар теленә, ислам дине кабул ителгәннән соң (X гасырда), Изге Коръән китабы белән, шулай ук башка мөселман халыкларының бай һәм тирән язма мирасы белән бергә кергән.

Раббым – Алладыр бәнем,  
Динем – исламдыр бәнем,  
Кыйблам – Кәгъбәмдер бәнем,  
Бердер Аллаһым бәнем.

Мой Господь – Аллах один,  
Верой мне – ислам один,

А святыня из святынь –
Мне Кааба, о Аллах [Садекова, б. 43].

Мөнәҗәтнең мәгънәсе – Аллаһның бу һәм киләчәк дөньяда бәндәләренә карата мәрхәмәтен үтенеп ялвару, дога кылу, тәүбә итү. Тормышта катлаулы хәлләр килеп чыкса да, сабырлык-түземлек сорап та татар халкы элек-электән Аллаһка ялварган, Раббысы белән шул рәвешле аралашкан. Мөнәҗәтләрдә дини гыйбадәтләр үтәү, гөнаһлардан саклану, бу дөньяның фанилыгы һ.б. телгә алына, шулай ук пәйгамбәрләр, аеруча Мөхәммәд (с.г.в.с.) мактала. Тәрҗемәдә термин мәсьәләсе русча «мунаджаты» дип билгеләп хәл ителгән, аңлатма кереш мәкаләдә бирелгән.

Фольклорчы Айсылу Садекова фикеренчә, мөнәҗәтләрнең бер өлешен – дини фольклорга, бер өлешен дөньяви фольклорга кертеп була [Садекова, б. 4]. Димәк, жанр үрнәкләрен үзгә телгә трансляцияләү проблемалары идея-мәгънә яссылыгында ук калкып чыга. Тирән лирик кичерешләргә, рефлексиягә, кайвакыт кешенең кайгы-хәсрәтен тасвирлауга корылган мөнәҗәтләр хәзерге заманда «татарча беләм» дип санаган татарларга да яхшы таныш, дип әйтеп булмый. Нәтиҗәдә, тәрҗемә русларны гына түгел, татарларны да әлеге жанр белән таныштыру функциясен үтәргә тиеш була.

Мөнәҗәтләр мөселман халыкларында, шул исәптән, төркиләрдә дә, ислам динен кабул иткән заманнардан бирле яши, дидек. Димәк, жанрга катлаулы дини терминология, мөселман һәм Коръәни образларның, байтак мөнәҗәтләрдә искә алынган персонажларның күплеге, әлеге тематика сюжетларына аллюзияләр һәм реминесценцияләр хас. Алар төрки халыкларның күпгасырлык фольклоры белән дә тыгыз үрелгән. Тәрҗемә иткәндә кыенлыкларның бер өлеше ислам-Коръән лексикасын, образларын, символларын, аларның татар фольклоры белән үрелешен, ассоциацияләрен икенче телдә адекват итеп тапшыру белән бәйле. Мөселман-төрки-татар традициясен русчага күчерү турында мәгълүм нашир һәм шагыйрь, тәрҗемәче Максим Амелин: «Күп гасырлар дәвамында үзенә төрле традицияләрне сеңдергән, ләкин асылда Европаныкына якын рус теленә тәрҗемә итүче өчен болар – төп кыенлыклар. Телнең эчендә тел эзләп табарга, охшаш образлар системасын булдырырга, метрик эквивалентлар тәкъдим итәргә – катлаулы, ләкин хәл итәрлек бурычлар», – дип яза [Амелин, с. 18].

Татар мөнәҗәтен рус теленә тәрҗемә итүнең тагын бер катлаулылыгы – оригиналдагы һәм тәрҗемә телендәге шигъри текстларның структурасы, ритмика, строфикасы аермасында [Иванов, с. 80]. Төрки һәм мөселман халыкларының шигъри системасы славян һәм Европа халыкларыныкы белән чагыштырганда нык аерылып тора. Шагыйрь-тәрҗемәче, филология фәннәре кандидаты Алексей Саломатин фикеренчә, совет елларында тәрҗемәчеләр моны истә тотмаган, алар күбесенчә стандарт «шартлы-поэтик тәрҗемә»дән файдаланган. Ягъни текстның үлчәм, ритм кебек үзенчәлекләрен башка телдәге чаралар

белән мөмкин кадәр төгәл тапшыру һич тә максат итеп куелмаган. Чынында исә «тәрҗемәче эстетик яктан да югары сыйфатлы продукт тудыру өчен күп көч куярга тиеш» [Саломатин, с. 59].

Чираттагы мәсьәлә – мөнәҗәтләр татар халкында көйләп башкарыла, шагыйрь-тәрҗемәчегә аларның бу үзенчәлеген исәпкә алырга туры килә. Әмма бу очракта оригинал белән трансляция текстының тәңгәллегенә ирешү гаять катлаулы.

Шунысын искәртик: ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында татар фольклорын рус теленә тәрҗемә иткәндә туган проблемаларны (югарыда санап киттек) хәл итүгә җитди фәнни караш барлыкка килде. Мөнәҗәтләр мисалында гына карасак та, фольклор әсәрләрен русча нәшер итүдә эзлекле һәм максатчан эшләр башкарыла: юлга-юл тәрҗемәләр филология фәннәре докторы дәрәҗәсендәге компетентлы белгеч тарафыннан әзерләнгән, шулар нигезендә әдәби тәрҗемәне эшләүгә җитди иҗади потенциялга ия шагыйрь җәлеп ителгән.

Мөнәҗәтләрне русчага әйләндергәндә Казан шагыйре, танылган тәрҗемәче С.В. Малышев жанрны фәнни өйрәнгән галим һәм юлга-юл тәрҗемә авторы А.Х. Садекова белән һәрдаим киңәшеп эшләде. С.В. Малышев татар халкының сакраль, аутентик иҗатына русча эквивалент барлыкка китерер өчен, тирәнтен уйланып, татар фольклорын һәм галимнәрнең хезмәтләрен өйрәнде. Соңында русча текстның һәр юлына, һәр сүзенә диярлек берничә төрле синонимик вариантлар тәкъдим итеп, җентекләп эшләде. Мәсәлән:

Йөзләреңә яптык ак пәрдәләр,
Хушлаштык без барыбыз бергәләп;
Күзкәйләрең, әнкәй, ачмадың син,
Балаларың көтте бик озак, –

дигән оригинал тексттагы «күзкәйләрең» сүзенең төрле стильдәге «глаза», «глазки», «глазоньки»; «очи» вариантлары сайлап алынды. Аларның берсе дә хәсрәт эчендәге лирик геройның эмоциональ халәтен, катлаулы кичерешләрен оригиналдагыдай бөтен нюанслары, төсмерләре белән тапшыра алмый. Бик озак уйлаганнан соң, С.В. Малышев һәм А.Х. Садекова «оченьки» варианты кулай дигән уртак фикергә килделәр.

Лицо твое под белой пеленой,
Склонились мы над ним в последний раз…
Как нам хотелось встретить взгляд родной,
Что ж не открыла оченьки для нас? [Садекова, б. 52]

Нәтиҗәдә, рус телендә мөнәҗәтнең мәгънәсе адекват һәм төгәл тапшырылган, эстетик кыйммәткә ия иҗади продукт алуга да ирешелгән.

Бу мисал, билгеле, катлаулы процессның бер генә фрагменты, ләкин ул фольклор текстларын тәрҗемә иткәндә килеп туган проблемаларны

эзлекле рәвештә, комплекслы, бөтен нечкәлекләрен игътибарга алып эшләү юлы белән генә уңышлы хәл итеп булуын күрсәтә. А.В. Федоров сүзләренә караганда, «Тәрҗемә итү – элегрәк бер тел чаралары ярдәмендә бирелгән [текстны] башка телдәге чаралар белән дөрес, төгәл һәм тулы итеп гәүдәләндерү, һәм ул кыскартып яки үзгәртеп тәрҗемә итүдән, әсәрнең эчтәлеген сөйләп бирүдән, төрле «адаптация»ләрдән аерылып тора» [Федоров, с. 16] .

Фольклорны тәрҗемәләү һәрвакытта да мондый дәвамлы һәм шактый мәшәкатьле процесс түгел, әлбәттә. (Телгә алынган «Мөнәҗәтләр» китабы очрагында, мәсәлән, тәрҗемәчеләрнең озаклап, җентекләп эшләү мөмкинлеге булган, дип саныйбыз, чөнки басманың күләме артык зур түгел.) Фольклорның академик тәрҗемәләре һ.б. күләмле проектларның сроклары кайвакыт чикләнгән була; яисә һәрвакытта да фәнни оешма берьюлы юлга-юл тәрҗемә итүчене дә, шигъри осталыкка ия шагыйрьне дә эшкә җәлеп итә алмый. Әлеге проблеманы альтернатив чишү юлы – татар фольклор әсәрләренең рус теленә тәрҗемәләрен әзерләүгә ике телне дә камил белгән тәрҗемәчеләрне җәлеп итү. Идеалда мондый белгечләр – профессиональ шагыйрьләр (әгәр сүз шигъри текстларны тәрҗемә итү турында барса), шулай ук ике тел-әдәбиятның үзенчәлекләрен, мәдәниятне, тарихны яхшы белүче, өстәвенә, милли фольклорның зур катламын үзләштергән кешеләр. К. Чуковский сүзләренчә, «Шигъриятне тәрҗемә итүче үзе шагыйрь дә, игътибарлы тикшеренүче һәм тәнкыйтьче дә булырга тиеш» [Чуковский, с. 30]. Мондый югары дәрәҗәдәге белгечләр гаять сирәк очрый, ихтимал, аларны максатчан рәвештә өйрәтү, үстерү кирәктер.

Шунысын әйтергә кирәк, болар гына тәрҗемә ителгән текстларда фольклорның һәммә үзенчәлекләре саклануын гарантияләми. Соңгы елларда чагыштырма культурология мәсьәләләре белән кызыксыну арта, ә әлеге фән инде текстларны түгел, ә мәдәниятләрне тәрҗемә итүне алга сөрә һәм, үзгә телдә милли фольклорның бөтен үзенчәлекләре ачылмаса да, аларны тирәнрәк аңлау мөмкиндер, дигән өмет уята [Федоров, с. 30].

XX гасырның 80 нче еллар азагы – 90 нчы еллар башында рус телендә татар фольклоры җыентыкларын чыгару эше киң җәелдерелде. Беренчедән, татар фольклорын җыю, өйрәнү һәм системалаштыру белән шөгыльләнә торган төп фәнни оешма – ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИнең халык иҗаты бүлеге квалификацияле кадрлар, рус һәм татар телләрен бертигез дәрәҗәдә белүче фольклорчылар белән тәэмин ителгән иде. Институт галимнәре бу бурычны хәзер дә намус белән үтиләр. Икенчедән, татар фольклорының совет чорында «тыелган» жанрларын: дастаннар, дини мөнәҗәтләр, бәетләрне һ.б. яңадан чыгару мөмкинлеге туды. Татар халкының милли кыйммәтләре, рухи дөньясы, тарихи тамырлары белән кызыксыну соңгы берничә дистә елда бермә-бер артты. Бу рус телле татар укучысының гына түгел, башка халыклар вәкилләренең дә

татарларның аутентик этник кыйммәтләренә карата кызыксынуы зур булуны аңлата.

Шул ук вакытта бүген татарларның яшь буыны туган телен югалта бара. Димәк, татар фольклорын рус теленә тәрҗемә итү галимнәр өчен генә түгел, ә тулаем татар халкы өчен дә көннән-көн актуальләшә. Хәзерге вакытта Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларның бер өлеше өчен татар фольклорының русчага Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ галимнәре тарафыннан әзерләнгән тәрҗемәләре үз милли гореф-гадәтләребез, фольклор байлыгыбыз белән танышуда җитди, ышанычлы чыганак булып тора.

1990–2000 елларда татар фольклорының аерым әсәрләре генә түгел, ә төрледән-төрле жанрлары да рус теленә актив тәрҗемә ителә башлады. Татар халык иҗатын тәрҗемә итүгә игътибар татар халкының рухи хәзинәләре һәм аутентик мәдәнияте белән кызыксыну артуга, шулай ук күпчелек җирдә төпләнеп яшәүче татарлар мәнфәгатьләрен истә тотуга бәйле иде.

Татар халкының бай фольклор фонды соңгы берничә дистә елда фольклорчы галимнәрнең планлы эше, төбәкләргә экспедицияләр, архив материалларын өйрәнү һәм халыкка җиткерү нәтиҗәсендә шактый тулылана. Татар фольклористикасы өлкәсендә яңадан-яңа тикшеренүләр алып барыла. Академик фән казанышлары нәтиҗәсендә тәрҗемәчелек эшчәнлеге дә тулы куәт ала.

2008 елдан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты татар фольклорының рус телендә унбиш томлык җыентыгын бастырып чыгара башлады. Татар фольклорчылары һәм тәрҗемәчеләре алдында милли фольклорны мөмкин кадәр тулы күләмдә һәм бөтен үзенчәлекләрен саклаган хәлдә рус теленә тәрҗемә итү бурычы тора. Димәк, татар халык иҗатын аның барлык жанрларында һәм аспектларында тәкъдим итү юллары ачыла.

**Әдәбият**

*Амелин М.* «Упаси от напастей лихих…» // Идель. 2013. № 8. С. 18–20.

*Габдрахманова Ф.Х.* Чагыштырма әдәбият белеме системасында тәрҗемә. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. Казан: КФУ, 2016. 93 б.

*Иванов Вяч.Вс.* Лингвистические вопросы стихотворного перевода // Избранные труды по семиотике и истории культуры. Т. 3: Сравнительное литературоведение. Всемирная литература. Стиховедение. М.: Языки славянской культуры, 2004. 571 с.

Мөнәҗәтләр – Мунаджаты / Сост., авт. словаря, примечаний и подстр. переводов А.Х. Садекова, поэтич. перевод на рус. яз. С.В. Малышев. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 64 б.

*Лиморенко Ю.В.* Проблема перевода фольклорных текстов в научном издании // Живая старина. 2011. № 4. С. 17–20.

Принципы художественного перевода / Статьи К. Чуковского и Н Гумилева. СПб.: Изд-во «Всемирная литература» при Народном Комиссариате по Просвещению, 1919. 35 с.

*Саломатин А.* Габдельджаббар Кандалый: второе приближение // Идель. 2012. № 12. С. 17–19.

*Сафиуллина Р.Ф.* Переводы татарского фольклора на русский язык: проблемы и решения // II Сибирский форум фольклористов: к 90-летию со дня рождения А.Б. Соктоева, основателя серии «Памятники фольклора народов Сибири и Дальнего Востока»: Тезисы докладов / Отв. ред. Е.Н. Кузьмина. Новосибирск: Алекспресс, 2021. С. 127.

*Федоров А.В.* Основы общей теории перевода (лингвистические проблемы): Для ин-тов и фак. иностр. яз. учеб. пособие. 5-е изд. СПб.: Филол. фак. СПбГУ; М.: Изд. дом «Филология три», 2002. 416 с.

*Ямалтдинов И.И.* Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века. Собирание, публикация и научное изучение фольклора. Казань: ИЯЛИ, 2016. 184 с. (Библиотека журнала «Фәнни Татарстан», кн. 8).

***Сафиуллина Рузия Фәһим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398

***З.М. Брусько***

# ТАТАР ДАСТАННАРЫНДА ЭТНИК ЙОЛАЛАР ЧАГЫЛЫШЫ

Статья посвящена исследованию темы отражения этнических обрядов в татарских дастанах. Дастаны представляют собой яркий образец народного творчества, в котором содержится богатый материал по истории, духовной и материальной культуре народа. Обращение к данной теме обусловлено стремлением выявить типологические мотивы этнического характера в сюжетной линии произведений, раскрыть их идейно-эстетические, функционально-семантические особенности. Одной из основных задач исследования заключается в том, чтобы определить, что эпос как жанр взаимосвязан с обрядовым фольклором. Эпос и традиции тесно переплетены. Эпос дает возможность демонстрировать традиционные представления и мировоззренческие взгляды народа. Обращение к типологическим мотивам на примере отдельно взятых дастанов («Кузы Курпяч и Баян-Сылу», «Тахир и Зухра», «Туляк и Сусылу» и др) позволяет автору сделать вывод об их значимости и актуальности и в современной обрядовой жизни татар.
**Ключевые слова:** татарский, обряд, поверье, эпос, дастан, мотив.

The article is devoted to study of reflection of ethnic rituals in Tatar dastans. Dastans are vivid example of folk art, which contains rich material on the history, spiritual and material culture of the people. Referring to this topic is determined by the desire to identify typological motifs of an ethnic nature in the storyline of works, to reveal their ideological aesthetic, functional and semantic features. One of the main objectives of the study is to determine that the epic as a genre grew out of ritual folklore. Epic and traditions are closely intertwined. Epic provides an opportunity to demonstrate the traditional ideas and worldviews of the people. Reffering to typological motifs on the example of individual dastans («Kuzy Kurpyach and Bayan-Sylu», «Takhir and Zukhra», «Tulyak and Susylu») allows the author to draw a conclusion about their significance in the modern ritual life of the Tatars.
**Keywords:** Tatar, rite, belief, epic, dastan, motive.

Халыкның көнкүреше, йола-ышанулары, гореф-гадәтләре – гасырлар буе яшәп һәм башкарылып килә торган күренешләр. Буыннан-буынга тапшырылып, алар халыкның этник күрсәткече булырдай төс алганнар һәм формалашканнар. Халык ядкярләренең әлеге өлкәсен өйрәнү гаять кызыклы һәм еш кына әлеге эзләнүләр йола иҗатының яңа үзенчәлекләрен ачарга, аның семантикасы, функциональ кыры, килеп чыгышы мәсъәләләрен ачыкларга ярдәм итәләр. Йола традициясенең аерым күренешләрен чагылдырган материал халык иҗатының башка жанрларында, шул исәптән, дастаннарда, әкиятләрдә, мәкаль-әйтемнәрдә, тарихи җырларда һ.б. сакланып калган. Без исә игътибарыбызны дастаннарга, төгәлрәк әйтсәк, аларда телгә алынган, бүгенге көндә дә билгеле кайбер йола-гадәтләргә, ышануларга, фольклор мотивларына юнәлтүне максат итеп куйдык. Бу нисбәттән фольк-

лорчы Б.Н. Путиловның эпос жанрына карата әйтелгән сүзләрен китерү урынлы булыр: «Эпос – халык мәдәниятенең аерылгысыз өлеше, шушы мәдәниятнең табигый казанышы, халыкның тарихи тәҗрибәсен, карашларын, идеалларын, көнкүреш традицияләрен чагылдыручы ядкяр» (мәкалә авторы тәрҗемәсе) [Путилов 1988, с. 4] Шул ук вакытта галим эпик әсәрләр беркайчан да дөреслеккә туры килеп бетми, чөнки алар эпик күзаллау призмасы аша үткәрелә, шул нәтиҗәдә билгеле үзгәрешләр кичерә, дигән фикерне дә җиткерә [Путилов, 1974, с. 81]. Әлбәттә, жанр таләпләрен, иҗат ителү чорын исәпкә алып, дастаннарда сурәтләнгән эш-гамәлләрнең, вакыйгаларның күпмедер дәрәҗәдә күпертелгәнлеген, чынбарлыктан ераклаштырылганлыгын күзаллавы кыен түгел. Ләкин әлеге әсәрләрдә йола, гореф-гадәт күренешләренең телгә алынуы ук игътибарга лаек һәм бу – аларның борынгылыгын, традиционлыгын һәм әһәмиятен күрсәтә торган дәлил. Эпос жанры башлангычының нәкъ менә йола иҗатына барып тоташуы күренекле галимнәрнең хезмәтләрендә дә ассызыклана [Бакиров, б. 111; Закирова, с. 32–35; Мухаметзянова, Миннуллин, с. 5–11].

Сүзне күп кенә төрки халыкларның билгеле эпик әсәрләрендә, шул исәптән, татар дастаннарында да урын алган баласызлык мотивыннан башлыйк. «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Фәрһад вә Ширин», «Таһир белән Зөһрә» һ.б. дастанарда әлеге мотив әсәр сюжетында бик зур роль уйный. Әсәр геройларының балалары булмау сәбәпле бик нык кайгыруы, дога белән Аллаһка мөрәҗәгать итеп бала соравы һәм Хак Тәгаләнең аларга ярдәмгә килүе – балалы итү күренеше әлеге әсәрләрдә алга таба сөйләнәчәк вакыйгаларның башы булып тора.

Эпоста нәсел дәвамчысын төрле потлардан, әүлияләрдән, башка илаһи көчләрдән сорау – бик борынгы эпик мотив. Мәҗүсият чорыннан ук килгән, ягъни архаик чорларга ук барып тоташкан дастаннарда ул шактый зур урын били. Ихтыяҗны канәгатьләндерүне сорап төрле табигать көчләренә мөрәҗәгать итү мотивына корылган архаик эпостан аермалы буларак, бу күренеш татар дастаннарында ярдәм сорап Аллаһка мөрәҗәгать итү мотивы белән алышына. Бу турыда дастан жанрын тирәнтен өйрәнгән галимә Л.Х. Мөхәммәтҗанова болай дип яза: «Бу – тормыш-көнкүреш шартлары үзгәрү нәтиҗәсендә соңгырак чор эпосында борынгы эпик мотивларның да билгеле бер эволюция кичерүе, эпик чикләнгәнлекнең башка калыпка күчүе нәтиҗәсе. Әлеге әсәрләрдә бу үзгәрешләр табигый төс алган, ислам чоры ядкярендә балалы булуга ирешүнең башка альтернативасы юк һәм була да алмый» [Мөхәммәтҗанова, б. 181].

Илаһи көчләрдән бала сорау күренешенең йола буларак формалашканлыгы һәм аның борынгы бабаларыбыз тормышында гаять мөһим роль уйнавы турында без нәкъ менә югарыда аталган һәм башка әсәрләр аша күзаллый алабыз. Шул ук вакытта әлеге йола эзләрен бүгенге көн йола традициясендә дә күзәтергә мөмкин.

Билгеле инде, һәр заман кешесе тарафыннан да баласыз тормыш мәгънәсез тормыш буларак кабул ителә. Бу күренеш халыкта

актив кулланышта йөргән әйтемнәрдә аеруча төгәл чагылыш тапкан. Мәсәлән, «Балалы өй – базар, баласыз өй – мазар», «Баласы юк кеше – ботагы кипкән агач» [Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр, б. 394]. Бу нисбәттән бала табу йоласы кысаларында башкарыла торган кайбер эш-гамәлләргә игътибар итик. Баласызлык бәласенә тарыган гаиләләрдә бу хәлдән чыгу юлын әле дә төрле альтернатив ысулларга мөрәҗәгать итеп эзлиләр. Шуларның иң киң таралганы – балага уза алмаган хатынга чүлмәк салу. Халык медицинасының әлеге ысулы хатын-кызның эче төшкән булу яки анда «ирләр корсагы» булу сәбәпле башкарыла. Ышанулар буенча, дәвалау барышында хатын догалар укырга, Аллаһка мөрәҗәгать итеп, үз теләкләрен юлларга тиеш, шул очракта дәвалау да нәтиҗәле була. Экспедицияләр вакытында халыктан яздырып алган «Я, Раббым, бала бирсәң, өчне рәттән табар идем», «Аллаһым, Раббым, бала сөяргә насыйп итсәң иде» [Брусько, 2013, б. 19] кебек мөрәҗәгатьләр аеруча үтемле яңгырый. Әлеге ышану баласызлыктан котылырга ярдәм итә торган магик йолаларның «бала – Аллаһ бүләге» дигән төшенчә белән аерылгысыз бәйләнештә булуына ачык мисал булып тора. Бу исә үз чиратында бүгенге көн йола традициясен тулаем тасвирлый торган күрсәткеч тә – халык ышанулары һәм ислам дине карашлары бер-берсенә гәҗәеп төстә яраклашып, бер-берсен тулыландырып килә торган үзенчәлекле система барлыкка китергәннәр.

Карап узган мисал белән беррәттән татарларда тамырлары белән борынгы чорларга барып тоташучы изге кешеләр каберенә зиярат кылу йоласы булуы да мәгълүм. Баласызлыктан интеккән хатын (үзе генә яки ире белән бергә) «Изгеләр өсте», «Изгеләр зираты» яки «Әүлия кабере» дип аталган җиргә барып, Аллаһтан бала бирүен ялвара. Дога кылуга өстәп, кабер, изге агач яки зират тирәли әйләнү, аларны җеп белән әйләндереп алу, чардуганга яки кабер өстендәге агачка сөлге, тасма бәйләү, шушы тирәдә корбан чалу кебек гамәлләр дә башкарыла [Брусько, 2019, б. 487]. Кардәш төрки халыклар эпосында бик еш сурәтләнгән әлеге гадәт татар дастаннарында да телгә алына, мәсәлән, «Чура батыр» сюжетына корылган дастаннарда, шушы ук сюжетка риваятьләрдә бу мотив элементларына юлыгырга мөмкин. Әмма башка төрки халыклар иҗатында сакланган вариантлар белән чагыштырсак, татар дастаннарында кабердән, изгеләрдән сорауның шулай ук Аллаһка мөрәҗәгать белән алышынган булуы табигый. Шулай булуга карамастан, изге кешеләр каберенә зиярат кылу йоласының халкыбызның йолалар системасында үз урынын тотуын безнең материаллар бик ачык күрсәтә. Дастаннарда, мәсәлән, «Чура батыр»да («Чура батыр хикәяте») исә әлеге мотив Чурага юлында изге карт очрау сюжетында гына бераз сакланып калган диярга мөмкин [Татар халык иҗаты. Дастаннар, б. 108–118]. Дастанның татар вариантындагы бер-ике мәгълүмат һәм башка халыктагы версияләре аша гына, шулай ук халыкның көнкүреш йоласында әле дә яшәп килгән кайбер билгеләр аша гына бу күренешне тулаем күз алдына китерергә мөмкин.

Романик дастаннардан «Кузы Көрпәч белән Баян-Сылу», «Таһир белән Зөһрә» вариантларында чагылыш тапкан төш күрү, күргән төшне юрау мотивына күз салыйк. «Таһир белән Зөһрә»нең билгеле бер вариантында ханның яраткан вәзире төшендә, Аллаһ ярдәме белән, үзенең һәм ханның балалары туачагын күрә һәм төшен ханга сөйли. Шуннан алар, шатланып, балаларын малайлар я кызлар булганда – дуслаштырырга («ул булсалар, ук-санайлары бер булыр, кыз булсалар, орчык-энәләре бер булыр»), берсенеке малай, икенчесенеке кыз туганда – өйләндерергә вәгъдә бирешәләр [Татар халык иҗаты. Дастаннар, б. 206–247]. Әлеге вәгъдәләшү күренешен күп кенә төрки халыкларның, шул исәптән, татар халкының туй йоласы комплексына караган балаларны сабый чакта ук ярәштерү гадәте белән бер яссылыкта карап булыр иде. Халык телендә «колак тешләтү» дип аталып йөртелә торган әлеге йола гадәте ир һәм кыз балалары булган гаиләләрнең киләчәктә туганлашу теләге белән үткәрелгән. Ике ят нәселнең кушылуы элек-электән ыру, кабилә вәкилләре, туган-тумача белән киңәшләшүгә корылган гаять җитди һәм җаваплылык таләп иткән мәсьәләләр рәтенә кергән [Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр, б. 372]. Күптәннән дустанә мөнәсәбәттә булган һәм бербересендә ышаныч уяткан ике нәселнең туганлашырга теләве артык сораулар тудырмый һәм табигый хәл буларак кабул ителә. Әлбәттә, мондый килешү рухи-әхләкый мәнфәгатьләрне генә кайгыртып калмыйча, көнитеш-көнкүреш хәлне ныгыту, мал-мөлкәтне арттыру бурычын да үтәгән. Киләчәктә кыз ягы кире уйласа, егет ягына калым бәясенчә байлык түләргә мәҗбүр булган.

Дастаннарга килгәндә, бер очракта, биргән вәгъдәне тотмыйча, бер ханның башка җиргә күчеп китүе («Кузы Көрпәч белән Баян-Сылу»), икенче очракта ханның кызын ятим калган вәзирнең улына бирмәскә хәл итүе («Таһир белән Зөһрә») – сюжетны алга таба үстерү өчен кулланылган алым. Тормышта исә әсәрдә тасвирланган вакыйгалар чынбарлыкка тулысынча да, өлешчә генә дә туры килергә мөмкин. Күпчелек очракта без мондый вакыйгаларның уңай хәл ителүен күзәтә алабыз дияргә урын бар.

Дастаннарда төш күрү мотивы вакыйгаларны алдан күрү, киләчәкне искәртү максаты белән дә кулланыла. Әйтик, «Кузы Көрпәч белән Баян-Сылу»да ярәшелгән ярын эзләү өчен юлга кузгалган Кузы Көрпәчкә әнисе төш күреп алу ниятен белдерә. «Тукта! Мин төш күреп алам синең китәсе юлыңа!», – ди ул аңа. Баш астына мендәр салып, бик озак йокыга тала. Уянгач, төшендә улының юлында очраячак каршылыкларны күрүе турында сөйли, шул рәвешле, улын уеннан кире кайтармакчы була. Ләкин Кузы Көрпәч кылган ниятеннән кире кайтмый һәм юлга чыга [Татар халык иҗаты. Дастаннар, б. 136–145].

Әсәрдә урын алган әлеге күренеш борынгы чорлардан ук билгеле фал ачу ысулларының берсе булып тора [Әхмәтҗанов, б. 30]. Ул гасырлар дәвамында халык көнитешендә кулланылып килгән һәм үз көчен әле дә югалтмаган. «Төшлек салу» дип аталган бу гадәтнең

тотрыклы булуын безгә соңгы елларда оештырылган экспедицияләр материаллары да күрсәтә. Гадәттә «төшлек салу»ны кешенең күңелен борчыган мәсьәләне, бигрәк тә кеше язмышын ачыклау өчен кулланалар. Мәсәлән, безнең очракта аны авыру баланың ни сәбәпле елавын, борчылуын белү өчен башкаралар. Төш салучы кеше «бөтен кеше карап торган вакытта кулын баш астына куеп, алъяпкычы белән битен каплый да, караваг кырыена ятып, ун-унбиш минут җоклап ала. Аннан соң торып баса, шулайрак булды дип, авыруын әйтә. Шуннан ничек дәваларга икәнен әйтә. Аның үзенә күрә дәвасы бар. Догасы бар аның» [Төшлек салу]. Күп очракта, кагыйдә буларак, мендәр астына төш юрау китабы салына [Әхмәтҗанов, б. 31].

Эпоста төш күрү мотивы аерым шәхеснең киләчәк язмышын ачыклау өчен генә түгел, ә җәмгыятьнең, ыру-кабиләнең, ил-дәүләтнең дә киләчәген билгеләү өчен файдаланыла. Моны без «Идегәй» дастаны мисалында күрә алабыз. Идегәй күргән төшләр тарихи вакыйгаларның барышын, юнәлешен, әһәмиятен мөһим үзгәрешләргә дучар иткән [Урманче, б. 133].

Күзәтүләрне дәвам итеп, кайбер дастаннарда урын алган тагын бер үзенчәлекле мотивка тукталыйк. «Түләк һәм Сусылу» дастанының бер вариантында анасының югалган улын тану эпизоды борынгы ышануларга нигезләнгән, этник күзаллауларны чагылдыра торган күренеш булуы белән кызыклы. Улын күргән ананың көтмәгәндә күкрәгеннән сөт ага башлый. Халык ышанулары буенча, ана сөте изге сөт булып санала һәм магик көчкә ия дип күзаллана. Бу, үз чиратында, аны күптөрле йола гадәтләре барышында, дәвалау-имләү практикасында кулланырга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, ана сөте белән яңа туган баланың аркасына чыккан чәнечкеләрне бетерәләр, күзе авырткан кешенең күзенә ана сөте тамызып дәвалыйлар, имезгән ананың каргышыннан куркырга кушалар. «Ана каргышы төшәр иде, ана сөте җибәрми» [Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр, б. 237] мәкаленнән ана сөтенең нинди зур көчкә ия булуын, хәтта ананың үз каргышына да калкан булып тора алуын күрәбез. Ә инде имезүче хатын чит баланы имезсә, ул әлеге бала өчен «Сөт анасы»на әверелә. Бала да, үз чиратында, шулай ук «чит» баладан «үз» балага әйләнә, гаиләдәге башка балаларның бертуганы булып исәпләнә башлый. Әлеге ышану халыкта бүгенге көндә дә яшәп килә. Бер ананы имеп үскән балаларга (төрле җенестән булган очракта) киләчәктә гаилә корырга ярамый дигән тыю нәкъ менә шушы ышануга барып тоташа [Сөт анасы]. Әлеге мисаллар ана сөте төшенчәсенең халык акылында тирән мәгънәгә ия булуын һәм аның белән бәйле ышануларның бүгенге көндә дә тотрыклы икәнлеген күрсәтә.

Дастаннар – халкыбыз тарихында, аның рухи-мәдәни һәм көнкүреш тормышында әһәмиятле вакыйгаларны чагылдырган кадерле ядкярләребез. Борынгы ышануларга, халык күзаллауларына нигезләнгән йолаларны һәм гореф-гадәтләрне тасвирлаулары белән алар безнең өчен гаҗәеп дәрәҗәдә кыйммәтле. Мәкаләдә телгә алынган

йола күренешләренең, мотивларның дастан битләрендә генә калмыйча, бүгенге көн халык тормышында да актив кулланылышта булуы аеруча әһәмиятле. Әлеге мәсьәләләрне фольклористика фәне югарылыгында махсус өйрәнүгә ихтыяҗ бар. Дастаннарыбызны аларда этник йолалар чагылышы җәһәтеннән барлауның потенциалы да шактый зур, бу исә әлеге юнәлештә эзләнүләрне тагын да киңәйтү зарурлыгын ассызыклый.

### Әдәбият

*Әхмәтҗанов М.И.* Татарлардагы кайбер көрәзә ысуллары // Түгәрәк уен. 2019. № 2. Б. 30–31.

*Бакиров М.Х.* Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары. Казан: Мәгариф, 2001. 343 б.

*Брусько З.М.* В круге жизни. Казань: Ихлас, 2013. 223 с.

*Брусько З.М.* Ритуальные практики в родильной обрядности татар // Финно-угорский мир в полиэтничном пространстве России: культурное наследие и новые вызовы. Материалы VI Всероссийской научной конференции финно-угроведов. (4–7 июня 2019 г.) Ижевск: Изд-во Анны Зелениной. С. 484–487.

*Закирова И.Г.* Төрки дастаннарда йола һәм ышанулар // Гуманитарные науки: поиски и достижения. Казан: Фикер, 2004. Б. 32–35.

*Мухаметзянова Л.Х., Миннуллин К.М.* Общие традиции в эпосе и семантике обряда сорэн у татар // Вестник Северо-Восточного федерального университета им. М.К. Аммосова. Серия: Эпосоведение. 2021. № 4 (24). С. 5–14.

*Мөхәммәтҗанова Л. Х.* Дөнья цивилизациясендә татар дастаннары. Казан: ТӘһСИ, 2018. 280 б.

*Путилов Б.Н.* Эпос и обряд // Фольклор и обряд. Обряд и обрядовый фольклор. Ленинград: Наука, 1974. С. 76–81.

*Путилов Б.Н.* Героический эпос и действительность. Л.: Ин-т этнографии им. Н. Н. Миклухо-Маклая, 1988. 223 с.

Сөт анасы / Авторның шәхси архивы. 2014 елның 26 сентябрендә Татарстан Республикасы Алексеевск районы Югары Татар Майнасы авылында Миндубаева Әлифә Әгъзәм кызыннан (1956 елгы) З.М. Брусько тарафыннан язып алынды.

Татар халык иҗаты. Дастаннар / Томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы Ф.В. Әхмәтова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 384 б.

Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр / Томны төзүче, кереш мәкаләне язучы искәрмәләр әзерләүче Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 591 б.

Төшлек салу / Авторның шәхси архивы. 2004 елның 7 июлендә Татарстан Республикасы Әтнә районы Күәм авлында Галиев Мөбарәк Хөснетдин улыннан (1930 елгы) Арикеева (Брусько) З.М. тарафыннан язып алынды.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. 3 т. (С–Я). Казан: Мәгариф, 2011. 199 б.

***Брусько Зәлия Мансур кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, «Татар ядкярләре» татар халкының милли-мәдәни традицияләрен торгызу һәм үстерү үзәгенең халык иҗаты материаллары белән эшләүче белгече (Казан)*

УДК 070

*Ә.Т. Сибгатуллина*

# «ИДЕЛ-УРАЛ» ЖУРНАЛЫ (1955)

В 1955 году в Стамбуле начал выходить ежемесячный журнал «Идел-Урал» на турецком и английском языках. Учредителем и главным редактором был татарский эмигрант Маджит Сакмар (1988–1978), бывший офицер турецкой армии и участник войн на Балканах и Первой мировой, а также национально-освободительной борьбы турецкого народа. После смерти Гаяза Исхаки (1878–1954) именно он возглавил в Турции национальный центр «Идел-Урал». Задуманный как издание по культуре народов Волго-Уральского региона журнал успел выйти лишь в двух номерах, в статье кратко анализируются материалы обоих номеров. Особо важным является специально изданное в виде книжки приложение к первому номеру журнала, посвященное кончине Гаяза Исхаки. В нем о жизни и творчестве писателя, о встречах с ним своими воспоминаниями поделились видные деятели-эмигранты из Азербайджана, Северного Кавказа, Америки, Финляндии.

**Ключевые слова:** татарская периодическая печать, татарская эмиграция, журнал «Идел-Урал», Маджит Сакмар, Гаяз Исхаки.

In 1955, the monthly magazine *Idel-Ural* began to appear in Istanbul. The magazine was published in Turkish and English. Its founder and editor-in-chief, Majit Sakmar (1988-1978), was a Tatar emigrant and former officer of the Turkish army. Sakmar participated in the wars in the Balkans, the First World War, and the national liberation struggle of the Turkish people. After the death of Gayaz Iskhaki (1878–1954), it was he who headed the national centre «Idel-Ural» in Turkey. The eponymous journal was conceived as a publication on the cultures of peoples in the Volga-Ural region but appeared in only two issues. The current article briefly analyzes materials published in these issues. Of particular importance is a special supplement to the first issue, printed in a book form and dedicated to the death of Gayaz Iskhaki. In it, prominent emigrants from Azerbaijan, the North Caucasus, America, and Finland shared their memories of their meetings with the writer.

**Key words:** Tatar periodicals, Tatar emigration, «Idel-Ural» magazine, Majit Sakmar, Gayaz Iskhaki.

Төркиядә яшәгән күренекле Казан татарларыннан калган тарихи-әдәби мирасны һаман җитәрлек дәрәҗәдә табып-өйрәнеп бетерә алмыйбыз әле. Мәсәлән, XX гасыр уртасында Мәҗит Сакмар тарафыннан чыгарыла башлаган, ләкин бүгеннәрдә генә очраклы рәвештә кулыма килеп кергән «Идел-Урал» исемле журнал турында, бик күпләр кебек, минем дә ишеткәнем юк иде. Шул уңайдан әлеге хәбәрне биргән һәм материаллар белән тәэмин иткән азәрбайҗан галим-эзтабарларыннан «Чапар» журналының баш редакторы Дилкам Әхмәд әфәндегә зур рәхмәтемне белдерәм.

«Идел-Урал» журналы 1955 елның май аенда Истанбулда Осман-бәй матбагасында төрек һәм инглиз телләрендә бер мәдәни җыентык –



«Идел-Урал» журналының
1 нче саны

айлык «культур мәҗмугасы» рәвешендә чыга башлый. Хуҗасы һәм баш редакторы булып Мәҗит Сакмар әфәнде (1888–1978) тора. Ни кызганыч, шушы көнгә кадәр М. Сакмар хакында да мәгълүматларыбыз бик чикле, Кырым татарларының Төркиядә чыккан «Әмәл» журналының 1978 елгы санында бирелгән некрологта аның Казанга бәйле Сакмар авылында (хәзерге Башкортстанда?) туу, 1905 елда Истанбулга күчеп килүе, хәрби мәктәпне бетергәч, офицерлар хәзерли торган уку йортында, аннаң соң хәрби Академиядә белем алуы хәбәр ителә. Балканнарда, аннары Беренче бөтендөнья сугышында катнашуы, төрек халкының милли-азатлык көрәшендә үзеннән өлеш кертүе турында әйтелә. Төркия армиясендә беренче һава көчләре оешмасын коручылардан булган М. Сакмар хәрби министрлыкта һәм генераль штабта хезмәт итеп, полковник дәрәҗәсендә лаеклы ялга чыккан [İdil-Ural Millî Merkezi Başkanı Mecit Sakmar, 1978, s. 16]. Безнең мәгълүматларыбыз буенча, 1943 елда Генштабта хезмәт иткән вакытта «Һава географиясе» (Hava Cografyası; Ankara) исемле бер китап та бастырган булган. 1954 елдан алып вафатына кадәр Гаяз Исхакыйдан мирас булып калган «Идел-Урал милли мәркәзен» җитәкләгән. Хатыны Алия ханым (1902–1978) да актив иҗтимагый тормыш алып барган, уллары профессор Әхмәт Ата Сакмар (1941–2021), адвокат һәм галим буларак, зур дәрәҗәләргә ирешкән, халыкара хокук һәм дипломатия темалары буенча Европада һәм Төркиядә китаплар бастырган.

Монда кыскача гына «Идел-Урал милли мәркәзе» идарәсенең ни сәбәпле М. Сакмарга бирелүе турында да әйтеп китү урынлы булыр. Яшь япон тикшеренүчесе Р. Оно 2011 елда очраклы рәвештә букинистларда сакланып калган бер уникаль коллекция тапкан һәм бу хакта язып та чыккан иде [Ono, 2013]. Бу табылдык тупланмада, нигездә, мөһаҗирлектә яшәгән үзбәк зыялысы доктор Габделваһаб Октайга килгән (1904–1968) хатлар булып, алар арасында Г. Исхакыйның соңгы көннәре белән бәйле язышмалар безнең өчен аеруча әһәмияткә ия. Кызы Сәгадәт Чагатайның этисенең сихәтлеге, аңа бирелгән дарулар, аны ничек каравы турында Г. Исхакый белән дус булган Г. Октайга хәбәр биреп баруы Габделваһаб әфәндене Төркиядәге бик күп мөһаҗирләрнең «үз врачы» булуын күрсәтеп тора. Аңа язылган хатлар арасында Г. Исхакыйның ярдәмчесе булган Мирхуҗа Әрәлинең[1]

[1] Мирхуҗа Хәсән Әрәли (1896–1958) – генерал. Уфада мәдрәсәдә һәм гимназиядә белем алган. 1915 елдан Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан, 1932 елда генерал-майор чины алган, Кызыл Армиянең 60 нчы һәм 275 нче дивизияләре белән идарә иткән. 1941 елда немецларга әсир төшкәч, туган илгә кайтмаган, 1949 елда Төркиягә килгән һәм Г.Исхакый янында эшләгән [Ono, 2013, s. 572].



«Идел-Урал» журналының 1 нче санына кушымта

7 июльдә, ягъни Г. Исхакыйның вафатына 15 көн кала, язылган хатында исә әдипнең милли эшләр белән соңгы көннәренә кадәр шөгыльләнүе белдерелә һәм үз урынына «Идел-Урал милли мәркәзен» җитәкләрдәй кеше табарга тырышуы аңлашыла. Бу урынга беренче кандидат буларак, танылган инженер-нефтьче Кәмал Локман[1] күрсәтелә, ләкин Төркиядә закон буенча дәүләт чиновникларына иҗтимагый оешмалар белән җитәкчелек итәргә ярамаганга, бу кандидатура төшеп кала, аннан соң Нурулла Ата[2] кандидатурасы килә, тик ул икеләнүен белдергәч, отставкадагы полковник Мәҗит Сакмарга мөрәҗәгать итәләр һәм ризалыгын алалар [Ono, 2013, s. 572].

Биографиясеннән күренгәнчә, М. Сакмар «Идел-Урал» журналын Гаяз Исхакыйдан Төркиядәге татар милли хәрәкәте җитәкчелеге идарәсен үз кулына алыр-алмас чыгара башлаган дияргә була: журналның 1 нче саны 1955 елның 19 маенда басыла, әгәр аны чыгару өчен рәсми язышмаларны, редакция портфелен туплау чорын искә алсак, Г. Исхакыйның вафатыннан (22 июль, 1954) соң узган вакыт шуңа туры килә. Моны исбатлый торган бик тә әһәмиятле тагын бер чыганак бар: ул да булса, Г. Исхакыйның вафатыннан соң чыккан «Милли мөҗаһит вә милли әдип Гаяз Исхакый» исемле җыентык [Milli Mücahit, 1955]. Истанбулда 1955 елда Осман бәй матбагасында басылган 49 битлек әлеге китапчыкның алгы битенә болай дип язылган: Бу – «Идел-Урал» мәҗмугасының беренче санына кушымтадыр. Мәҗмуга белән бергә бирелер, аеруча акчага сатылмас». Мәҗмуганың тышлыгында «Гаяз Исхакыйның соңгы рәсеме» куелган, икенче биттә рәхмәт сүзләре язылган: әдипнең вафатыннан соң телеграмма җибәреп, хат юллап, кайгы уртаклашкан Финляндия, Америка, Япония, Төркия, Европа илләрендәге дусларына, Украина, Белоруссия,

---

[1] Кәмал Локман (1899–1976) Казакъстанның Казалы шәһәрендә туган, башлангыч белемне шунда алганнан соң, гаиләсе белән Госманлы Төркиясенә күченгән. Урта мәктәпне бетергәч һәм армия хезмәтен тәмамлагач, Франциягә киткән, Гренобль политехника институтында, аннан соң Страсбургта нефтьчелек буенча югары уку йортын тәмамлаган (1927). 1929 елда Төркиягә кайтып, төрле дәүләт оешмаларында нефтьчелек буенча эшләгән, аеруча җир асты файдалы казылмаларын эзләү өлкәсендә фәнни эшләр алып барган һәм Төркиядә нефть сәнәгате формалашуга әһәмиятле өлеш керткән.

[2] Нурулла Ата (1887/88–1974), педагог. Самарада туган, 1909 елда Истанбулга килеп белем ала һәм башлангыч сыйныф укытучысы дипломына ия булган, 1913 елдан мәктәптә укыта башлаган. Армиядә хезмәт иткәннән соң, Кавказда, Азәрбайҗанда укыткан, 1923 елдан яңадан Истанбулга кайтып, профессиясе буенча эшләгән, 1952 елда пенсиягә чыкса да, төрле мәктәп һәм мәгариф оешмаларында хезмәт иткән.

Польшадагы фикердәшләренә редакция рәхмәт белдерә, диелгән. Җыентыкны М. Сакмарның «Беренче тәэсир» исемле язмасы ачып җибәрә, анда ул әдип белән беренче мәртәбә 1911 елда Истанбулның Нур-ы Госмания мәчете буендагы бер кунакханәдә очрашуын әйтә, «Йосыф Акчура белән икесен күргәндә алган тәүге тәэсирем гомер буе үзгәрмәде, 44 елдан соң яңадан күрешкәндә дә гел шулай калган кебек тоелды», дип яза автор.

«Бер мөҗаһитнең тормышы» исемле икенче язманың авторы М. Әрәли Исхакыйның биографиясен, язучылык һәм журналистлык эшчәнлеген өч өлешкә бүлеп, укучыларга шактый җентекле мәгълүмат бирә. Өченче язма – «Гаяз Исхакый» – Кавказ эмигрантларыннан Сәид Шамил[1] тарафыннан язылган. Аннан соң Азәрбайҗанның бөек каһарманы Мәхмәт Әмин Рәсүлзадәнең[2] «23 июль, 1955, Әнкара» датасы куелган «Аркадашым Гаяз» исемле мәкаләсе килә. «Юл аркадашы» псевдонимы астында бирелгән язмада Г. Исхакыйның Мюнхенга ясаган сәяхәте, мөһаҗирлектәге рус булмаган халыкларның үзара мөнәсәбәтләре турында хәбәр ителә.

«Мәрхүм Гаяз бәйне күреп-танышырга Аллаһ миңа насыйп итмәде» дип башланган язманың авторы – Нью-Йорктан Хәмит Рәшит. Ул Г. Исхакыйны «ватанымда өмет чаткылары тудырган символ» дип атый, әсәрләренең совет хөкүмәте тарафыннан тыелуын, хәтта бу чорларда бик популярлашкан «Зәңгәр шәл» музыкаль комедиясен К. Тинчурин яза алмас, чөнки авыл тормышын бик белми, бу – мөгаен, Г. Исхакыйның эшедер дип, халык арасында тыярга омтылдылар, дигән кызык фикер дә китерә. «Икенче бөтендөнья сугышы мине дә, меңнәрчә Идел-Урал егетләре кебек, Германиягә чыгарып атты», дип үзе хакында да бераз мәгълүмат бирә автор [Milli Mücahit, 1955, s. 37–38]. 70 яше тулу уңаеннан Г. Исхакыйга котлау хаты язып, соңыннан аның белән даими хәбәрләшү мөмкинлеге тапкан Х. Рәшит әдипнең сугыштан соң Германиядә калган бер төркем татарның АКШка күчәргә карар бирүен хуплавын да белдерә.

«Истә тотам» исемле язманың авторы – ингуш халкының күренекле улы Вассан Гирәй Җабаги[3] Г. Исхакый белән дүрт тапкыр очрашу-күрешүен, иң соңгысының Варшавада яшәгәндә шактый озак дәвам итүен, әдипнең аларда калуын, балаларына дин дәресе бирүен зур ихтирам хисләре белән искә ала.

---

[1] Мөхәммәд Сәид Шамил (1901–1981) – Кавказның атаклы шәхесе Шәех Шамилнең оныгы, күренекле җәмәгать эшлеклесе, Кавказ мөһаҗирләренең лидеры.

[2] Рәсүлзадә Мәхмәт Әмин (1884–1955) – күренекле азәрбайҗан дәүләт, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, журналист һәм язучы. 1922 елдан эмиграциядә төрле илләрдә яши, татар мөһаҗирләре белән якын элемтәдә тора.

[3] Вассан Гирәй Җабаги (Джабагиев) (1882–1961) – ингуш халкының күренекле сәяси-иҗтимагый эшлеклесе, публицист, Европадагы Кавказ эмиграциясенең күренекле вәкиле. 1938 елдан соң Төркиядә яши.

«Халкымның тәрбиячесе» исемле язманың авторы Һидәят Яшин[1] Исхакыйның психология һәм педагогиканы яхшы белүенә басым ясый һәм милләтнең әхлагын яхшырту юнәлешендәге эшчәнлегенә, халкының бәйсез киләчәге өчен алып барган көрәшенә туктала.

М. Вәли[2] имзасы астында басылган соңгы язмада Г. Исхакыйны күмү мәрасимендә катнашкан кешеләрнең сөйләгән сүзләре китерелә: Солтан Гариф, Ибраһим Бадай, төркестанлы Аман Бәрдимурат, азәрбайҗан Фатали-бәй, әрмән Тумасьян, калмык Шамба Балина[3], белорус Кабиш, украин Довгал, кырым татары И. Кырымәл[4] һ.б. мәрхүм турында изгелек белән генә искә алганнар.

Югарыда әйтелгәнчә, бу язмаларның барысы да «Идел-Урал» журналына кушымта итеп таратылган китапчыкта бирелгән. Инде хәзер журналның үзендәге материалларга күз салыйк. Кызганычка каршы, «Идел-Урал» бары тик ике генә сан чыгып калган, ни сәбәплеябылган, төгәл билгеле түгел. Беренче сан 1955 елның 19 маенда – Төркиядә яшьлек һәм спорт бәйрәме буларак котлана торган һәм Ататөрекне искә алу көнендә чыкканга, тышлыкта Ататөрек һәйкәленең рәсеме урнаштырылган һәм «Ататөрек бары тик Анадолу төрекләренең түгел, бөтен төркиләрнең Атасы» дип язылган. Эчтәлеккә күз салу белән, журналның ике телдә: төрек һәм инглиз телләрендә чыгарырга планлаштырылганлыгы аңлашыла: сигез төрекчә язманың дүртесе инглизчәгә тәрҗемә итеп бирелгән. «Ни өчен чыга?» дип исемләнгән кереш мәкалә журналның оешуы һәм алга куйган максатлары хакында сөйли: дөньяда барган тарихи вакыйгалар эчендә Идел-Урал мәдәниятенең юкка чыгуына юл куймау, төрки халыкларның уртак мирасын, тарихын саклап калырга омтылу, И. Гаспралының «Телдә,

---

[1] Һидәят Яшин (1894–1978) – педагог. Казанда туган, Укытучылар мәктәбендә укыган. Укуын бетермичә, фронтка алынган, Беренче бөтендөнья сугышында немецларга әсир төшкән. Соңрак Төркиягә килгән. 1915 елда Габдеррәшид Ибраһим һәм Галимҗан Идриси тәэсирендә төрек армиясенә кушылып, Месопотамия фронтында сугышкан. Сугыштан соң педагогик белемен арттырып,Артвин шәһәрендә эшләгән. Төркиядә тыелган «Яңа милли юл» журналын яшерен тарату эше белән шөгыльләнгән [Ono, 2013, s. 577].

[2] М. Вәли – Мостафа Вәли Айтуган (1907–1965), гаскәри һәм язучы. Алабуга шәһәренә якын авылларның берсендә туган. 1925–1928 елларда Казанда хәрби мәктәптә укыган, соңрак Мәскәүдә М. Фрунзе исемендәге хәрби академияне (1939–1941) бетергән. 1941 елда совет-фин сугышына майор буларак катнашкан, финнарга әсир төшкәч, Германиягә киткән һәм үз теләге белән Идел-Урал» легионына кергән (1943–1945), татарча газета чыгару эшенә өлеш керткән. Сугыштан соң Мюнхенда яшәгән, 1953 елда Идел-Урал милли мәркәзенең Германиядәге вәкиле булган, «Милли байрак» (1953–1954) газетасын оештырган, тик аның ике генә саны чыгып калган.

[3] Шамба Балинов (псевдоним Галдана) (1894–1959) – эмиграциядәге калмыкларның лидеры, журналист. Дондагы калмык кенәзе гаиләсеннән. Революциядән соң Берлинга күчеп киткән, 1928 елда калмык эмигрантлары оешмасы Khalmag Tanchin Tug ны нигезләгән. Эмиграциядәге күп кенә газета һәм журналларда язышкан. Бөек Ватан сугышы чорыында Германиядә яшәгән. 1959 елда Америкада вафат булган.

[4] Мостафа Эдигәй Кырымәл (1911–1980) – кырым татарларының мөһаҗәрәттәге күренекле лидерларыннан берсе.

фикердә, эштә берлек» шигаренә таянып эш итү, эмиграциядә яшәгән милләттәшләргә бу байлыкны таныту, аларга мәдәни һәм иҗтимагый ярдәм күрсәтү, чит илләргә таралган зыялыларыбыз белән элемтә урнаштыру. М. Сакмар тагын болай ди: «Шулай ук, төрек армиясенең элеккеге офицеры буларак, армиягә һәм ватаныма язуларым белән булса да, хезмәтемне дәвам иттерүне үземнең бурычым дип саныйм». Автор Идел-Урал буендагы сугышчылар турында да яңа материаллар бирергә омтылуын әйтә.

«Идел-Урал» дип исемләнгән икенче мәкаләнең иясе М.С. дип кенә бирелсә дә, моның Мәҗит әфәнде үзе булганлыгы әллә ни шик тудырмый. Ул Идел, Җаек, Агыйдел елгалары турында гомуми белешмә бирә, хәтта татарча бер җырдан үрнәк тә китерә. Казан ханлыгы тарихы, рус кенәзлекләре белән мөнәсәбәтләрне истә тотып, алардан гыйбрәт алган хәлдә, хәзерге заманда Идел-Уралдан чыккан халыкларның үзара бердәмлеген ныгыту, матди-мәгънәви, мәдәни көчен арттыруның бик кирәкле булуын ассызыклый. Аннан соң шул ук М.С. имзасы белән «Казанның соңгы маликәсе – сөелгән Сөем хан Бикә» исемле ике битлек шигырь урнаштырылган: Сөембикәнең гүзәллеге, ат өстендә ауга чыгулары, рус авына төшкән ире Җан Гали образы матур гына тасвирланган.

Чираттагы язманың авторы – М. Сакмарның дусты генерал Пәртәв Дәмирхан (1878–1964), кайчандыр рус-япон сугышында инспектор-күзәтүче булып эшләгән, япон тарихы буенча хезмәтләр язган кеше. Ул язмасында Япония белән төрки халыклар арасындагы тугандашлык җепләре, ислам дине һәм япон культурасы арасындагы багланышлар хакында сүз башлый, язма киләсе санда дәвам итәчәк, диелә. Япония темасын дәвам иттереп, М. Сакмар үзе дә «Японияләге идел-ураллылар: дин һәм миллият» дигән темага материаллар китерә.

Аннан соңгы язма «Совет Армиясендә сержантлар тәрбияләү мәсьәләсе» дип атала, авторы исемен күрсәтмичә, «Мөлтәче» (эмигрант) дип кенә куйган. Ике санда чыккан бу мәкаләдә яңа гына Совет Армиясенә алынган егетләрнең, нигездә, колхоз басуларында бертуктаусыз һәм авыр шартларда эшләп үскән авыл балалары булуын әйткәннән соң, колхозлардагы нинди эшкә ничә эш көне (трудодень) язылуын җентекләп аңлата: сау-сәламәт ир-егет ел буена 250 эш көненә ия булса, колхоз рәисе исә, басуда эшләмәсә дә, 2250 эш көненә хуҗа дип, эш хакын түләүдәге тигезсезлекне күрсәтә.

Мирза Бала[1] үз мәкаләсендә Азәрбайҗан милли бәйсезлек хәрәкәтенең идеологы һәм лидеры Мәхмәт Әмин Рәсүлзадәнең 6 март көнне вафат булуын хәбәр итә һәм аның эшчәнлегенә кыскача анализ ясый.

«Финляндиядәге Идел-Урал төркиләре» исемле язмада яңа чыккан басмаларга кыска гына күзәтү ясала.

[1] Мирзабала Мәмәтзадә (1898–1959) – азәрбайҗан публицисты һәм язучысы. «Мусават» партиясенең рәисе (1955–1959). Европадагы азәрбайҗан эмиграциясенең күренекле вәкиле.

«Идел-Урал өлкәсенең җир асты байлыклары» исемле мәкаләдә бу төбәктә чыгарыла торган нефть ятмалары хакында мәгълүмат бирелә. Бу соңгы язмаларның да дәвамы киләсе саннарда чыгачагы хәбәр ителә.



«Идел-Урал» журналының 2 нче саны

Икенче санның тышлыгына Плевна каһарманы Гази Осман пашаның (1832–1900) портреты куелган. Беренче санда башланган П. Демирхан, М. Бала, «Мөлтәче» язмаларының дәвамы янында, бу санда иктибасларның (башка чыганаклардан алынып, тәрҗемә итеп бирелгән) язмаларның шактый булуы күзгә ташлана, мәсәлән, «Алтайлы кавемнәрнең язмышы», «Икенче Плевна сугышы», «Финляндия төркиләре», «Төрки казакълар хөрриятне ничек сайлады?», «Меото хәзәрләре» исемле язмалар башка илләрдә (нигездә, инглиз телендә) чыккан язмалардан алынган.

Оригиналь әсәрләрдән бу санда игътибарга лаек язма – М.С. имзасы белән язылган «Идел-уралл шәһит ителгән яшь шагыйрь Әхмәт Сима» исемле хәбәр һәм әлеге шәхеснең «Табынырдым» (Табына идем) исемле татарча шигыре. 1940 елның май аенда 23 яшендә үтерелгән Ә. Симаның соңгы шигыреннән берничә юлын без дә биредә китерүне кирәк таптык:

Булган, диләр, татар гаскәренең
Тугай аты җирне таптаган,
Алтын Урда Урал тауларыннан
Карпатларга кадәр атлаган.

Ул дәвернең кешеләре, имеш,
Нык булганнар тимер-корычтан.
Урыс түгел, дөнья калтыраган
Кама бүрек, кыңгыр кылычтан.

Ул кавемнең дәһшәт чәчеп торган
Башкаласын Сарай дигәннәр,
Күп патшалар Татар ханнарына
Тез чүккәннәр, башын игәннәр...

Изге милләт, ике юл бар, сайла:
Я мәңгегә бетеп калырга,
Я яңадан кулыңа булат тотып,
Ирекне урыстан тартып алырга!

[İdil-Ural Kültür Mecmuası, № 2, s. 20]

Бу санда чыккан язмаларның бары тик икесе генә инглиз теленә тәрҗемә ителгән.

Журналның башка саннары нигә чыкмаган? Әллә чыгып та, берәр рәсми тыюга дучар булганмы? Әлегә без бу хакта мәгълүмат таба алмадык. Ләкин өченче санга «дәвамы бар» дип язылган материалларның булуы, редакциянең басма эшен туктатырга җыенмавын күрсәтеп тора. Шул ук вакытта күпчелек материалны М. Сакмар әфәнденең үзе әзерләве аның янында якын фикердәшләре, көрәштәшләре аз яки бөтенләй булмавына ишарә итә кебек. Ничек кенә булмасын, әлеге басманың чит илләрдә яшәгән татар-башкорт мөһаҗирләренә, аларның балаларына туган халкыбызның тарихын һәм мәдәниятен таныту максатында оешкан булуы аңлашыла. «Идел-Урал» журналы чит илләрдәге татар вакытлы матбугатының бер парчасы булып санала ала һәм шул уңайдан җентекле өйрәнүгә лаек дип саныйм.

**Әдәбият**

İdil-Ural Kültür Mecmuası. İstanbul. № 1. 19 Mayıs 1955; № 2. 19 Haziran 1955.

Milli Mücahit ve Milli Edip Ayaz İshaki. İdil-Ural mecmuasının 1.sayı ilavesidir. 1955.

İdil-Ural Millî Merkezi Başkanı Mecit Sakmar Vefat Etti // Emel. 1978. № 107. S. 16.

Ono, Ryosuke. Muhaceretteki Bir Özbek Türkü'nün Mektuplarına Göre Türk Dünyası – Abdulvahap Oktay ve Mektupları//Ankara Üniversitesi Dil ve Tarih-Cografya Fakultesi Dergisi, 2013, № 2 (53). S. 563–584.

***Сибгатуллина Әлфинә Таһир кызы**,*
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Росссия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 28

*Г.М. Дәүләтшин*

# БОЛГАРЛАРДА ИСЛАМ ТАРАЛЫШЫ ЭТАПЛАРЫ

Основным направлением распространения ислама является Центральная Азия (Мавераннахр), тесные связи с которой тюркские племена Северного Кавказа установили еще в хазарское время. Эта традиция продолжается и развивается и на Волге. Постепенно Центральная Азия с центром в Бухаре и Волжская Булгария составляют единый культурно-религиозный ареал, основой которого является ислам ханафитского толка.

922 год, весной которого на Волгу прибыло посольство из Багдада, вошел в историю как год официального признания Халифатом Волжской Булгарии в качестве одного из государств как части мусульманской цивилизации.

С распространением ислама волжские булгары были включены в мусульманское богословие, просвещение и науку мусульманского мира.

**Ключевые слова:** булгар, ислам, ханафит, Ибн Фадлан, Алмыш, Багдад, халифат.

The main direction of the spread of Islam is the Central Asia (Maverannahr). The Central Asia established close connection with Turkic tribes of North Caucasus back in the Khazar times. This tradition continues and develops in the middle Volga region. Gradually, Central Asia with Bukhara as its center and the Volga Bulgaria form a common cultural and religious area based on Hanafi Islam.

The year of 922, when ambassadorial envoys arrived from Baghdad to the Volga River is remembered as the year of official recognition of Volga Bulgaria by the Caliphate as a part of Islamic civilization.

With the spread of Islam the population of the Volga Bulgaria have been involved in theology, education and science of the Islamic world.

**Key words:** bulgar, islam, hanafi, ibn Fadlan, Almish, Baghdad, caliphate.

Бүгенге көнгә болгарларга исламның һәм мөселман мәдәниятенең үтеп керүе, таралышы һәм дәүләт диненә, мәдәниятенә әверелүе хакында шактый бай фәнни һәм фәнни-популяр әдәбият тупланган. Шулай да бу мәсьәләләрне өйрәнүгә күп еллар гомерен багышлаган, аны фәнни нигезгә салган Елена Александровна Халикованың хезмәтләре, аеруча «Мусульманские некрополи Волжской Булгарии X – начала XIII в.» [Халикова, 1986] китабы, хосусан, йомгак рәвешендә язылган «О времени проникновения и степени распространения ислама в Волжской Булгарии в домонгольский период» исемле бүлектәге төрле яктан нигезләнгән нәтиҗәләре әһәмиятле. Соңгы елларда алар яңа күзәтүләргә нигезләнгән тикшеренүләр белән баетылды [Халиков, 1991, с. 156–161; Давлетшин, 1990, с. 111–118; Дәүләтшин, 1999, б. 218–284; Давлетшин, 2008, с. 440–446; Давлетшин, 2019; Ахунов, 2003; Измайлов, 2006, с. 549–556; Измайлов, 2016,

с. 68–88]. Шулай да болгарларның ислам белән беренче танышулары, аның тәүге адымнары хакындагы мәсьәлә аз өйрәнелгән һәм бу хакта каршылыклы фикерләр әйтелгән дип расларга кала.

Болгарларда ислам таралышының иң әһәмиятле мәсьәләләреннән берсе – Азов буе Бөек Болгар дәүләтендә (632–669) һәм Хәзәр каганлыгында (650 еллар – XI гасыр уртасы) болгар-хәзәр кабиләләренең беренче тапкыр ислам белән танышуы. Бу – исламның Россия җирендә тәүге адымнары була. Миссионерлык эшчәнлегеннән тыш, ул Кавказга ике чордан торган (642–652 һәм 706–738 еллардагы) гарәп яулары белән дә бәйле. 737 елда хәлифә Мәрван II ибн Мөхәммәд (688–750) армиясе, тар-мар ителгән болгар һәм хәзәрләрне куып, Идел буеның «урманлы төбәкләр»енә [Артамонов, 1962, с. 223; Ахунов, 2003, с. 46] (хәзерге Саратов, хәтта Самара), ягъни булачак Идел буе Болгарының көньяк чигенә кадәр барып җиткән. Болгар кабиләләренең бер өлеше, аерым алганда, бәрәнҗәрләр ислам динен кабул иткәннәр. Багдад илчелеге килгәч, аның сәркатибе Әхмәд ибне Фазлан нәкъ менә аларны Идел Болгарында да билгеләп үтә: «Без аларда инде барысы да исламны кабул иткән бергә яшәүче ире вә хатыны биш меңләп булган кешеләрне күрдек. Аларның барысын да бәрәнҗәрләр дигән исем белән атыйлар. Аларга агачтан мәчет салганнар. Шунда алар намаз укыйлар» [Гараева, 2006, с. 736].

Монда шуны да өстәргә кирәк: археологлар тарафыннан Биләрнең үзәгендә X гасырның беренче яртысына караган һәм бик зур итеп агачтан (44/48×30 м), бераз соңрак акташтан салынган (42×26 м) өлешләрдән гыйбарәт җамигъ мәчет табып тикшерелде. Бу – безнең җирләрдә билгеле булган иң борынгы мәчет [Халиков, Шарифуллин, 1979; Хузин, 2000, с. 275–278], аның янында аксөякләр зираты, мавзолей, мунча (тәһарәтханә?). Шушы вакыттан ук исламның тиешле институтлары: шәригать кануннары, мәчет, мавзолейлар, һәм аларда хезмәт күрсәтүче мәзиннәр, имамнар, казыйлар, факиһлар, хатиплар булган дип уйларга нигез бирә.

Идел буе болгарларының ислам динен Мөхәммәд пәйгамбәр заманында ук кабул итүе турында да хәбәрләр бар. XVI–XVII гасырларның Госманлы-Мисыр тарихчысы Мөхәммәд ибн Мөхәммәд Чыкрыкчы Задә «Дәләилү нөбүт...» («Пәйгамбәрнең дәлилләре») әсәре (халыкта «Алты бармак китабы» буларак танылган) шундыйлардан. Анда һиҗри белән 7, милади белән 629 елда, башка хәлләр белән беррәттән, болгарлар хакиме Фәруһ бине Гамру Хизаминың ислам динен кабул итүе хакында бәян ителә. Моны рәсмиләштерү өчен, ул 629 елны Мәдинәгә үзенә тугры Мәсгуд бине Сәгыйдне, Мөхәммәд пәйгамбәргә хат һәм бүләкләр биреп, илче итеп җибәрә. Мөхәммәд пәйгамбәр Болгар хакименең һәм болгарларның ислам динен кабул итүләренә хәер-фатихасын бирә [Мөхәммәд ибн Мөхәммәд, 1899, б. 427–428]. Бу хикәя легенда характерында. Ул вакытта һәм соңрак та ислам динен кабул иткән халык аны Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) үз кулыннан алдык, дип инандырырга омтылган легенда-риваятьләр

аз булмаган. Шулай да госманлы язучысының болгарларга бәйле хикәясе үзенең тарихи фактларга якын булуы һәм ул чорның тарихи халәтенә туры килүе белән аерылып тора [Дәүләтшин, 1999, б. 218–222; Яхин, 2018, б. 92–98; Гәрәев, б. 148–154].

Үзәк Азиянең, Төньяк Иранның исламлашуы нәтиҗәсендә угызларның (750–1055), таһириларның (821–873), саффариларның (861–1003), саманиларның (875–999), караханиларның (940–1212), газнәвиләрнең (977–1186) һәм сәлҗүкләрнең (1037–1194) төрки-фарсы хәнәфи мәзһәбендәге мөселман дәүләтләре барлыкка килә. Алар белән тыгыз сәүдә, дини-мәдәни элемтәләр нәтиҗәсендә болгарлар һәм Хәзәр каганлыгы X йөздә рәсми рәвештә хәнәфия юнәлешендәге ислам динен кабул итә [Новосельцев, 1990, с. 231].

Болгарлар арасында исламның алга таба таралуы да Үзәк Азия белән бәйле. Идел буе Болгар дәүләте, саманилар дәүләте белән элемтәләрне җайга салып (Биләр – Бохара юлы), ислам динен кабул итеп кенә калмыйча, алардагы дәүләт төзелешен, салым, акча-үлчәү системасын кабул итеп ала һәм мәдәният өлкәсендә дә күп нәрсәләрне үзләштерә.

А.П. Ковалевский фикеренчә, Идел буе Болгары, һәрхәлдә, Багдад илчелеге килгәнче, саманилар дәүләтенә мәдәни-дини бәйлелектә булган [Ковалевский, 1956, с. 32].

Йакуб ибне Ногман да үзенең «Тәварихы Болгария»сендә Болгар иленә килүче дингә өндәүчеләрнең Бохарадан булуын искәртә.

«Болгар» сүзе галим кеше дигәнне белдерә. Эш шунда ки, Бохарадан мөселман сәүдәгәрләреннән булган бер кеше килә. Ул тыйбны яхшы белгән фәкыйһ була. Патша һәм аның хатыны каты авыру белән интегәләр. Һәм аларны үзләрендә кабул ителгән дарулар белән дәвалыйлар. Әмма авыру көчәя генә. Икесе дә үлемнән курка башлыйлар. «Бу мөселман аларга әйтте: «Әгәр дә мин сезне дәвалап, икегезне дә дәвалап терелтсәм, минем динемне кабул итеп алырсызмы?» Икесе дә: «Әйе», – диделәр. Ул аларны дәвалады һәм алар савыктылар, ислам динен кабул иттеләр. Мәмләкәт әһалисе (халкы) дә исламны кабул итте. Шуннан соң зур гаскәр белән Хәзәр патшасы килеп, алар белән сугышты. «Минем әмеремнән башка нишләп бу динне кабул иттегез?» – диде. Мөселман болгарларга курыкмаска, «Аллаһе әкбәр. Аллаһе әкбәр, Аллаһка мактау! Йә Аллам, Мөхәммәд һәм аның ыруына хәер-фатиханы бир!» – дип кычкырырга кушты. Бу патша белән көрәшеп, аның гаскәрен качып китәргә мәҗбүр иттеләр. Шуннан соң бу патша алар белән солых төзеде, аларның диннәрен кабул итте һәм (хәзәрләр) патшасы әйтте: «Мин сезнең гаскәрләрегездә минем сугышчыларны күпләп үтергән күк атларга атланган олуг ирләрне күрдем. Алар мине качып китәргә мәҗбүр иттеләр». Бу фәкыйһ әйтте: «Бу ирләр – бөек һәм шөһрәтле Алланың гаскәре» [Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати, 1971, с. 30–31]. Йакуб ибне Ногман башкала казые, тарихчы, атаклы Нишапур дин белгече, тарихчысы Әбел-Мәгали Әбд әл-Мәлик ибне Әбу Мөхәммәд әл-Җүвәйнинең (1028–1086)

шәкерте яки тарафдары була [Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати, 1971, с. 30, 72]. Ул язган «Тәварихы Болгария» – Болгар иленең рәсми тарих китабы, андагы ислам динен кабул итү турындагы хикәят болгарларның тагын да борынгырак чорга киткән традицион тарихи фикерләвен чагылдыран.

Ислам динен кабул итү турындагы шуңа охшаш төрле риваятьләр соңрак та болгар-татар халкы арасында киң тарала. Аларның бер өлеше телдән-телгә сөйләнелә, кайберләре популяр китапларда да урын ала. Шундыйлардан Йакуб ибне Ногманның «Тәварихы Болгария»сендә бирелгән хәбәрнең җентекләбрәк тасвирлануы белән Хисаметдин Шәрәфетдин Мөслиминең XVIII йөздә язылган «Рисала таварих әл-Болгария...»сендә, Таҗетдин Йалчыголның «Тәварихе Болгария»сендә бирелгән вариант аерылып тора [Миңнегулов, 2014, б. 339–359; Галяутдинов, 1990]. Ислам динен кабул итү, халкыбыз тарихында бик мөһим, данлыклы вакыйга буларак, халык иҗатына күчеп, төрле риваятьләрдә дә урын ала.

Үзәк Азия белән дини элемтәләр соңрак та дәвам итә. XIII гасырның танылган гарәп тарихчысы Ибн әл-Әсир Караханилар державасы турында болай дип яза: «1043 елда 10 мең чатырда яшәгән төрекләр (төркиләр. – *Г.Д.)* вакыт-вакыт Баласагун һәм Кашгар тирәләрендәге мөселман шәһәрләренә һөҗүм итеп торалар. ...Җәйне алар Болгар якларында үткәргәннәр, ә кышын Баласагун биләмәләрендә яшәгәннәр. Әмма ислам динен кабул иткәннән соң, алар ил буенча таралыштылар...» [Бартольд, 1966, с. 53–54; Извлечения из «Китаб алкамил фи-т-арих» Ибн ал-Асира, 1973, с. 60]. Әлеге өзектәге хәбәргә караганда, Карахани күчмәннәренең бер өлеше Болгар йогынтысында да ислам динен кабул иткән булып чыга.

Хәтта күп еллардан соң да болгарлар Үзәк Азиядән килгән рухи остазларын һәм үзләренә бу җирләрдән ислам дине үтеп керүен онытмыйлар. Болгар патшасы Әбу Исхак ибн Мөхәммәд 1024–1025 елларны Хөрәсән хакименә Сәбзевар һәм Хөсрәүҗер шәһәрләрендә ике җамигъ мәчет төзү өчен акча һәм «гаҗәеп бүләкләр» җибәрә: «Ул өлкәдә, кайсыдыр ки тулаем Болгар дип атыйлар, Әбу Исхак Ибраһим бине Мөхәммәд бине Б.л.т. вар әмир иде; 415/1024–1025 елда ул үз биләмәсендә янәсе сиңа, Нишапур өлкәсендәге Бәйхакка, Сәбзеварда һәм Хөсрәүҗердә ике җамигъ мәчетне төзергә тоту өчен күпмедер акча җибәрелергә тиешлеге хакында төш күрде. Ул Хөрәсән хакименә бик күп акча һәм кеше күрмәгән, дөньяның бер могҗизасы кебек гаҗәеп бүләкләр җибәрде. Ул вакытта бу акчаны шушы ике мәчетне төзү өчен тоттылар» [Заходер, 1967, с. 46].

Әкренләп мәркәзе Бохарада булган Үзәк Азия Идел буе Болгары белән бердәм дини-мәдәни киңлек тәшкил итә.

Нәкъ менә Үзәк Азиянең мәдәни яктан алга киткән төбәкләре белән тыгыз элемтәләр нәтиҗәсендә, болгарлар арасында хәнәфия юнәлешендәге ислам дине тарала, ныгый. Бу ике төбәктәге мәгърифәтле кешеләр эшчәнлегендә дә күренә [кара: Дәүләтшин,

1999, б. 472–476]. Моннан тыш, Идел буе болгарлары өчен хәнәфи мәзһәбендә калу ул вакытка кадәр Идел буе Болгары белән Үзәк Азия арасында урнашкан сәүдә мөнәсәбәтләрен саклау өчен дә мөһим булган. Хәнәфичелек, нигездә, шәһәрләр дине буларак, фән, сәнгать, мәгариф, әдәбиятны үстерү өчен киң мөмкинлекләр ача. Хәнәфи мәзһәбендә һәр илнең һәм халыкның тарихы, гореф-гадәтләре, мәдәнияте һ.б. искә алынган [Ислам: Энциклопедический словарь, 1991, с. 273]. Монда мөселман төрки халыкларның борынгы диннәрендәге илаһият исеме – Тәңре сүзенең Аллаһ исеме белән янәшә кулланылуын искә алу да җитә.

X гасыр башында Ибн Рустә: «Алмыш исемле Болгар патшасы ислам динен тота, аларның (ягъни болгарларның. – *Г.Д.*) күп өлеше ислам динендә, авылларда (яшәгән җирләрдә. – *Г.Д.)* аларның мәчетләре һәм имамнары белән башлангыч мәктәпләре бар», – дип хәбәр итә [Хвольсон, 1869, с. 22, 23].

Идел буе Болгарында исламның үзенчәлеге шунда ки: ул башта ук болгар кабиләләрен берләштерүдә, дәүләт оешуда идеологик чара буларак кулланылган. Болгар дәүләтчелегенең аякка басуы һәм илне исламлаштыру бер-берсеннән аерылгысыз, бер-берсен үзара көчәйтә торган агым буларак бара.

Дәүләтчелекне булдыруның соңгы этабында, Хәзәр каганлыгына буйсынуда булган болгарлар арасында яһүд динен көч кулланып кертү омтылышы белән бәйле халыкара киеренкелекне йомшарту, илдә ислам позициясен ныгыту, дәүләт абруен күтәрү һәм ул чорда иң кодрәтле көч саналган хәлифәнең канаты астына керү максатыннан, Болгар патшасы Җәгъфәр ибн Габдулла 921 елда аның ярдәменә омтылып, Багдадка, Гарәп хәлифәлегенә мөрәҗәгать итә.

Идел буе Болгарына юнәлгән Багдад илчелеге, нәкъ менә дошмани Хәзәр каганлыгын читләтеп үтү өчен, Урта Иделгә юлны Харәзем – Устюрт – Урал буе далалары – Ургенч аша инде күптән Үзәк Азия һәм Болгар сәүдәгәрләре, сәяхәтчеләре һәм дин таратучылары салган маршрутны сайлый. Багдад илчелеге һәм Әхмәд ибне Фазланның «Рисалә»се турында киң фәнни, фәнни-популяр әдәбият бар. Монда бары тик шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: илчелек иман тарату мәгънәсендә, аеруча аларны исламдагы башка мәзһәбкә юнәлтергә омтылып, әллә ни уңышка ирешә алмый. Болгар мөселманнары хәнәфиләр булып кала. Шулай да ул чорда ислам үзәге булган Багдадтан 922 елда Болгарга зур илчелекнең килүе илдә исламны ныгытуга, илнең халыкара абруен күтәрәгә уңай йогынты ясый. 922 ел, Идел буе Болгарын, цивилизацияле мөселман дөньясы дәүләтләренең берсе буларак, Хәлифәлек тарафыннан рәсми тану елы буларак тарихка кереп кала.

Болгар илендә алга таба да хәлифәне онытмыйлар, хөтбәләрдә аның исемен искә алалар, аның исемен дә кертеп тәңкәләр сугалар, вакыт-вакыт аңа бүләкләр җибәрәләр. Шулай итеп, Багдад хәлифәсенең хакимияте танылa. Әмма Багдад Болгардан бик еракта, һәм бу «хакимлек» номиналь булып кына кала.

Бу вакыттан бирле бер генә Шәрык географик иншасы да Болгарны искә алмыйча калмый инде. Ислам илләре белән багланышлар ныгый һәм үсә.

Идел буе болгарлары арасында ислам дине көчәюнең өченче чоры башлана. Шуның нәтиҗәсендә Болгар дәүләте ислам дәүләте буларак таныла. Ислам илнең бөтен территориясе буйлап тормышның барлык өлкәләренә, җәмгыятьнең барлык катламнарына үтеп керә.

Болгар илендәге социаль-икътисади төзелеш, мөселман үзәкләре белән тыгыз сәүдә-икътисади, сәяси, мәдәни элемтәләр, архитектура, кием-салым, йолалар, мәгариф системасы, фән, нәфис әдәбият, метрология һәм акча-авырлык системасы, календарь һ.б. – барысы да мөселман традицияләре белән бәйләнгән. Ислам болгар мәдәниятен Көнчыгыш халыклары культурасы белән якынайтуның идеологик нигезенә әверелә.

Исламны феодаль иҗтимагый-икътисади формациягә туры килә торган идеология буларак кабул итү һәм тарату илнең алдагы язмышлары өчен зур нәтиҗәләргә китерә. Ислам Болгар дәүләтенең халыкара абруен ныгытуга, Шәрык илләре белән икътисади-сәүдә һәм мәдәни багланышларны җанландыруга, гомумболгар халкын берләштерүгә, татар халкы бабаларының үзенчәлекле рухи мәдәнияте оешуга китерә.

Ислам диненең ул вакыттагы үзәге – Багдад белән элемтәләр тагын да көчәя. Багдад илчелегеннән соң, Болгар әмиренең улы Җәгъфәр үзенең яраннары белән хаҗга барганда Багдадта туктый. Хәлифә Әл-Мөкътәдиргә бүләкләр һәм акчалар бирелә [Новосельцев, 1990]. Бу хәлләр кабатланып тора. Гарәп тарихчысы һәм дин галиме Габдерахман ибн әл-Җәүзи (1116–1201), борынгы чыганакка сылтап, борынгы Болгардан «зур кешеләрнең берсе» 50 кешелек яраннары белән хаҗга барышлый Багдадта тукталды. Аларны хәлифә диванында сөйләшүләр алып баручы «Казый» исемен йөрткән Йал ибн Исхак әл-Харәзми озатып йөрде, дип яза [Халидов, 1998, с. 82–83]. Ягъни, ерак төньякта урнашкан мөселман иленнән килгән Болгар илчелеге Багдадта рәсми рәвештә кабул ителә.

Идел буе Болгары мөселман цивилизациясе мохитенә карахани карлукларына, сәлҗүкләргә караганда иртәрәк һәм тирәнрәк керә. Фламанд сәяхәтчесе Вильгельм Рубрук 1235 елда, бәлки бераз арттырып та, Болгар мөселманнары «Мөхәммәд динен башкаларга караганда нык тоталар» («Эти булгаре – самые злейшие Саррацины, крепче держащиеся закона Магометова, чем кто-нибудь другой») дип, үрсәләнеп хәбәр итә [Путешествие в восточные страны Плано Карпини и Рубрука, 1993, с. 103].

Әбү Рәйхан әл-Бируни (972–1048) болгарлар «исламның төп илләреннән» аерылган, шуңа да карамастан, «Хәлифәлек, хәлифәләр турындагы мәгълүматлардан мәхрүм түгел, киресенчә, аларның исемнәре белән хөтбә укыйлар» дип билгеләп үтә [Бируни, 1957,

с. 55]. Академик В.В. Бартольд Идел Болгарын «мөселман мәдәниятенең төньяк форпосты» дип атады [Бартольд, 1968, с. 510].

Болгарларның бу хәле Идел буе Болгарында ислам йолаларын үтәүнең билгеле бер ортодоксальлегенә һәм катгыйлыгына китерә. Мәсәлән, Ә.Г. Мөхәммәдиев суварларның әмир Алмышка буйсынмавын аларның 737 елда Хәзәр каганлыгында кабул ителгән һәм тагын да нык бирелгәнлек характерында булган ислам диненең үзенчәлекләре белән аңлата [Мухамадиев, 1990, с. 141–142]. Моны без Болгар илендә мөселман йолаларының үтәлешендә дә күрәбез. Мәсәлән, болгар-мөселманнарның җирләү йоласында археолог Е.А. Халикова каберләрнең еш кына бер градуска кадәр төгәллек белән кыйблага йөз тотуын билгеләп үтте. Тикшеренүчеләр хәтта кабер юнәлешен билгеләүдә Болгарда билгеле бер гномон тибындагы прибор куллануларын да фаразлыйлар [Халикова, 1986, с. 63].

Г.А. Федоров-Давыдов Алтын Урда Болгарында исламның ни дәрәҗәдә көчле булуы турында болай дип яза: «Алтын Урда шәһәрләрендә ислам нормаларыннан, аерым алганда, җирләү йоласыннан тайпылу Идел Болгарына караганда көчлерәк булган, ләкин якынча Харәземдәге кебек үк» [Фёдоров-Давыдов, 1998, с. 37]. Шулай итеп, Болгарда ислам Алтын Урда үзәкләренә караганда да көчлерәк булган һәм соңгыларын исламлаштыруда җитди роль уйнаган. Болгар бу вакытта да ислам һәм ислам мәдәнияте өлкәсендә күбрәк Үзәк Азиягә йөз тоткан.

Аерым алганда, мөселманча күмү, җеназа йолаларын башкарганда, хәрәмнән тыелуда (әйтик, дуңгыз итен ашамауда һ.б.) Болгар халкы исламның гомуми нормаларын гына тотмыйча, күп кенә мөселман Шәрык илләренә караганда да катгыйрак үз җирле кануннарын булдыра һәм аларны бар төбәктә дә җиренә җиткереп үти [Измайлов, 2016, с. 85]. Әхмәд ибне Фазлан мәзиннең җәйге кыска төннәрдә иртәнге намазга чакыру вазифасын (азан) үткәреп җибәрүдән куркып, бер ай буена йокларга да ятмавы турында гаҗәпләнеп яза [Гараева, 2006, с. 733].

Ислам үзәкләреннән аерылган ерак төньякта көчле ислам дәүләте барлыкка килү ислам дине җанатарларын таң калдыра. Ай яклавында булган дин кардәшләренә булышу, аларга рухи ярдәм күрсәтү, мөселман мәгърифәтен иңдерү өчен ислам үзәгеннән бу якларга килү алар өчен саваплы эш саналган [Шерефи, 1995, с. 87].

Шулай итеп, Идел буе Болгарындагы исламның борынгы заманнарга китүче тирән тамырлары бар. Беренче чиратта, ул югары мәдәниятле Үзәк Азия һәм Төньяк Иран төбәкләре белән бәйле. Исламның хәнәфи мәзһәбе – шәһәрләр һәм язма мәдәниятне үстерүдә киң мөмкинлекләр ача торган юнәлеш – катлаулы дини вазгыятьләргә карамастан, безнең көннәргә кадәр сакланып калган. Ислам таралу белән Идел буе болгарлары мөселман дөньясының мәгарифенә һәм фәненә тартылганнар. VIII–IX гасырлар археология материалларындагы беренче гарәп язулары инде Урта Идел буенда элгәреге Болгар

кабиләләренең барлыкка килүе белән бәйле, һәм алар барысы да дини характерда [Казаков, 1985, с. 178–185].

IX–X йөзләрдә үк болгарлар яшәгән җирләрдә («селениях») мәчетләр һәм башлангыч училищелар барлыкка килү турында Ибн Рустә (X гасыр) сүзләре күпләргә таныш [Хвольсон, 1869]. Бу мәктәп белеменең башлангыч баскычы турында. Көнчыгыш мәдәни үзәкләрендә: Бохара, Сәмәрканд, Нишапур, Бәлех, Багдад, Мәрвә, Газна һ.б. сабак алу мөселман белеменең югары баскычы булган һәм бу традиция татарларда XX гасыр башына кадәр дәвам иткән. Бу җәһәттән «Абына-абына Бохарага җитәрсең, ялгыша-ялгыша галим булырсың» дигән татар мәкале гыйбрәтле.

Кяферләр белән әйләндереп алынган әлеге форпостка, изге рухи вазифа буларак, ислам һәм аның мәдәнияте нигезләрен саклау, тарату бурычы йөкләнә. Болгар, ислам һәм мөселман мәдәниятенең иң төньяк үзәге буларак, аларны таратуда гаять зур эшчәнлек алып бара.

Болгарлар исламны үзләренең күршеләре булган башкорт [Юнусова, 1999, с. 20–22] һәм өлешчә фин-угор [Белавин, Иванов, 2011] халыклары арасында да тараталар.

Соңгы елларда Пермь археологлары тарафыннан өйрәнелгән Рождественск шәһәрлеге (Урта гасырлар гарәп, фарсы чыганакларында ул «Афкула» касәбәсе дип йөртелгән) Урал буенда болгар-мөселманнарның шәһәр үзәге булган [Белавин, Иванов, 2011].

Болгарлар кенәз Владимир I нең дин сайлау мәсьәләсендә хәбәрдар булып, 986 елда, аны исламга күндерү максаты белән, Киевка баралар. Кызыклы бу вакыйга хакында «Повесть временных лет»ның бөтен редакцияләрендә диярлек кабатлана [ПСРЛ, I, с. 84; II, с. 71, 72; XV, с. 77; XXV, с. 359].

Болгардан ерак Көнбатыш Себергә, Төньяк котыпка таба иң төньяк төбәкләргә кадәр кәрваннар белән сәүдәгәрләр, миссионерлар килә: дини мәдәният кенә түгел, яшәү рәвеше, фән, сәнгать таратыла [Худяков, 2006, с. 330–334; Белавин, Иванов, с. 74–109].

Нәтиҗәдә, академик В.В. Бартольдның Идел Болгарын «мөселман мәдәниятенең төньяк форпосты» дип атавы, соңгы еллардагы тикшеренүләр нәтиҗәсендә, ислам дөньясын тагын да төньяккарак киңәйтте.

Шулай итеп, Болгар иленә исламның үтеп керүе, таралуы, ныгуы төрле юнәлештә барган. Урта Идел, Кама буйларына килгән болгарларның бер өлеше ислам дине белән VII–VIII гасырларда ук таныш булып, аны үз диннәре итеп кабул иткәннәр, яңа җирләрдә исламны таратуда, Болгар дәүләтен оештыруда әйдәп баручы көчкә әверелгәннәр. Үзәк Азия белән традицион элемтәләрен, исламның хәнәфия юнәлешен саклап, үстереп җибәргәннәр. 922 елда Болгарга зур абруйлы Багдад хәлифәлеге илчелегенең килүе аны ислам дәүләте буларак таныткан, аның шөһрәтен арттырган. Инде X гасыр ахыры – XI гасыр башында ук ислам һәм аның мәдәнияте илнең бар төбәгендә, иҗтимагый катламнарында тамыр җәйгән.

**Әдәбият**

*Артамонов М.А.* История хазар. Л.: Изд-во Гос. Эрмитажа, 1962. 524 с.

*Ахунов А.М.* Исламизация Волжско-Камского региона (VII–X вв.): на материале арабских и старотатарских источников Казань: Отечество, 2003. 216 с.

*Бартольд В.В.* Болгары. Сочинения, т. V. Работы по истории и филологии тюркских и монгольских народов. М.: Наука, 1968. С. 509–520.

*Бартольд В.В.* Отчёт о поездке в Среднюю Азию с научною целью. 1893–1894 гг. 1893–1894 гг. Сочинения. Т. 4. М., 1966. С. 21–94.

*Белавин А.М., Иванов В.А.* Восход золотого полумесяца над восточной Европой (начальные этапы утверждения ислама в Урало-Поволжье). Уфа: Изд-во Башкир. гос. пед. ун-та, 2011.

*Бируни А.* Памятники минувших поколений. Избранные произведения. Ташкент: Изд-во АН Узбекской ССР, 1957.

*Галяутдинов И.Г.* «Тарихнамә-и Булгар» Таджетдина Ялчыгулова. Уфа, 1990. 238 с.

*Гараева Н.* Ибн Фадлан // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. II. Волжская Булгария и Великая Степь. Казань: РухИЛ, 2006. С. 714–744.

*Давлетшин Г.М.* Волжская Булгария: духовная культура. (Домонгольский период X – нач. XIII в.). Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. 192 с.

*Давлетшин Г.М.* Начало распространения ислама на территории России Роль конфессии в развитии межнациональных отношений: Россия – Балканы – Поволжье: Труды международной конференции (Самара, 11–13 сентября 2008 г.). Самара: Изд-во Самарского научного центра РАН, 2008. С. 440–446.

*Гәрәев Ф.М.* «Алты бармак» китабы // Гуманитарные науки: проблемы и аспекты изучения. Материалы Итоговой конференции Татарского гос. гуманитарного института за 1996 год. Казань: Татарский государственный гуманитарный институт, 1997. Б. 148–154.

*Давлетшин. Г.М.* Ислам и мусульманская культура в истории тюрко-татар учеб. пособие. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2019. 152 с.

*Дәүләтшин Г.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 513 б.

*Заходер Б.Н.* Каспийский свод сведений о Восточной Европе. Горган и Поволжье в IX–X вв. М.: Наука, 1967. Т. 2. 212 с.

Извлечения из «Китаб ал-камил фи-т-тарих» Ибн ал-Асира / Перевод с арабского К.Б. Старковой // Материалы по истории киргизов и Киргизии, вып. 1. М., 1973. С. 15–23.

*Измайлов И.Л.* Ислам и мусульманская культура в Волжской Булганрии // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. II. Волжская Булгария и Великая Степь. Казань: Изд-во «РухИЛ», 2006 С. 549–556.

*Измайлов И.Л.* Археология и ислам в Среднем Поволжье в X – первой трети XIII в. // Поволжская археология. Казань, 2016. № 2 (16). С. 68–88.

Ислам: Энциклопедический словарь. М.: Наука. Главная редакция восточной литературы. 1991.

*Казаков Е.П.* Знаки и письмо ранней Волжской Болгарии по археологическим данным// Советская археология. 1985. № 4. С. 178–185.

*Ковалевский А.П.* Книга Ахмеда ибн Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Исследование по Мешхедской рукописи. Харьков, 1956. 347 с.

*Миңнегулов Х.* Таҗеддин Ялчыгол // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 2 т. XV–XVIII гасырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Б. 339–359.

*Мөхәммәд ибн Мөхәммәд Чыкрыкчы Задә.* Дәләилү нөбүт вә шәмәилү фөтүт Әхмәди. Казан, 1899.

*Мухамадиев А.Г.* Древние монеты Поволжья. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. 192 с.

*Новосельцев А.П.* Хазарское государство и его роль в истории Восточной Европы и Кавказа. М., 1990. 264 с.

Полное собрание русских летописей (ПСРЛ) Т. I. Лаврентьевская летопись и Суздальская летопись по Академическому списку. М., 1962.

ПСРЛ. Т. II. Ипатьевская летопись. М. 1962. 87 с.

ПСРЛ. Т. XV. Тверьской сборник. М., 1965.

ПСРЛ. Т. XXV. Московский летописный свод конца XV века. М.; Л., 1949.

Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.). Публикация Большакова О.Г., Монгайта А.Л. М., 1971. 136 с.

Путешествие в восточные страны Плано Карпини и Рубрука. Алматы, «Гылым», 1993.

*Федоров-Давыдов Г.А.* Религия и верования в городах Золотой Орды // Историческая археология. Традиции и перспективы. М., 1998. С. 28–39.

*Халидов А. Б.* Сообщение арабской хроники XII в. о посольстве из Булгара в Багдад. Ш. Марджани: Наследие и современность. Материалы международной научной конференции. Казань, 1998. С. 82–83.

*Халиков А.Х., Шарифуллин Р.Ф.* Иследование Комплекса мечети // Новое в археологии Поволжья. Казань, 1979. С. 21–45.

*Халиков А.Х.* Беренче дәүләт. Болгар иле. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 216 б.

*Халикова Е.А.* Мусульманские некрополи Волжской Булгарии X – начала XIII в. Казань: Изд-во Казан. ун-та,1986. 160 с.

*Хвольсон Д.А.* Известия о хозарах, буртасах, мадьярах, славянах и руссах Абу Али Ахмеда Бен-Омар Ибн-Даста... СПб., 1869.

Худяков Ю. Путь из Булгарии в Сибирь // История татар с древнейших времен в семи томах. Т.II. Волжская Булгария и Великая Степь. Казань: РухИЛ, 2006. С. 330–334.

*Хузин Ф. Ш.* Булгарский город в X-начале XIII вв. Казань, 2000. 480 с.

*Шерефи Х.* Зафер наме-и Вилайет-и Казан. Публикация А. Мелек Узйетгин. Предисловие и перевод с турецкого на русский язык Ф.С. Хакимзянова // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1995. Май. С. 83–92.

*Юнусова А.Б.* Ислам в Башкортостане. Уфа: Уфимский полиграфкомбинат, 1999. 352 с.

*Яхин Ф.З.* Коръән сүзенең Идел буена беренче китерелүе // Туган җир: Төбәк тарихы буенча журнал. 2018. № 4. Б. 92–98.

*Kurat A.N.* Bulgar. Islam Ansiklopedisi. Istanbul, 1920. S. 789.

***Дәүләтшин Гамирҗан Миргаҗан улы,***
*тарих фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 94(47).023

***Ф.Ш. Хуҗин***

# БОЛГАР ИЛЕНДӘ ИСЛАМ
# ҺӘМ ЭЛГӘРЕГЕ ШӘҺӘРЛӘР

В статье рассматриваются проблемы двуединого процесса распространения ислама и урбанизации в Волжской Булгарии. Автор приводит исторические и археологические факты, свидетельствующие об основании города Биляра на р. Джаушыр (Малый Черемшан) и Соборной мечети в его центре в период пребывания в Булгарии Багдадского посольства (лето 922 г.). По мнению автора, ранние поселения городского типа возникали по Великому Волжскому и Камскому пушному пути, что свидетельствует о значительной роли внешней торговли в урбанизационных процессах страны.

**Ключевые слова:** Волжская Булгария, Багдадское посольство, ислам, ранние города, Булгар, Биляр, Соборная мечеть, внешняя торговля.

The article deals with the problems of the dual process of the spread of Islam and urbanization in the Volga Bulgaria. The author mentions historical and archaeological facts testifying of the foundation of the city of Bilyar on the river Jaushyr (Small Cheremshan) and the Cathedral Mosque in its center during the stay of the Baghdad embassy in Bulgaria (summer 922). According to the author, the early urban-type settlements arose along the Great Volga and Kama fur routes, which indicates a significant role of foreign trade in the country's urbanization processes.

**Key words:** Volga Bulgaria, Baghdad Embassy, Islam, early cities, Bulgar, Bilyar, Cathedral Mosque, foreign trade.

Тарих фәнендә расланган факт: Мөхәммәд (с.г.в.) исән вакытта уңышлы гына башланып киткән яңа дин тарату кампаниясе аның вафатыннан соң Гарәбстан ярымутравыннан читкә чыга. Йөз ел дәвамында, дөрес, бераз «тәнәфесләр» белән, Көнбатышта Испания, Марокко һәм Мавританиядән башлап, Көнчыгышта Пакыстан, Һиндстан һәм Бангладешка кадәр сузылган, төньякта исә Урта, Кара, Каспий һәм Арал диңгезләре, көньякта Африка Сахарасы һәм Һинд океаны диңгезләре белән чикләнгән зур территорияләр һәм шул җирләрдә яши торган халыклар Багдад хәлифәлеге хакимияте астына эләгәләр [Очерки истории, 2008, с. 7].

Әмма Болгар илендә ислам дине таралу Мөхәммәд пәйгамбәр заманында ук башлана дигән фикер объектив чыганаклар белән расланмый. 630–660 еллар тирәсендә, ягъни Кубрат хан идарә иткән чорда, Бөек Болгар дәүләте халкы ислам динен тотмаган. Алардан соң калган зиратларда бары тик мәҗүси йолалар буенча күмелгән кеше сөякләре генә табыла [Рашев, 2004]. VII гасырның 60 нчы елларында Кубрат хан дәүләте таркалганнан соң, Урта Иделгә күчеп килүчеләрнең беренче дулкыны булып саналган болгарлар да үлгән кешеләрне мәҗүсиләр йоласы буенча күмгәннәр [Багаутдинов, Богачев, Зубов, 1998].

Исламның Көнчыгыш Европага, хәзерге Россия җирләренә үтеп керүе VII гасыр урталарында башлана. Дагстан территориясендә Гарәп хәлифәлегенең төп көндәше – Хәзәр каганлыгы. Гарәп-хәзәр сугышлары йөз елга якын дәвам итә (642–737). Бу сугышлар тарихы әл-Балазури, әл-Йакуби, әт-Табари, ал-Куфи, Ибне әл-Асир кебек гарәп һәм фарсы тарихчыларының хезмәтләрендә бәян ителә [Гараева, 2002, с. 6 и сл.]. Билгеле булганча, 737 елда Хәзәр дәүләте җиңелә, полководец һәм булачак хәлифә Мәрван ибне Мөхәммәд хәзәрләр белән солых төзи. Шартнамә буенча хәзәр каганы, аның яраннары һәм кул астындагы халыклар, шул исәптән болгарларның да бер өлеше, җиңүчеләр динен кабул итәргә мәҗбүр ителәләр. Шулай да галимнәрнең күбесе, бу чорда исламның таралу даирәсе каган һәм аның якыннары белән генә чикләнгән, болгарлар үзләренең традицион тәңречелек карашларыннан ваз кичмәгәннәр, дигән фикерне алга сөрәләр. Әмма тарихта шунысы да билгеле: IX гасыр башларында хәзәр каганы Обадия яһүдиләр динен кабул иткәч, аның бу гамәле белән килешмәгән болгарлар баш күтәрә, илдә чуалышлар башлана. Баш күтәрүчеләрнең бер өлеше, ислам динен тотучылар, Урта Иделгә күчеп китәргә мәҗбүр була [Плетнева, 1997, с. 49; Хузин, 2006, с. 40].

Безнең кулда тагын бер кызыклы чыганак – 903–912 елларда фарсы географы һәм тарихчысы Әбү-Али Әхмәд ибне Умәр ибне Рустә тарафыннан язылган «Әл-алак эн-Нәфисә» («Кадерле кыйммәтләр») дигән зур энциклопедик хезмәтнең җиденче томында теркәлгән хәбәр. Түбәндәге юллар игътибарны җәлеп итә: *«Болгарларның күпчелеге ислам динен тота, авылларында мәчетләре һәм имамнарымөәзиннәре белән башлангыч мәктәпләр бар <...> Аларның киемнәре мөселманнарныкына охшаш, зиратлары да мөселманнарныкы кебек»* [Хвольсон, 1869, с. 22–24] Академик И.Ю. Крачковский Ибне Рустәнең бу хезмәте 903–912 елларда язылган дип исбатлады. Болгар мөселманнары турындагы әлеге мәгълүматлар Ибне Рустәнең китап язу чорында гына барлыкка килмәгәндер, дип уйларга нигез бар. Алар, И.Ю. Крачковский язганча, һичшиксез, IX гасыр азагы чынбарлыгын чагылдыра [Крачковский, 1957, с. 159].

Исегезгә төшерәбез: әле XIX гасырның 80 нче елларында ук танылган дин галиме һәм тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани болгарларны Алмыш хан (Җәгъфәр ибне Абдаллаһ) заманында түгел, ә Габбаси хәлифәләре Әл-Мә’мүн (813–833) һәм Әл-Васыйк (842–847) идарәсе чорында, ягъни IX гасырның беренче яртысында ук ислам диненә күндерә башлыйлар, дип язып чыккан иде [Мәрҗани, 1989, б. 123]. Шушы ук фикерне соңыннан, 1990 елларда, профессор Альфред Халиков та яклады. Ул үзенең хезмәтләрендә Мә’мүн хәлифә заманында Хәзәр каганлыгы белән VIII гасырда ук мөселманлашкан Урта Азия арасында тыгыз хәрби-сәяси һәм сәүдә-икътисади элемтәләр урнашкан булуына басым ясады. Хәзәр дәүләтендә яшәгән болгарларга ислам дине нәкъ менә Урта Азиядән, төгәлрәге Харәзем өлкәсеннән үтеп кергән булырга тиеш, дип фаразлады әлеге галим [Халиков, 1991, с. 57].

Чыганакларыбызның тагын бер төркеменә – археология һәм нумизматика материалларына тукталып үтик. 1956 елда Бөек Новгородның Нерев дип аталган бер өлешендә археологик казу эшләре алып барганда Шәрык илләреннән китерелгән көмеш тәңкәләр хәзинәсе табыла. Хәзинәдәге тәңкәләр арасыннан бер ягына Җәгъфәр бине Абдаллаһ исеме язылган дирһәм галимнәрнең игътибарын яулап ала. Шәрык нумизматикасы белгече С.А. Янина Җәгъфәр бине Абдаллаһ – Идел Болгары хакиме Алмыш ханның мөселманча исеме, ә тәңкәнең исә дирһәмнең кире ягында күрсәтелгән Аббас хәлифәсе әл-Моктафи (902–908) идарә иткән чорда сугылган булуын кире какмаслык дәлилләр белән исбатлады [Янина, 1962, с. 179 и сл.]. Димәк, Болгар хакиме илтабар Алмыш тарихи 922 елга кадәр егерме ел элек үк инде ислам динендә булган икән. С.А. Янинаның бу ачышын бүгенге нумизматлар да инкяр итми, чөнки ул яңадан-яңа табышлар белән раслана тора [Кулешов, 2016, с. 517].

Археологларның ачышлары исә болгарларның Хәзәр каганлыгында яшәү чорына, ягъни тагын да борынгырак дәвергә карый. Каганлык халкының шактый өлеше чыннан да ислам динен тоткан дигән фикерне Дон елгасы бассейнында ачылган IX гасыр мөселман зиратларын казып тикшергән археологлар 1980 елларда раслады [Копыл, Татаринов, 1990]. Мөселман каберлекләренең датасын ачыклау җиңел түгел, чөнки мәетләрне киендереп күммәгәннәр, каберләрдә, мүҗүсилек чорындагы кебек, даталары төгәл билгеле бизәнү әйберләре дә, эш һәм сугыш кораллары да юк. Элегрәк археологлар мондый каберләрне Алтын Урда чорыныкы дип уйлыйлар иде. Стратиграфик күзәтүләр – кайбер каберләр X–XI гасыр корылмалары белән җимертелгән – мондый зиратларның IX гасырда барлыкка килүен исбатладылар. Хәзерге вакытта Хәзәр каганлыгы территориясендә, нигездә, Азов буйларында, ягъни соңрак Урта Иделгә күчеп утырган болгарлар яшәгән урыннарда, дистәгә якын мөселман каберлекләре билгеле [Кравченко, 2005].

Хәзәр илендә мөселман сәүдәгәрләре, һөнәрчеләр, Урта Азиянең төрле өлкәләреннән килгән башка төркем вәкилләре күп була. Аларның археологик эзләре Урта Азия шәһәрләрендә сугылган тәңкәләр, тандыр тибындагы мичләре булган торак урыннар, керамик эшләнмәләр, башка әйберләр рәвешендә сакланып калганнар. Хәзәрләрнең шул чордагы башкаласы Итилдә, гарәп тарихчысы Ибн Хәүкәл язмаларына караганда, утызга якын мәхәллә мәчете булган, шәһәрнең үзәк мәйданында биек манаралы Җамигъ мәчет балкып торган [Артамонов, 2001, с. 537−538].

Археологлар тарафыннан расланган тагын бер фактны исәпкә алырга кирәк: Идел Болгарына хәлифә Мокътәдир илчелеге килгәнче үк, Урта Азия сәүдәгәрләре Болгар базарларында сәүдә иткән, алар белән һөнәрчеләр дә, ислам дине вәгазьчеләре дә килгән [Валеев, 1995]. Нәтиҗәдә, Болгар дәүләте мәдәни яктан, академик Ю.В. Готье язганча (әлбәттә, бераз арттырып, әмма асылда дөрес), «Шәрыкнең

чын колониясе» нә әверелә башлый [Готье, 1930, с. 156 и сл.]. Бу исә болгарларның ислам диненә күчү процессын җиңеләйтә генә.

Борынгы болгар бабаларыбызның 922 елга кадәр исламга омтылып үткән юллары шулардан гыйбарәт.

Хәзер инде 922 ел вакыйгаларына күчик.

Идел Болгары дәүләт буларак IX гасыр ахырларында – X гасыр башларында формалаша. Биредә төрки телле болгар, сувар, барсил (берсула), бәрәнҗәр, искил һәм күрше фин-угор кабиләләре – мәҗүсиләр һәм мөселманнар яши. Болгар патшасының хыялы шул кабиләләрне, алар белән идарә итүне җиңелләштерү өчен, бер халык итеп туплау һәм үз дәүләтен халыкара күләмдә таныту була. Моның иң кулай юлы илдә күп аллалы мәҗүсилекне бетереп, ислам динен рәсми рәвештә кабул итү икәнен Җәгъфәр бине Абдаллаһ (Алмыш) яхшы аңлый. Һәм ул, шул максаттан чыгып, 921 елда Багдад хәлифәсе Мокътәдиргә хат белән мөрәҗәгать итә. Хатында ул хәлифәдән: 1) болгарларны дингә өйрәтүче, ислам дине кануннарын аңлатып бирүче факиһлар, 2) алар өчен мәчет төзеп бирүче осталар җибәрүен, 3) дошман патшалардан саклану өчен кальга (крепость) салуда ярдәм итүен үтенә.

Багдад хәлифәсе ризалыгын бирә. Һәм шул ук 921 елның 21 июнендә Багдадтан ерак Болгарга зур гына илчелек чыгып китә. Болгар иленә илчелек 922 елның 17 май көнендә килеп җитә. Хәзер сүзне Ибне Фазланга бирик:

*«Хәлифәнең хатын укыганны ишетсеннәр өчен ул, Болгар патшасы, үз иленең патшаларын (кабилә башлыкларын, бәкләрен. – Ф.Х.), гаскәр башлыкларын һәм хөрмәткә лаек башка кешеләрен җыйганчы, без үзебез өчен корылган чатырларда якшәмбе, дүшәмбе, сишәмбе һәм чәршәмбе көннәрдә (торып) калдык. Пәнҗешәмбе көне килеп җиткәч (922 елның 21 мае. – Ф.Х.) һәм алар җыелгач, без үзебез белән алган ике чигелгән байракны җәеп җибәрдек, аны, Болгар патшасын, кара киемнәргә киендердек һәм чалма кидердек. Мин хәлифәнең хатын чыгардым һәм аңа: «Хат укыганда утырып тору рөхсәт ителми», – дидем. Һәм ул аякларына торып басты, үз дәүләтенең шунда булган күренекле, хөрмәткә лаек кешеләре дә торып бастылар. Мин укый башладым һәм хатның башын укыдым. Һәм: «Сиңа тынычлык булсын! Һәм чыннан да мин сиңа (мөрәҗәгать итеп), Аллаһыны данлыйм, Аннан башка бүтән бөек көч юк», – дигән сүзләргә җиткәч, мин: «Мөселманнарның хөкемдарына тынычлык теләп җавап бир!» – дидем. Һәм ул җавап бирде, шунда булган кешеләр дә барысы бергәләп җавап бирделәр. Без хатны укып бетергәч, алар «Аллаһу әкбәр!» тәкъбирен кычкырып әйттеләр. Җир яңгырап торды.*

*Аннан соң мин вәзир Хәмид ибне әл-Габбасның хатын укыдым, Болгар патшасы бу вакытта басып торды. Аннан соң мин аңа утырырга куштым, һәм ул Нәзир әл-Харәминең хатын укыганда утырып торды. Хат укуны тәмамлагач, аның, Болгар патшасының, иярченнәре аңа күп итеп дирһәмнәр чәчтеләр. Аннан соң мин хуш исле нәр-*

*сәләрдән аның өчен һәм аның хатыны өчен тәгаенләнгән киемнәрдән, энҗеләрдән торган бүләкләрне чыгардым. Аннан соң мин аның хатынын кешеләр барында бүләкләдем, ә ул аның (Болгар патшасы) белән янәшә утыра иде. Һәм бу – аларның йоласы һәм аларның гадәте. Һәм мин аны бүләкләгәндә хатын-кызлар аңа дирһәмнәр чәчтеләр, һәм без чыгып киттек»* [Хәйри, 2013, б. 350–351].

Шуның белән Багдад илчелеге алдына куелган төп бурыч үтәлә: Болгар, ислам дөньясының иң төньягында урнашкан дәүләт буларак, рәсми рәвештә танылa. Җәгъфәр ибне Абдаллаһның Багдад хәлифәсенә язылган һәм хәлифә тарафыннан ярдәм итәргә вәгъдә бирелгән тагын бер бик мөһим мәсьәләне хәл итәсе кала. Ул да булса, Болгар илен яһүдиләрдән, ягъни Хәзәр патшасыннан саклау өчен хәрби ныгытма – крепость һәм мәчет төзү белән бәйле эшләр. Билгеле булганча, бу вакытта болгарлар Хәзәр каганлыгының вассаллары булып торалар. Җәгъфәр ибне Абдаллаһның улы Итилдә тоткынлыкта газап чигә, сөекле кызын җария итеп хәрәмдәге хатыннар янына алып китмәкчеләр. Шуңа күрә, Болгар патшасының хәзәрләрдән бәйсезлеккә омтылуын аңларга була.

Кызганыч, безнең тарихчылар Әхмәд ибне Фазлан язмаларын күп очракта бары тик Болгарда ислам динен кабул итү, болгар халкының рухи мәдәниятен, яшәү рәвешен өйрәнү максатында гына кулланып килделәр. Ислам һәм Болгар илендә шәһәрләр барлыкка килү – урбанизация процессы белән бәйле проблемалар фәндә беренче мәртәбә А.Х. Халиков тарафыннан күтәрелде [Халиков, 1991]. Әлеге проблемага без дә бераз ачыклык кертергә тырышып карадык [Хузин, 1995, с. 137 и сл.; 2001, с. 135 и сл.].

Крепость төзү мәсьәләсен Багдад илчеләре белән очрашуда Болгар ханы үзе күтәрә. Эш шунда ки, Багдад хәлифәсе үзенең хатында, Болгар илендә ныгытылган кала төзү өчен, Җәгъфәр ибне Абдаллаһка дүрт мең динар акча вәгъдә иткән була. Илчелек әгъзаларына кагылмаган төрле сәбәпләр аркасында бу акча Болгарга килеп җитми. Җәгъфәр хан Ибне Фазланның акланууларын тыңларга да теләми. Ахыр чиктә Багдад илчесе Болгар патшасыннан сорый: *«Синең дәүләтең бик зур, акчаларың күп, керемең күпсанлы, ә син ни өчен хәлифәдән киләчәк аз гына акчага ныгытма төзеп бирсен дип үтендең?» Болгар патшасының җавабы бик төпле: «Ул акчалар дини кануннар тарафыннан рөхсәт ителгән чыганаклардан алыналар дип санадым. Һәм чыннан да, әгәр дә мин үземнең акчаларга, көмешләргә яки алтыннарга ныгытма төзәргә теләгән булсам, минем өчен моңарда бернинди авырлык булмас иде»* [Хәйри, 2013, б. 369].

Һәм Болгар ханы Җәгъфәр ибне Абдаллаһ үзенә буйсынган кабилә башлыклары һәм төзү эшенә яраклы ир-атлар белән Җаушыр[1] дип аталган елга янына кузгалып китә. Биредә ул ике ай чамасы була.

[1] Хәзер бу елганы Кече Чирмешән дип йөртәләр.

922 елның җәендә Җаушыр елгасы янында нинди вакыйга булган соң? Бу турыда Ибне Фазлан язмаларында бер сүз дә әйтелмәгән (хәер, ул язмалар безгә тулысы белән килеп тә җитмәгән). Галимнәр фикеренчә, Җаушыр елгасы буенда Җәгъфәр ибне Абдаллаһ белән килгән болгар төзүчеләре Биләр каласына нигез салалар. Багдад илчелеге составында, дин белгечләреннән кала, хәрби ныгытмалар, шәһәр-крепостьлар төзү буенча тәҗрибәле осталар булганлыгы турында Ш. Мәрҗани [1989, б. 124], академик В.В. Бартольд [1968, с. 512], А.Ю. Якубовский [1948, с. 276–278], А.П. Смирнов [1951, с. 137, 252; 1976, с. 3–6] кебек күренекле галимнәр бер дә шикләнмичә язалар. Эшне хәрби ныгытмалар һәм булачак шәһәр үзәгендә мәчет төзүдән башлыйлар. Ягъни Болгар ханының Багдад хәлифәсенә язган үтенечен тормышка ашыралар.

Биләрнең планына күз салыгыз. Ул бер-берсенә кереп утырган ике өлештән – бер үк вакыт аралыгында барлыкка килгән эчке һәм тышкы шәһәрләрдән тора. Урыны-урыны белән икешәр рәтле калын диварлар – туфрак өеп ясалган биек үрләр, шул үрләргә куелган агач буралар һәм башнялар белән ныгытылган эчке шәһәрнең мәйданы 130 гектар чамасы. Өч рәт диварлар белән уратып алынган тышкы шәһәр исә 490 гектар җирне биләп тора. Крепость диварларының гомуми озынлыгы 40 километр чамасы. Шунысы кызык, Биләр үзенең планировкасы белән Урта гасырлар Багдадына охшаган. Багдад та хәлифә резиденциясе урнашкан эчке һәм сәүдә-һөнәрчелек бистәләрен берләштергән тышкы шәһәрдән гыйбарәт булган[1] [Большаков, 1982, с. 175]. Күрәсең, Биләргә нигез салуда катнашкан Багдад белгечләре, интуитив рәвештә булса да, үз шәһәрләре образын күз алдында тотканнар.

Биләрнең эчке шәһәрендә, аның үзәгендә диярлек, XVIII–XIX гасыр сәяхәтчеләре һәм төбәк тарихын өйрәнүчеләр борынгы мәчет урынын табалар [Рычков, 1770, с. 13]. 1970 елларда Казан археологлары шул мәчет хәрабәләрен казып чыгардылар һәм аның салыну вакытын ачыкладылар. X гасырның беренче яртысында ул ике өлештән торган. Борынгысы, 1400 квадрат метр мәйданда агач бүрәнәләрдән салынган өлеше, профессор А.Х. Халиков фаразлавынча, IX гасырда ук корылган [Халиков, 1991, б. 52–55]. 922 елда аның ак таштан салынган өлешен торгызганнар булса кирәк. Ул 1076 квадрат метр мәйданны били. Таш мәчетнең эчендә алты рәт колонналар тезелгән (һәр рәттә дүртәр колонна). Көньяк-көнчыгыш дивары ярымколонналар – пилястрлар белән ныгытылган.

Безнең уйлавыбызча, мәчетнең агач бүрәнәләрдән салынган өлеше чыннан да борынгырактыр, моны стратиграфик күзәтүләр дә раслый – аның төньяк-көнбатыш стенасы мәчетнең таш бинасын салганда бераз җимерелгән. Аннан соң Багдад осталары агач бина салу белән мәшәкатьләнеп тә тормаслар иде. IX гасыр ахырларында тө-

[1] X гасырда эчке һәм тышкы шәһәр ныгытмалары бер генә рәттән торган.

зелгән мәчет 922 елдан соң мәдрәсә ролен үтәмәде микән? Әлеге мәчет турында Мәскәү археологы Э.Д. Зиливинскаяның фикерләрен дә искә алып үтәргә кирәк. Ул, таш мәчет төзелгәннән соң, аның искесен (агач мәчетне) бөтенләй җимереп ташлаганнар, ә аның урынында зур гына шәһәр мәйданы барлыкка килгән, дип раслый [Зиливинская, 2019]. Хәзерге дин әһелләре фикеренчә, агач мәчет – кыш көне (ягып җылыту җиңелрәк), таш мәчет җәй көне файдаланылган булырга мөмкин.

Шушы мәчет янында ук 1971–1972 елларда кирпечтән салынган зур гына бина хәрабәләре казып тикшерелде [Халиков, 1979]. Соңгы елларга кадәр бу бинада үзенең гаиләсе белән югары дәрәҗәле берәр дин әһеле яшәгәндер, дип фаразлана иде. Бүген исә аның функциясен мунча яисә тәһарәтханә белән бәйләп аңлаталар. Бу фикер идән астында урнашкан җылыту системасы каналлары, сууткәргеч торба ватыклары кебек табылдыклар белән раслана [Зиливинская, 2020, с. 147]. Белгечләр исә Биләр биналары төзелешендә Якын Көнчыгыш һәм Урта Азиянең IX–XI гасырларга караган архитектура элементларын табалар [Шарифуллин, 1976, с. 50–51; Халиков, 1979, с. 11, 13, 15–16, 18–19; Khalikov, Sharifullin, 1977, p. 199–201].

Җамигъ мәчетнең көньяк-көнбатыш ягында мәйданы ягыннан артык зур булмаган зират урнашкан. Биредә 50ләп кабер тикшерелде. Үлгән кешеләрнең кайберләре кирпеч төрбәләр эчендә ята иде. Барысы да саф мөселман йоласы буенча җирләнгәннәр [Шарифуллин, 1984, с. 72–74]. Бу – болгар ханнарының, аларның якыннарының, гомумән, югары катлау кешеләренең каберләре. Шәһәр уртасында, Җамигъ мәчет янында, махсус төрбәләрдә гади кешеләрне күммәгәннәр, билгеле.

Тагын бер кызыклы факт: мәчет тирәсендә гади кешеләр яши торган агач йортлар, хуҗалык корылмалары, ашлык саклау амбарлары урнашкан. Арада безнең якларга бөтенләй дә хас булмаган торак йортлар да бар. Аларның стенасы, тал чыбыгыннан үрелгән читән ике яктан да калын итеп кызыл балчык белән сыланган. Өй эчендә, ишегалдында тандыр тибындагы мичләр тора [Хузин, 1979, с. 62–68]. Бу йортлар безнең як халыкларыныкына охшамаган, биредә, һичшиксез, Урта Азия якларыннан, Шәрык илләреннән килгән төзүчеләр яшәгән.

Әлеге мәчет комплексы – Идел Болгары дәүләтендә археологлар тарафыннан өйрәнелгән иң борынгы архитектура корылмасы, һәм ул, турыдан-туры булмаса да, Биләрнең беркайчан да гади шәһәрләр рәтендә йөрмәвенә ишарәли. Белгечләр раславынча, ул заманнарда Җамигъ мәчет (вәгазь сөйләү һәм ил хакиме (хан/әмир) исемен кушып хөтбә уку өчен имам-хатыйпка дип махсус ясалган мөнбәре булган) бары тик дәүләтнең административ-сәяси үзәгендә генә урнашкан.

Биләр мәчете белән бәйле тикшеренүләргә киңрәк тукталуыбызның сәбәбе Болгар илендә шәһәрләр барлыкка килү процессының ислам дине белән бәйле булуын күрсәтүдә иде. Иң борынгы шәһәрләр рәтендә йөрүче Болгар, кызганычка каршы, Ибне Фазлан

язмаларында (һәм X–XII гасырларга караган рус елъязмаларында) бер тапкыр да телгә алынмаган. Сиксән елга якын системалы рәвештә археологик казу эшләре алып барылуга карамастан, биредә монгол яуларына кадәрге чорда салынган мәчет эзләре табылмаган, торак йорт урыннарының саны дистәдән артмый, юрта эзләре дә юк, башка матди калдыклар да бик аз. Дөрес, хәзерге шәһәрлек территориясендә, Кече Иерусалим чокыры итәгендә, X гасырның беренче чирегенә караган бер урын бар, әмма аны Болгарның «чишмә башы» дип тану бик кыен [Старостин, 1993]. Археологлар Болгар шәһәрлегенең X–XI гасырлардагы мәйданын 9–12 га чамасы дип күрсәтәләр [Хлебникова, 1987, с. 52]. Ни генә булмасын, X гасырга караган гарәп-фарсы язма чыганакларында (әл-Балхи, әл-Истаһри язмалары) Болгар һәм аның белән беррәттән Сувар да телгә алына: «Болгар – халкы ислам дине тотучы илнең һәм Җәмигъ мәчете булган шәһәрнең исеме. Аннан ерак түгел тагын бер шәһәр урнашкан, Савир (Сувар) исемле, биредә дә Җамигъ мәчет бар. Бу шәһәрләрнең икесендә дә халык саны 10 меңгә җитә» [Хвольсон, 1869, с. 82]. Әмма хикмәт шунда ки, әле X гасырда ук Болгар илендә халык саны 10 меңгә җитә торган шәһәрләрнең булуы бик шикле. Урта гасырларда гигант шәһәрләр рәтендә йөргән Биләрдә дә ул кадәр халык яшәмәгән. Ә менә Бөек Идел сәүдә юлында урнашкан Болгарның X гасырда (тагын да элегрәк булмаса әле) эре сәүдә үзәге, җәен халыкара ярминкәләр үткәрелә торган урын булуын инкяр итеп булмый. Шул ук әл-Балхи һәм әл-Истаһри язмаларында күрсәтелгәнчә, «Тышкы Болгар – кечкенә генә шәһәр, киң мәйдан биләп тормый; ул дәүләтнең иң эре сәүдә ноктасы буларак кына танылу алган» [Хвольсон, 1869, с. 83]. Ибне Хәүкәл һәм «Хөдүд әл-әләм»нең билгесез авторы Болгарның Идел буенда урнашкан мөселман шәһәре булуын ассызыклыйлар [Калинина, 1976, с. 94; Худуд ал-алем, 1930, с. 31, 32].

Ислам дине кабул ителгәннән соң, Болгар иле гарәп-фарсы географлары, тарихчылары, сәяхәтчеләре тарафыннан Урта гасырлар цивилизациясенең иң атаклы һәм бай бер өлеше сыйфатында тасвирлана. Эреле-ваклы шәһәрләре булу һәр цивилизациянең төп билгеләреннән санала. Урта Идел һәм Кама буйларында археологлар тарафыннан ачыкланган болгар калаларының саны 170 кә җитә. Аларның өч дистәдән артыгы – чын шәһәр калдыклары [Хузин, 2001, с. 47–48]. Болгар шәһәрләре ерактан ук балкып торучы мәчет манаралары, кызыл кирпечтән салынган җәмәгать биналары – мунчалары, төрбәләре белән Шәрык дөньясының мөселман шәһәрләренә охшап торган.

X гасырның беренче яртысында барлыкка килгән болгар шәһәрләре Болгар, Биләр һәм Сувар белән генә чикләнмәгән, әлбәттә. Рус елъязмаларында телгә алынган Җүкәтау, Кашан, Ашлы (Ошель) шәһәрләрен дә шул исемлеккә кертергә мөмкин. Болгар дәүләтенең көньяк чикләрен саклау максаты белән Самара Дугасында калкып чыккан Мөрән каласы да (Муромский городок) иң борынгы шәһәрләр исәбендә [Матвеева, Кочкина, 1998].

Билгеле булганча, ислам дине гарәп сәүдәгәрләре даирәсендә барлыкка килә. Коръән сәүдәгәрләрнең эшчәнлеген һәрьяклап хуплый, канун кысаларына туры китереп регламентлаштыра. Икътисад ягыннан караганда, Урта гасырлар шәһәре, беренче чиратта – һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге. Гарәп-фарсы географлары хезмәтләрендә Идел Болгары, Хәзәр дәүләте һәм мөселман Харәземе кебек, инде IX гасырда ук Хәлифәлек өлкәләре белән тыгыз сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырган ил буларак тасвирлана [Крачковский, 1957, с. 126]. Академик В.Л. Янин, нумизматика материалларына нигезләнеп, «VIII гасырдан алып XI гасыр башларына кадәр Идел Болгары сәүдә өлкәсендә Русьны Шәрык илләре белән бәйләп торган бердәнбер капка ролен уйнап килде», – дип язган иде [Янин, 1956, с. 105]. Болгар дәүләтенең Шәрык, Көнбатыш Европа, Балтыйк буе һәм Скандинавия илләре белән бәгланышлары археологиядә дә чагылыш таба. Болгар, Биләр, Мөрәнише эре шәһәрләрне казыганда чыккан табылдыклар арасында VIII–X гасырларда сугылган көмеш дирһәм хәзинәләре, Урта Азиядән (Үргәнеч, Сәмәрканд, Мәрвә), Ираннан (Кашан, Рей), Һиндстаннан, Сүриядән, Византиядән китерелгән кыйммәтле савытсаба, муенса төймәләре, бизәнү әйберләре ясаганда кулланыла торган лазурит, сердолик, гранат, тау хрустале кебек асылташлар һәм башка әйбәрләр бар. Төсле витраж пыялалары, лампалар, савыт-сабалар Грузиядә, Әрмәнстанда, Азәрбайҗанда эшләнгәннәр. Казылмаларда Херсон һәм Таврия остаханәләрендә ясалган амфоралар, Лотарингиядә, Аквитаниядә эшләнгән бакыр-көмеш савытлар очрый. Сирәгрәк булса да Алманиядә, Даниядә, Чехиядә сугылган акчалар табыла. X–XI гасырларда ясалган франк кылычлары болгарларга варяглар аша килеп кергән. Швециядә, Норвегиядә, Финляндиядә, Даниядә, Польшада, Венгриядә һәм Балтыйк буе дәүләтләрендә X гасырда сугылган болгар акчалары табылган [Валеев, 1995, с. 60–75; Хузин, 2001, с. 244–252]. Әлбәттә, ислам динен кабул итү чорында формалаша башлаган халыкара сәүдә бәгланышлары болгарларда икътисадның һәм мәдәниятнең үсешенә уңай тәэсир ясаган.

Икътисадның кызу темплар белән үсеше яңа шәһәрләр барлыкка килү процессын тагын да җанландырып җибәрә. Бу бигрәк тә X гасыр ахырында һәм XI гасыр башларында дәүләт белән Ибраһим әмир идарә иткән чорда ачык күренә. Бу вакытта инде Идел Болгары – ислам идеологиясе астында берләшкән, гомум болгар исеме алган элеккеге кабиләләрнең бердәм һәм көчле дәүләте. Нәкъ менә шул вакыт аралыгында әле чагыштырмача күптән түгел генә үзләренең 1000 еллык бәйрәмнәрен үткәреп җибәргән Казан һәм Алабуга шәһәрләренә нигез салына. Рус елъязмаларында Бряхимов исеме белән телгә алынган Ибраһим шәһәре дә XI гасыр башыннан да соңга калмыйча нигезләнгән булырга тиеш[1]. 1236 елгы монгол-татар яуларына кадәр

[1] Бу шәһәрнең төгәл урыны әлегә кадәр билгеле түгел. Аны Алабуга, Болгар, Түбән Новгород белән тәңгәлләштереп караучылар булды, әмма мәсьәлә һаман да бәхәсле булып кала бирә.

яшәгән шәһәр-калаларның шактый өлеше X–XI гасырларда Бөек Идел юлы һәм аның бер тармагы булган Чулман сәүдә юлы өстендә барлыкка килә [Фахрутдинов, 1975, с. 26–49]. Кызганыч, бу шәһәрләрнең күбесе, хәтта язма чыганакларда телгә алынганнары да, археологик яктан бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән, аларда мәчетләр булу-булмавы да билгеле түгел. Ә бит Шәрык илләрендә Җамигъ мәчет – торак пунктларга шәһәр статусы бирә торган иң мөһим билгеләрнең берсе.

XII гасырда яшәгән фарсы тарихчысы Әбү-л-Хәсән Бәйхаки китабында болгар әмире Ибраһимның Хөрәсән патшасына Сәбзевар һәм Хөсрәүҗәрд шәһәрләрендә мәчетләр төзү өчен акча һәм бай гына бүләкләр җибәрүе турында язылган: «Болгарның һәм Болгар исеме белән атала торган тулы бер өлкәнең әмире Исхак Ибраһим ибне Мөхәммәд ибне Б.л.т.вар иде. 415/1024–1025 елда ул үзенең биләмәсендә төш күрә: син, имеш, Нишапурның бер өлкәсе булган Бәйхакка беркадәр акча җибәрергә тиешсең, шул акчаны Сәбсевар һәм Хөсрәүҗәрд шәһәрләрендә Җамигъ мәчет төзергә тотсыннар өчен. Ул бик күп акча һәм Хөрәсән патшасына искитәрлек бүләкләр җибәрде – чын мәгънәсендә дөнья могҗизасы. Шул чакта ул акчаларны теге ике мәчетне төзүгә исраф иттеләр» [Заходер, 1967, с. 46].

Югарыда китерелгән фактлар Идел Болгарында шәһәрләр барлыкка килү – урбанизация процессының илдә ислам дине таралу һәм сәүдә үсеше белән параллель рәвештә барганлыгын күрсәтеп тора.

**Әдәбият**

*Артамонов М.И.* История хазар. 2-е изд-е. СПб.: Лань, 2001. 688 с.

*Багаутдинов Р.С., Богачев А.В., Зубов С.Э.* Праболгары на Средней Волге. (У истоков татар Волго-Камья). Самара, 1998. 286 с.

*Бартольд В.В.* Булгары / Сочинения. М.: Наука, 1968. Т. V. С. 509–520.

*Большаков О.Г.* Средневековый арабский город // Очерки истории арабской культуры V–XV вв. М.: Наука, 1982. С. 156–214.

*Валеев Р.М.* Волжская Булгария: торговля и денежно-вестовые системы IX – начала XIII веков. Казань: Фест, 1995. 160 с.

*Гараева Н.Г.* Проникновение ислама на территорию России (взгляд арабских историков) // Ислам и мусульманская культура в Среднем Поволжье: история и современность / Науч. ред. Р.М. Мухаметшин. Казань: Мастейр Лайн, 2002. С. 6–20.

*Готье Ю.В.* Железный век в Восточной Европе. М.; Л.: Госиздат, 1930. 280 с.

*Заходер Б.Н.* Каспийский свод сведений о Восточной Европе. Т. II. Булгары, мадьяры, народы Севера, печенеги, русы, славяне. М.: Наука, 1967. 212 с.

*Зиливинская Э.Д.* Монументальные постройки Биляра: новый взгляд. «Джума мечеть» // Поволжская археология. 2019. № 2. С. 78–95.

*Зиливинская Э.Д.* Монументальные постройки Биляра: новый взгляд. Здания с подпольным отоплением // Поволжская археология. 2020. № 4. С. 145–158.

*Калинина Т.М.* Сведения Ибн Хаукаля о походах на Руси времен Святослава // Древнейшие государства на территории СССР. Материалы и исследования. 1975. М.: Наука, 1976. С. 90–101.

*Копыл А.Г., Татаринов С.И.* Мусульманские элементы в погребальном обряде праболгар Среднедонечья // Ранние болгары и финно-угры в Восточной Европе / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КНЦ АН СССР, 1990. С. 52–71.

*Кравченко Э.Е.* Мусульманское население среднего течения Северского Донца и распространение ислама в Восточной Европе в хазарское время // Степи Европы в эпоху Средневековья. Т. 4. Хазарское время / Гл. ред. А.В. Евглевский. Донецк, 2005. С. 153–186.

*Крачковский И.Ю.* Арабская географическая литература // Избранные сочинения. Т. IV. М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1957. 919 с.

*Кулешов Вяч.С.* Эпоха Ибн Фадлана в памятниках нумизматики // Путешествие Ибн Фадлана: Волжский путь от Багдада до Булгара / Науч. ред. А.И. Торгоев, И.Р. Ахмедов. М.: Изд. дом Марджани, 2016. С. 512–541.

*Матвеева Г.И., Кочкина А.Ф.* Муромский городок. Самара, 1998. 46 с.

Очерки истории исламской цивилизации. Т. 1. / Под ред. Ю.М. Кобищанова. М.: РОССПЭН, 2008. 936 с.

*Плетнева С.А.* Древние болгары в восточноевропейских степях // Татарская археология. 1997. № 1. С. 31–60.

*Рашев Р.* Прабългарите през V–VII век. София: БАН, 2004. 348 с.

*Рычков Н.П.* Журнал или дневные записки путешествия по разным провинциям Российского государства в 1769 и 1770 году. СПб., 1770. 189 с.

*Смирнов А.П.* Волжские булгары. (Тр. ГИМ. Вып. XIX). М., 1951. 275 с.

*Смирнов А.П.* Среднеазиатские элементы в архитектуре и строительном деле волжских болгар // Средневековые памятники Поволжья / Отв. ред. Г.А. Федоров-Давыдов. М.: Наука, 1976. С. 3–6.

*Старостин П.Н.* Раннее поселение на правом берегу Малого Иерусалимского оврага в Болгарах // Археология Волжской Булгарии: проблемы, поиски, решения / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: ИЯЛИ АН РТ, 1993. С. 53–63.

*Фахрутдинов Р.Г.* Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. 219 с.

*Халиков А.Х.* Кирпичное здание на XVII раскопе // Новое в археологии Поволжья. (Археологическое изучение центра Билярского городища) / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1979. С. 11–20.

*Халиков А.Х.* Ислам и урбанизм в Волжской Булгарии // Биляр – столица Волжской Булгарии / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1991. С. 47–60.

*Хвольсон Д.А.* Известия о хазарах, буртасах, болгарах, мадьярах, славянах и русах Абу-Али Ахмеда бен Омар Ибн-Даста, неизвестного доселе арабского писателя X века. СПб., 1869. 169 с.

*Хлебникова Т.А.* История археологического изучения Болгарского городища. Стратиграфия. Топография // Город Болгар. Очерки истории и культуры / Отв. ред. Г.А. Федоров-Давыдов. М.: Наука, 1987. С. 32–88.

Худуд ал-‘алем. Рукопись Туманского. С введением и указателем В. Бартольда. Л.: Изд-во АН СССР, 1930. 126 с.

*Хузин Ф.Ш.* Рядовые жилища, хозяйственные постройки и ямы цитадели // Новое в археологии Поволжья. (Археологическое изучение центра Билярского городища) / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1979. С. 62–99.

*Хузин Ф.Ш.* Великий город на Черемшане. Стратиграфия, хронология. Проблемы Биляра-Булгара. Казань: ИЯЛИ АН РТ, 1995. 223 с.

*Хузин Ф.Ш.* Булгарский город в X – начале XIII вв. Казань: Изд-во «Мастер-Лайн», 2001. 480 с.

*Хузин Ф.Ш.* Ранние булгары и Волжская Булгария. (VIII – начало XIII вв.). Казань, 206. 583 с.

*Шарифуллин Р.Ф.* Иранские параллели в архитектуре Волжской Булгарии домонгольского периода (по материалам Билярского городища) // Этнокультурные связи населения Урала и Поволжья с Сибирью, Средней Азией и Казахстаном в эпоху железа. Препринты док. и сообщ. Уфа: ИИЯЛ БФАН СССР, 1976. С. 50–51.

*Шарифуллин Р.Ф.* Исследования IV Билярского могильника в 1979 году // Археологические памятники Нижнего Прикамья / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань, 1984. С. 65–82.

*Якубовский А.Ю.* К вопросу об исторической топографии Итиля и Болгар в IX и X веках // Советская археология. 1948. Т. X. С. 255–270.

*Янин В.Л.* Денежно-весовые системы русского Средневековья. Домонгольский период. М.: Изд-во МГУ, 1956. 207 с.

*Янина С.А.* Новые данные о монетном чекане Волжской Болгарии X в. // Материалы и исследования по археологии СССР. № 111. (Тр. Куйбышев. археол. эксп. Т. IV) / Отв. ред. А.П. Смирнов. М.: Изд-во АН СССР, 1962. С. 179–204.

*Мәрҗани Ш.* Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр) / Китапны тәрҗемә итүче һәм төзүче Ә.Н. Хәйруллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 415 б.

*Хәйри Ә.* Әхмәд ибне Фадланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе. Казан: Сүз, 2013. 536 б.

*Khalikov A., Sharifullin R.* On the Development of Architecture in Premongolian Volga-Bulgaria // Acta Archaeologica Academiae Scientiarum Hungaricae. Budapest. 1977. № 29 (1–2). P. 199–202.

***Хуҗин Фаяз Шәрип улы,***
*тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы,*
*ТР ФА А.Х. Халиков исемендәге Археология институты*
*баш гыйльми хезмәткәре*

УДК 82.512.1-131

***Л.Х. Мөхәммәтҗанова***

# ТАТАР ДАСТАННАРЫ ҮСЕШЕНДӘ ИСЛАМНЫҢ РОЛЕ

В статье обобщается некоторые результаты исследования татарских дастанов. Рассуждая о роли ислама в формировании и развитии крупного эпического жанра фольклора и литературы в устном и письменном словесном творчестве, автор обращает особое внимание на героико-религиозную и любовно-религиозную тематику в классификации татарского эпоса. Стадиально поздняя группа национального эпоса в статье характеризуется с точки зрения проникновения в них мусульманской идеологии. Возникновение, становление и развитие данной группы эпос-дастанов автор рассматривает как результат интенсивного влияния ислама в народную культуру.

**Ключевые слова:** героико-религиозный эпос, любовно-религиозные дастаны, татарский эпос, влияние ислама, письменный фольклор.

The article summarizes some results of the study of Tatar dastans. Discussing the role of Islam in the formation and development of a large epic genre of folklore and literature in oral and written verbal creativity, the author pays special attention to the heroic-religious and love-religious themes in the classification of the Tatar epic. The stage-late group of the national epic is characterized in the article from the point of view of the penetration of Muslim ideology into them. The author considers the emergence, formation and development of this group of epic dastans as a result of the intense influence of Islam in folk culture.

**Key words**: heroic-religious epic, love-religious dastans, Tatar epic, Islamic influence, written folklore.

Ислам грамоталылыкны, укымышлылыкны, китапны һәрвакыт пропагандалавы белән мәшһүр, шуңа бәйле рәвештә мөселман мәдәниятенә ия халыкларның дөньяга карашлары формалашуга зур йогынты ясаган. Православие динендәге аз санлы керәшеннәрдән кала барлык татарлар – Россиядәге иң эре мөселман халкы. 922 елда Идел буе Болгарында ислам дине рәсми игълан ителгәннән соң (кайбер мәгълүматларга караганда, хәтта аннан да иртәрәк) борынгы татар халкының дөньяны танып белүе үсеш-үзгәреш кичергән булу гаять табигый. Хәлбуки ничәмә-ничә гасыр буена татар халкы гомумкешелек рухи кыйммәтләрен ислам аша үзләштерә килгән. Шуңа да татарларның мәкаль-әйтем, табышмак, риваятьләреннән алып, зур күләмле китаби эпос-дастаннарында да мөселманча тормыш рәвеше чагылган булу, алай гына да түгел, әлеге ядкярләрнең ислам мәдәнияте белән бик тирән сугарылган, керешеп беткән булуы бер дә гаҗәп түгел.

Билгеле булганча, татар эпосы ике зур төркемгә бүленә. Аның беренчесе каһарман батырлыгы турында сөйли торган героик дастаннар

булса, икенчесе – романик характердагы мәхәббәт сюжетлы әсәрләр. Әлбәттә, бик борынгы дәвердә, әле исламгача чорларга кадәр үк барлыкка килгән татар эпосы тоташтан мөселманлык идеяләренә буйсына дип әйтү дөрес булмас. Татар эпосы формалашуга тәэсир иткән факторлар арасында исламны аерып күрсәтү татар дастаннарының эчтәлегендәге һәм таралу рәвешендә булган үзенчәлекләргә барып тоташа. Татар эпосында архаик катламнардан алып мөселманлык чорындагы дәвергә кадәрге тормыш чалымлана, ә кайвакыт бер үк әсәр сюжетында әлеге катламнар гармоник дәрәҗәдә кушылып-буталып та киткән була. Ә инде эпосның таралу рәвешенә исламның тәэсире дигәндә, татар дастаннарының бик иртә китаби-язма рәвеш алу тенденциясен күздә тотабыз. Халык аңына ислам аша үтеп кергән китапка, язуга хөрмәт татар эпик фольклорына хас дастаннарның язма-китаби формада үсеп китүенә бик нык йогынты ясаган. Шуңа күрә татар халык иҗатында язма әдәбият белән фольклор чигендә торган китаби эпос башка төркиләргә караганда ныграк үсеш алган да.

Батырлык темасына багышланган яисә мәхәббәт сюжетына корылган татар дастаннары милләтнең тарихын, көнкүрешен, рухи кыйммәтләрен чагылдыра. Татар дастаннарының героикага нигезләнгәннәрендә курку белмәс батыр көрәшченең яуда зур җиңүләргә ирешүе, гашыйклар тарихына багышланганнарында исә ике гашыйкның мәхәббәт тарихы сурәтләнә. Ләкин әлеге әсәрләрнең әһәмияте батырлык яки мәхәббәт тарихын бәян итү белән генә чикләнми. Татар дастаннары әле Идел буе Болгары чорыннан ук ислам белән, дини идеология белән тыгыз бәйләнештә һәм бу – аларның җитди үзенчәлеге. Алай гына да түгел, гомумән, татар дастаны, бигрәк тә аның китаби төре, гасырлар буена язма мәдәният һәм ислам йогынтысында формалашкан. Идел һәм Урал буйларында гына түгел, гомумән Евразия далаларында сибелеп яшәүче татарларда киң таралып, татар дастаны халык тормышында эмоциональ-экспрессив дәрәҗәдәге рухи азык, тәэсирле язма, укып, күңел юату, вакыт уздыру чарасы гына булмыйча, тарихның халык өчен хәлиткеч әһәмияткә ия бер этабында үзенә күрә бертөрле идеологик функция дә үтәп килгән.

Дөнья, шул исәптән татар, рус һәм башка милләт галимнәренең фәнни-теоретик концепцияләрендә халык иҗатында эпик стиль һәм эпик семантика һәрвакыт конкрет тарихи җирлек белән бәйләп каралырга тиеш, дигән фикер уздырыла [Короглы, б. 15]. Эпос стиленә һәм эпос семантикасына хас сыйфатларның төп җирлеген конфессиональ, милли, социаль, географик, хронологик пландагы тарихи нигез барлыкка китерә, татар дастаннарының төп асылын билгеләүдә дә әлеге нигез турыдан-туры роль уйный. Бу шактый катлаулы тоелган фәнни концепцияне аңлау өчен, татарларның тарихи тормыш итү рәвешләрен, аларның фольклорында һәм әдәбиятында нәрсәгә өстенлек бирүләрен күзәтү җитә. Татарларның ислам динен тотуын, аларда

язмачылык, укымышлылык, мәгърифәтнең югары дәрәҗәдә булуы халыкның эпик иҗатына үз эзен салган.

Сөйләмә характердагы авыз иҗаты буларак буыннан-буынга күчеп саклана килгән фольклор төшенчәсе киңәеп, безнең көннәрдә «язма фольклор» гыйбарәсе барлыкка килү нәкъ менә халыкның грамоталыгына, дини һәм язма культурасы дәрәҗәсенә барып тоташа. Төркиләр арасында татарларда эпосның китаби төре нык үсеш алган булу да шуңа бәйле. Язу тарихы бик тирәннән килә торган халыклар өчен бу – табигый күренеш, ә татарлар нәкъ менә шундый югары мәдәниятле халыклар исәбенә керә. Ә инде исламның татар аңына тәэсире аның мәдәниятенең тагын бер баскычка югарырак күтәрелүе белән характерлана. Тарихчы һәм әдәбиятчы галимнәрнең тикшерү объекты булган кульязма дастаннарыбыз, ягъни ислам йогынтысын кичергән язма характердагы эпос авыз-тел иҗатын өйрәнүче фольклорчыларда зур кызыксыну уята. Язма-китаби төр дастаннар милли мирасыбызда бик зур урын били. Татарлар яшәгән төбәкләрдә әледән-әле табылып тора торган дини, әдәби, юридик, медицина, тарих һ.б. өлкәләргә караган кульязмалар арасында [Әхмәтҗанов, б. 5] иң зур күпчелекне фольклорның эпик төренә карый торган күләмле жанр үрнәкләре – эпос-дастаннар тәшкил итүе мәгълүм.

Дини эчтәлектәге эпик язма истәлекләребезнең бер өлеше халык эпосының героик характердагы дастаннары үрнәгендә иҗат ителгәннәр, шуңа күрә аларны героик дастаннар составына кертеп, героик эпос төркеменең аерым бер төре – дини-героик дастаннар дип карау дөрес булыр [Мөхәммәтҗанова, б. 40–47]. Болар, асылда – шул ук батырлык дастаннары, ягъни каһарманлык эпосы кебек үк героика белән сугарылганнар, әмма аларның дини теманы алга сөргәннәрендә ил һәм халыкның гадәттән тыш көчле батыры урынына пьедесталга дин юлында күрсәтелгән батырлык үрнәге күтәрелә, сюжет-вакыйгалар да исламга бәйле яктыртыла. Дини эчтәлек белән өретелгән эпоста сюжетлар, эпик образларга хас чикләнгәнлек дини элементлар белән баетыла, традицион героика дини героика белән алмашына.

Эпос кагыйдәләре традициясендә, үзенә тиң шәп атта моңа кадәр барлык дошманнарын махсус сугыш коралы ярдәмендә берүзе кырып салган каһарман дини-героик эпоста, дошманнарын җиңү өчен, Аллаһ ярдәменә таяна, алар белән Аллаһ теләгенә буйсынып көрәшә. Каһарманның дошманнары дини дошманнар сыйфатын ала, алар бик еш кына кяферләр дип бирелә. Әйтик, сүзләребезгә дәлил буларак, «Кисекбаш китабы», «Кыйссаи авык», «Кыйссаи Сәкам» кебек дастаннардан күпләгән мисал китерергә мөмкин булыр иде.

Дини характердагы героик эпос үрнәкләренең татар халкы рухи тормышында биләгән аерым урыны һәм үз функциясе бар. Халыкның милләт буларак сакланып калу-калмавында күп очракта илдәге сәяси вазгыять зур роль башкара. Билгеле бер чорда халыкта героик-

дини темага мөрәҗәгатьнең артуы сәяси факторга барып тоташа. Халыкның үз-үзен, мәдәниятен, традицияләрен, телен саклау инстинкты, героик эпос темасы буларак, дастан жанрында калкып чыга, әсәрдә халык каһарманы үз илен, үз ыруын яклап дошманнар белән сугыша, аларны җиңә, халык эпосы татар телендә шушы вакыйгалар хакында эпик картина тудыра. Ә инде моңа кадәр берәүгә дә буйсынмый торган каһарманның әкренләп ислам кысаларына кертелүен халыкның авыр вазгыятьтән чыгу юлын исламда күрүе белән аңлатырга мөмкин. Дастан эчтәлегендә героиканың дини-героикага күчүе – катлаулы чорда халыкның исән калырга омтылу чарасы ул. Элгәрләре табынган ислам динендә, Аллаһ кодрәтенә ышануда халык милли һәм дини кысрыклаудан котылу һәм тынычлану тапкан. Бу исә дини эчтәлекле, күптән мәгълүм дастани сюжетларның яңаруына, героик өлгеле, ягъни каһарманлык фәлсәфәсе белән сугарылган, әмма дини характерлы дастаннарны күчереп таратуның артуына йогынты ясаган. Дәүләтчелек, рухи бәйсезлек проблемалары хакында турыдан-туры сөйләп булмаган чор өчен мондый дастаннарның әһәмияте бик зур булган.

Нәтиҗәдә, Мәскәү хаимлегендәге яңа социаль-сәяси шартлар татарларда героик-дини дастаннарның ныклы үсеш алуына сәбәп булган. «Каһарман Катил», «Кыйссаи авык», «Кыйссаи Сәкам», «Кисекбаш», «Дастаны Җөмҗөмә» кебек дастаннарның күпләгән вариантлары – татарларда әнә шундый истәлекләрдән. Казан ханлыгының XVI гасыр урталарыннан кинәт көчәеп киткән рус дәүләте тарафыннан яулану вакыйгаларына багышланган, классик тарихи-героик эпос төркеменә керә торган «Чура батыр» дастанының татар версиясенә игътибар итсәк, биредә дә ислам йогынтысының алга чыгуын, шулай ук героиканың әкренләп дини героика белән алышынуын күрәбез. Дастанда дошманнар сыйфатында «кяферләр» күздә тотыла; мәчетләр, «Аллаһулап азан әйттерүләр» һ.б. дини элементлар телгә алына.

Каһарман батырлыгы дини героика белән алышынган дастаннарда герой сугыш-көрәш картиналарында һәрвакыт Аллаһка тапшырып эш итә, вакыт исәбе намаз вакыты белән билгеләнә, намаз вакыты кергәч, сугыш туктап тора. Дастанда дошманнарга каршы баручы яу ачыктан-ачык ислам идеяләре өчен көрәшә. Мондый мисалларны, әйтик, татарларда XVIII гасырда популярлашкан «Каһарман Катил» дастанында күпләп табарга була.

Татар ханлыкларының бер-бер артлы рус дәүләте тарафыннан яулану чоры вакыйгаларын бәян иткән «Чура батыр»ның да, мөселман илендәге ислам гаскәренең героик маҗаралары хакында сөйли торган «Каһарман Катил» дастанының да, татар дәүләтчелеге мәсьәләләрен алга сөргән «Кыйссаи Сәкам»нең дә, дини каһарманлык дастаны «Кисекбаш»ның да татарлар тарафыннан яратып кабул ителүенең төп сәбәбе – аларның халык кабул иткән исламча яшәү рәвешен алга куйган ядкярләр булуында. Аларның һәркайсында батыр мөселман

каһарманы дошманнары белән аяусыз көрәшкә күтәрелә, берүзе, батырларча сугышып, җиңүгә ирешә яисә һәлак була, әмма беркайчан җиңелми. Дини-героик эпос каһарманнары, традицион рәвештә, татар халкында курку белмәс һәм җиңелмәс гадәттән тыш батыр образын гәүдәләндерә.

Башка дини конфессиядәге дәүләт составында гомер кичергән мөселман-татарлар, илдәге тәртипләр белән ачыктан-ачык көрәшмәсәләр дә, атаклы «Кисекбаш» вариантлары, маҗаралы сюжетка ия «Каһарман Катил», татар дәүләтчелеге мәнфәгатьләрен алга сөргән «Кыйссаи Сәкам» кебек дини-героик дастаннары аша хөкүмәтнең эчке һәм тышкы сәясәте өлкәсендә үз сүзләрен әйткәннәр. Мондый дастаннарда көрәшнең бөтен дөньяда ислам җиңүенә юнәлтелгән булуы бик зур эчке мәгънәгә ия. Татарларның дини-героик, ягъни дини каһарманлык дастаннары – фәлсәфи рухлы һәм бай идея-эстетик кыйммәткә ия әсәрләр.

Героик характердагы дастаннардан тыш татар эпосының тагын бер төре – Идел һәм Урал буе татарларында киң таралган мәхәббәт дастаннарының да дини караш белән сугарылган булуы игътибарны җәлеп итә. Үзәгендә героика түгел, ә романтика булган дастаннарның татар вариантлары безнең әдәбиятка һәм фольклорга суфи идеология белән өретелгән Көнчыгыш әдәбияты аша килеп кергән. Корьән Кәримгә ияреп иҗат итү методына нигезләнгәнлек тә мондый төр халык иҗаты әсәрләрендә үзен бик нык сиздерә. Күп гасырлар дәвамында иҗат кешеләре, чичәннәр өчен ислам нигез дә, илһам чыганагы да булган. Әйтик, «Йосыф китабы» дигән исем белән таралган, Корьәннең уникенче «Йосыф» сүрәсе һәм Кол Гали исеме белән бәйле дастан вариантлары, «Мең дә бер кичә»дән башлангыч алган «Сәйфелмөлек», Сайади, Кормашиныкыннан башка да дистәләгән вариантларда билгеле «Таһир-Зөһрә» сюжетлы дастаннары, Баһави, Кормаши исеме белән мәгълүм күчермәләре табылган «Бүз егет», атаклы Низамига ук барып тоташа торган «Ләйлә белән Мәҗнүн» һ.б. романик эпик ядкярне халкыбыз бик нык үз иткән.

Ислам йогынтысын кичереп яңа бер форма алган, фольклорда һәм әдәбиятта үз урынын булдырган эпос-дастаннарыбыз – мәхәббәт тарихын бәян итәме ул, героик эпосмы – үз эчендә әллә никадәр серләр саклый, тамыры борынгы мифологиягә үк китә торган, әмма асылда ислам кысасына җиңел ярашкан язма ядкярләр. Татар халкы үзенең яшәү-тереклек итүе дәверендә нәкъ менә дини характердагы эпос-дастаннарга бик еш мөрәҗәгать иткән; мондый ядкярләр тарихи үсешнең татарлар өчен үзенчәлекле чорларында халыкка милли үзаңны, милли үзбилгеләнүне саклап калу чарасы булган. Дини-героик һәм дини-романик характердагы әсәрләр – татар эпосының иң соң формалашып таралган төре; халыкның дастани мирасын бөтен тулылыгы белән барлаганда, эпик иҗатның бу төренә карый торган һәр ядкяр аерым фәнни игътибарга лаек. Аларны төрле аспектта тикшерү,

шул исәптән милли эпик иҗатка ислам тәэсирен күзәтү җәһәтеннән өйрәнү – филология фәненең әһәмиятле бурычы.

**Әдәбият**

*Әхмәтҗанов М.* Татар кулъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 270 б.

*Короглы Х.Г.* Древнетюркская письменность // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). Казань: ФЭН, 1999. С. 11–40.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Дөнья цивилизациясендә татар дастаннары. Казан: ТӘһСИ, 2018. 280 б.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге*
*баш фәнни хезмәткәре*

УДК 821.411.21

***А.М. Ахунов***

# ИБНЕ ФАЗЛАН «ЯЗМАЛАР»ЫНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕНӘ БЕРЕНЧЕ ФӘННИ ТӘРҖЕМӘСЕ ТУРЫНДА

В данной статье анализируется первый научный перевод «Рисале» Ибн Фадлана (X в.) на современый татарский язык, выполненный напрямую с арабского языка в 1960-е гг. в г. Баку Дж.-С. Мамедовым. Данный труд долгие годы оставался неизвестным широкому читателю, хранился в рукописи и был опубликован лишь в 2003 г. Перевод Дж.-Мамедова является удачным в плане более точной передачи ряда встречающихся в трактате Ибн Фадлана этнонимов, топонимов и гидронимов, в целом, адекватнее передает дух арабского оригинала, помогает представить его как целостное, логически законченное произведение.

**Ключевые слова:** Ибн Фадлан (X в.), Дж.-С. Мамедов, Волжская Булгария (X в.), Ислам в Поволжье, арабская географическая литература.

This article analyzes the first scientific translation of Ibn Fadlan's «Risale» (X century) into modern Tatar language, made directly from Arabic in the 1960s in Baku by J.-S. Mamedov. This work remained unknown to the general public for many years and it was kept as a manuscript and was published only in 2003. The translation of J.-S. Mamedov is successful in terms of more accurate transmission of a number of ethnonyms, toponyms and hydronyms found in Ibn Fadlan's treatise, in general, this translation conveys the spirit of the Arabic original, helps to present it as a holistic, logically complete work.

**Keywords:** Ibn Fadlan (X century), J.-S. Mamedov, Volga Bulgaria (X century), Islam in the Volga region, Arabic geographical literature.

Багдад илчелеге сәркатибе Әхмәд Ибне Фазлан «Язмалары» бүгенге көнгә кадәр X гасыр Идел буе һәм Урал яны халыклары тарихы буенча иң тулы һәм ышанычлы гарәп чыганагы булып тора. 921–923 елларда Габбасилар хәлифәсе әл-Моктәдир (908–932 еллар) илчелеге составында ул Харәзем, Устюрт платосы һәм Урал яны далалары аша Идел Болгарына сәяхәт кыла. Бу сәфәр Болгар ханы инициативасы белән оештырыла: ул, хәзәрләр хакимлегеннән котылырга теләп, хәлифәдән болгарларны үз канаты астына алуын сорый һәм ислам динен кабул итәргә вәгъдә бирә. 921 елда илчелек Багдадтан чыгып китә һәм 922 елның маенда Идел Болгарына килеп җитә. Ибне Фазлан (мөгаен, илчелектәге икенче кеше) әлеге сәяхәт турында тәфсилле хисап калдыра һәм анда угызлар, башкортлар, болгарлар һәм хәзәрләр турында этнографик характердагы күп кенә уникаль мәгълүматлар китерелә. Моннан тыш, Ибне Фазлан Болгарда русларны күргән һәм аларның күмү йоласын җентекләп тасвирлаган.

Ибне Фазлан «Язмалар»ын татар галимнәре арасында беренчеләрдән булып Шиһабетдин Мәрҗани өйрәнә. Ике томнан торган «Мөстәфадел-әхбар фи әхвале Казан вә Болгар» (Казан, 1885, 1890)

дип аталган тарихи хезмәтендә ул гарәп галиме Йакут әл-Хәмәви[1] (1179–1229) төзегән «Географик сүзлек»тән күләмле өземтәләр китерә, чөнки ул вакытта «Язмалар»ның оригиналь тексты табылмаган була әле.

1923 елдан, Иранның Мәшһәд шәһәрендә танылган тюрколог Әхмәт-Зәки Вәлиди Тоган Ибне Фазлан текстының иң тулы нөсхәсен тапкач, «Язмалар»ны өйрәнүдә яңа чор башлана. 1937 елда Иран хөкүмәте СССР Фәннәр академиясенә Мәшһәд кулъязмасының фотокүчермәсен бүләк итә, һәм шуның нигезендә А.П. Ковалевский[2] аны 1939 елда рус телендә[3] матбугатка әзерли, 1956 елда ул Харьковта, эшкәртелеп һәм тулыландырылып, икенче тапкыр басыла [Ковалевский, 1956].

Шунысы кызык: А.П. Ковалевский белән бер үк вакытта диярлек, Ибне Фазлан «Язмалар»ының гарәп телендәге тәнкыйди текстын һәм немец теленә тәрҗемәсен Әхмәт-Зәки Вәлиди Тоган да 1939 елда Лейпцигта бастырган [Togan, 1939].

Күп еллар дәвамында А.П. Ковалевскийның тәрҗемәсе эталон булып саналган, һәм ул бүгенге көндә дә үзенең әһәмиятен югалтмый. Шуңа да карамастан, тикшеренүчеләр бу хезмәттәге билгеле бер җитешсезлекләрне билгеләп үткәннәр, һәм бу еш кына төрки чыгышлы топонимнарны, гидронимнарны һәм этнонимнарны адекват тәрҗемә итү проблемаларына кагыла.

Чыганакны татар теленә тәрҗемә иткән очракта, мондый характердагы күп кенә мәсьәләләр хәл ителгән булыр иде. Чөнки аны арадаш тел аша бастырып чыгарганда, грамматик планда да, логик-мәгънәви планда да югалтуларның булуы котылгысыз. Шуңа да карамастан, озак вакытлар дәвамында бездә әлеге истәлекнең татар теленә тулы кыйммәтле тәрҗемәсе булмады (Ш. Мәрҗани һәм Р. Фәхреддин хезмәтләрендә урын алган кыска-кыска өзекләрне исәпкә алмаганда).

Ибне Фазлан «Язмалар»ының гарәпчәдән татар теленә тулы фәнни тәрҗемәсенең булуы һәм аның 1960 елларда ук Баку татары Җәгъфәр-Садыйк Мамедов тарафыннан башкарылганлыгы турында күпләр хәтта белми дә. 1970 еллар башында, татар драматургы һәм галиме Нәкый Исәнбәт тәкъдиме белән, бу тәрҗемәдән алынган аерым өзекләр «Казан утлары» журналында басылып чыга [Мамедов, б. 152–159]. 1978 елның ноябрендә Алимбәк Вәлиев әлеге кулъязма-

---

[1] Йакут үзенең безнең көннәргә берничә нөсхәдә килеп җиткән «Географик сүзлеге»нә Ибне Фазланнан берничә өземтә керткән.

[2] Аның турында кара: [Авербух, с. 161–172].

[3] Хезмәт академик И.Ю. Крачковский редакциясендә башкарылган. Ул хакимияткә Ибне Фазланның хезмәтен тәрҗемә итү өчен А.П. Ковалевскийны тәкъдим иткән булган. Украина галиме бу вакытта ЧК төрмәсендә утырган һәм аны, тәрҗемә өстендә эшләү өчен, Ленинград төрмәсенә махсус күчергәннәр. 1939 елда Ибне Фазланның «Язмалар»ы тәрҗемәчесе күрсәтелмичә генә дөнья күргән. Кара: [Юлдашбаев, с. 163].

ның төп нөсхәсен ТАССР Дәүләт музеена (ТР Милли музее) тапшыра һәм ул хәзер дә шунда саклана.

2000 еллар башында Татарстан Республикасы Дәүләт музееның өлкән фәнни хезмәткәре Рәмзия Абзалина инициативасы һәм тырышлыгы белән Җ.-С. Мамедовның кулъязмасы аерым китап булып басылып чыкты [Әхмәд Ибн Фадлан китабы]. Моннан тыш, бу басманың факсимилесе дә була. Ул гына да түгел, әлеге проектны гамәлгә ашыруда галим-археограф, филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов һәм ул вакытта ТР Үзәк төбәге казые (мөселман судьясы) вазифасын башкарган Камил хәзрәт Бикчәнтәевнең дә роле зур була.

Китап турында сөйләргә керешкәнче, шуны әйтәсе килә: тәрҗемә, һичшиксез, дөрес һәм җиңел укыла торган татар телендә. Иң мөһиме, җиңел бәянга оригиналь гарәп текстын гадиләштерү яки үзгәртү исәбенә ирешелми.

Без Җ.-С. Мамедов вариантын Ибне Фазлан текстының гарәп оригиналы (тәнкыйди тексты 1960 елда Сүрия галиме Мөхәммәд Сами әд-Даххан[1] тарафыннан чыгарылган [Даххāн, 1960]) белән чагыштырып чыгып, тәрҗемәгә чагыштырма анализ ясадык. Шунысы игътибарга лаек: Мамедов текстны тулысынча тәрҗемә иткән, кайбер җитешсезлекләрен исәпкә алмаганда, ул тулы кыйммәтле фәнни хезмәт дип саналырга хаклы[2]. Моннан тыш, тәрҗемәче тарафыннан эшләнгән шәрехләмәләрне дә искә алып үтәргә кирәк. Алар китапның ахырында урнаштырылган. Күләме һәм фәнни әһәмияте ягыннан алар аерым, мөстәкыйль тикшеренү булып тора һәм бик күп кызыклы һәм үзгә мәгълүматны үз эченә ала.

Ибне Фазлан «Язмалар»ының тәрҗемәсендә төп проблемаларның берсе – «сакләба» этнонимын адекват аңлату мәсьәләсе. Традиция буенча, Россия шәркыятендә бу сүзне «славяннар» дип тәрҗемәләү кабул ителгән. Бу фикер тотрыклы дип саналса да, аның тирәсендә барган бәхәсләрнең әле дә туктаганы юк. Эш шунда ки, Россия шәркыятьчеләре «сакләба» итеп бары славяннарны гына күрергә тели һәм башка вариантларны кабул итми [Гаркави, с. 74; Бартольд, с. 870; Новосельцев, с. 368–369; Мишин, 2002]. Татар галимнәре исә «болгарлар», «кыпчаклар» яисә «төркиләр» дип тәрҗемә итү дөресрәк була дип саныйлар [Зәкиев, с. 68–81]. Бу темага күпсанлы мәкаләләр басылып тора [Мухаметдинов, с. 53–57] һәм хәтта диссертацияләр яклана [Мишин, 1999].

А.П. Ковалевский бу этнонимны түбәндәгечә тәрҗемә итә: «Сказал Ахмед ибн-Фадлан: когда прибыло письмо Алмуша сына Шилки Йылтывара, царя «славян», к повелителю правоверных…» [Ковалевский, 1956, с. 121]. Күргәнебезчә, «славяннар» сүзен ул куштырнаклар

[1] Аның турында безнең мәкаләне кара: [Ахунов, с. 57–64].

[2] Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: бүгенге көнгә кадәр татар телендә Ибне Фазлан «Язмалар»ы тәнкыйди текстының тулы кыйммәтле академик басмасы юк. Ә. Хәйринең 2013 елда нәшер ителгән хезмәтен фәнни-популяр басмаларга кертергә мөмкин. Кара: [Хәйри, 2013].

эченә ала, бу бер генә нәрсәне аңлата ала – тәрҗемәче бу сүзнең нәкъ менә «славяннар»ны гына белдерүенә тулысынча ышанып бетми. Ул тагын да алдарак болай дип билгеләп үтә: «…так как авторы не слишком хорошо разбирались в этнических признаках, а тем более в языках северных народов, то этим термином сплошь и рядом обозначали всевозможные северные народы и германцев на Рейне, и финнов, и булгар. Таким образом, приходится в каждом отдельном случае решать вопрос, какое содержание вкладывал в это слово данный автор» [Ковалевский, 1951, с. 193].

Сүрия тикшеренүчесе Сами әд-Даххан тарафыннан Мәшһәд кулъязмасы буенча эшләнгән гарәп оригиналына күз салыйк. Гарәп текстында бу өзек түбәндәгечә: «Кала Ахмад Бну Фадлан: ламма васала китаб Алмуш бну Йалтуар малик ас-сакалиба иля амир-у-л-му’миниин…» [Даххан, с. 67]. Сами әд-Даххан астөшермәдә «ас-сакалиба» сүзен аңлатканда, гарәп традициясендә бу термин белән славяннарны атыйлар дип белдерә. «Аларның илләреннән гарәпләргә коллар китергәннәр». Шуның белән беррәттән, ул Көнбатыш тикшеренүчеләренең болгарлар һәм сакләбаның бер үк нәрсәне аңлата дип уйлауларын да билгеләп үтә. Һәм «ас-сакалиба» Багдадтан илчелек килгәнче үк мөселманнар булган дип санаган гарәп тарихчыларының фикерен җиткерә [шунда ук, б. 67].

Җ.-С. Мамедов бу өзекне болай тәрҗемә иткән: «Әхмәд Ибне Фадлан әйтте: сакләбләр падишасы Балтуар углы Әл-Хәсәннең дин кагыйдәләрен өйрәтергә…илчеләр җибәрүне үтенеп язган хаты Әл-Мөкътәдиргә тапшырылгач, бу үтенечләрне кабул иттеләр» [Әхмәд Ибн Фадлан китабы, б. 26]. Күрүебезчә, татар тәрҗемәчесе бу сүзнең гарәп телендәге язылышын калдырган, бу – әлеге ситуациядә иң яхшысы. Мондый карарга килүне шәрехләп [шунда ук, б. 90], ул әлеге терминның шактый үзенчәлекле аңлатмасын бирә. Мамедовның язуына караганда, гарәпләр, мөгаен, мөселман булмаган бөтен халыкларны «сакалиба» дип кабул иткәннәр һәм бу очракта болгарлар да, чувашлар да, удмуртлар да һ.б. халыклар да шул исем белән аталган [шунда ук, б. 91].

Моннан тыш, тәрҗемә авторы «сакалиба» хөкемдары исеменең А.П. Ковалевский һәм Сами әд-Даххан вариантларындагыдан үзгә язылышын бирә: «Балтуар углы Әл-Хәсән» формасында, ә «Алмыш ибне Йалтуар», һәм бигрәк тә «Алмыш ибне Шилки Йылтуар» дип түгел. Шунысы кызык: бу очракта Җ.-С. Мамедов бик хаклы булып чыга, чөнки ул Мәшһәд кулъязмасында бу исемнең гарәпчә төп нөсхәдәге язылышын калдыра «әл-Х.с.н. Б.л.т.у.а.р» [Әхмәд Ибн Фадлан китабы, б. 139].

«Язмалар»ны өйрәнгән гарәп тикшеренүчесе Сами әд-Даххан үзенең текстында «сакалиба» хөкемдарының исемен «әл-Хәсән Балтуар» дип түгел, ә «Алмыш бине Йалтуар» рәвешендә язганда, төп нөсхәдән читкә китүне аңлатып, әлеге тәңгәллекнең шул ук затның башка урында «Алмубна Шилка», ә Йакутның «Алмубна Шилка

Йалтуар» дип аталуы белән бәйле, дип ачыклык кертkән. Боларның барысы да аның хөкемдарның исемен «Алмыш бине Йалтуар» дип унификацияләвенә нигез була, чөнки «әл-Хәсән...» язылышы – аның сүзләренә караганда, җан исәбен алучыларның хатасы [Әхмәд Ибн Фадлан китабы, б. 67]. Бу өзекне аңлаткан астөшермәдә [шунда ук, б. 92], Мамедов шулай ук җан исәбен алучыларның хатасына һәм «Алмыш» исемен «әл-Хәсән» дип язуга сылтама ясый, әмма ничек кенә булмасын, ул төп нөсхәдән читкә китми һәм аның тәрҗемәсе күпкә ышанычлырак. «Балтуар»[1] исемен аңлатуга карата да ул үз фикерен әйтә: биредә шулай ук җан исәбе алучы хата ясаган, чөнки «Балтуар» (Мамедовча дөрес вариант – «бәлкуар») – ул исемнең бер өлеше түгел, ә хөкемдарның титулы, төрки телдән «белүче», «галим» дип тәрҗемә ителә.

Тарих тагын бер шундый очракны саклаган. Әле 1944 елда ук Казан галиме, бик күп телләр белгән Әхмәт Булатов үзенең академик Д. Грековка язган хатында Ибне Фазлан «Язмалар»ы тәрҗемәсендәге кайбер төгәлсезлекләрне күрсәтә. Аерым алганда, ул үзе тәрҗемә иткән вариантта «Алмыш хан» исемен – «әл-Хәсән», ә «Шилка»ны, «Билге» дип укырга тәкъдим иткән [Ислам, 2001]. Сүз уңаеннан, А.П. Ковалевский тәрҗемәсендәге төгәлсезлекләр мәсьәләсе хәзерге заман Россия шәркыятьче галимнәре тарафыннан да күтәрелә [Большаков, с. 54–63].

Тагын бер гадәттәгечә бәхәсле мәсьәләгә – Ибне Фазлан «Язмалар»ындагы чувашизмнар проблемасына тукталасы килә. Мәгълүм булганча, чуваш тарихчылары һәм телчеләре әлеге истәлек текстындагы «Хеллече», «Гаушерма», «Атал», «сюдже», «суаз», «вырах» кебек сүз һәм гидронимнар чуваш теленеке дип, шуның нигезендә Идел болгарларының чувашча сөйләшүләре турында нәтиҗә ясыйлар.

Бу проблема галим-тюрколог, филология фәннәре докторы М.З. Зәкиев монографиясендә аеруча җентекләп тикшерелгән [Закиев, 2003, с. 322–331]. Татар галиме билгеләп үткәнчә, кайбер сүзләр, мәсәлән, «Хеллече» («Язмалар»ның А.П. Ковалевский әзерләгән беренче басмасында «Халҗа» дип транскрипцияләнгән), соңыннан чуваш галимнәре йогынтысы астында «хелле» («зима») дигән чуваш сүзенә тиңләштерү һәм шул ук вакытта бу гидронимга «болгар патшасының кышкы торулыгы» дигән мәгънә бирү өчен чувашлаштырылган [шунда ук, б. 322].

Югарыда телгә алынган гарәп галиме Сами әд-Даххан да бу сүзне аңлатырга тырышкан. «Х.л.җ.т.» күленең атамасын тикшергәндә, гарәп географы Ибн Варди (1457 елда вафат) хезмәтенә таянып, төрле вариантлар тәкъдим итә, шул исәптән бу хәзәр шәһәрләренең берсе булырга мөмкин дип фаразлый. «Җ.а.у.ш.и.р» елгасының атамасын-

[1] Мәшһәд кульязмасының рецензияләнә торган китапта китерелгән факсимилесендә «Балтуар» сүзендә бер генә нокта күренә – димәк, «Йалтуар» түгел, ә «Балтуар». Кызганычка каршы, әлеге материалны язганда безнең кулда кульязманың әлеге сүзнең язылышына төзәтмәләр кертерлек тәфсилле факсимилесе юк иде.

да ул Актай елгасын да, Каманың бер кушылдыгын да күрә [Даххан, с. 110]. Җ.-С. Мамедов «х.л.җ.т.» сүзен – «Хөлҗә» [Әхмәд Ибн Фадлан китабы, б. 63], ә «Җ.а.у.ш.и.р.» гидронимын «Җаушир» дип транскрипцияли [Шунда ук, б. 115]. Нәкъ менә шундый аңлатманы шәрехләп, ул аларның төрки-татар тамырларын ачып бирә һәм аларны чуваш сүзләре дип аңлатырга мөмкинлек калдырмый.

Бүгенге көнгә кадәр болгар патшасы кунакларны сыйларга яраткан «суджув» эчемлеге тирәсендә дә бәхәсләр тынмый. Бу сүз славяннарның «соты»сын белдерә дигән фикер дә бар (А.П. Ковалевский, Б.Н. Заходер) яки төрки халыкларның «шәраб»ын, «татлы эчемлек»не [Закиев, 1995, с. 72]. Бу сүзне Сами әд-Даххан үзе «ас-с. джу» рәвешендә җиткерә. Ул шулай ук гарәп телендәге «әл» артикленнән башка «суджу», «суджи» вариантларын да тәкъдим итә. Галим бу сүзне үзенең төгәл аңлатып бирә алмавын таный. Ул аны «хәмер» («шәраб») дип тәрҗемә иткән шәркыятьчеләр фикеренә таяна. Әмма үзе барыбер моңа шикләнә һәм шәех Ибне Фазлан берничек тә шәраб эчә алмый дип саный. Һәм шунда ук, үз-үзенә каршы килеп, Ибне Фазлан шәраб эчкән дип раслаган Йакутның сүзләрен китерә [Мөхәммәтдинов, с. 53–57]. Сорау ачык кала. Ибне Фазлан «Язмалар»ының татар теленә тәрҗемәләүчесенә килгәндә, ул бу сүзне «сеҗү» дип транскрипцияли һәм «әче бал» дип тәрҗемә итә [Әхмәд Ибн Фадлан, б. 50].

Җ.-С. Мамедов тәрҗемәсенең оригиналь өлешләре турында сөйләгәндә, гарәп илчелеге башлыгы Сусан ар-Расси исеменең гадәти булмаган аңлатмасын да онытырга ярамый. Аның фикеренчә, бу исем Сәһсән әр-Рәсиби дип язылырга тиеш [Әхмәд Ибн Фадлан китабы, б. 96]. Йакут әл-Хәмәвидә аның нәкъ менә шушы транскрипциясе бирелгән, татар галиме Шиһабетдин Мәрҗани аны шулай ук атаган. Җ.-С. Мамедов моны шуларга таянып нигезли. Татар тәрҗемәчесе билгеләп үткәнчә, Мәшһәд кулъязмасын игътибар белән карасак, «Расси» сүзенең ахырында «йай» хәрефеннән соң куелган ноктаны күрергә мөмкин – димәк, бу сүзне «Рәсиби» дип укырга кирәк. Моннан тыш, ул Шиһабетдин Мәрҗанинең Сусан ар-Рассиның X гасыр башында Васита шәһәре тирәсендә яшәгән төркиләр әмире Әбел-Хәсән Гали ибне Әхмәт әр-Рәсиби нәселеннән чыгуы турындагы фикере белән килешә [Әхмәд Ибн Фадлан китабы, б. 96]. Сами әд-Даххан үзе исә, әл-Идрисигә нигезләнеп, Сусан ар-Расси исеменең этимологиясен «нәһр ар-рус» (руслар елгасы) гидронимы белән бәйләп, Идел елгасыннан килеп чыккан дип аңлата.

Җ.-С. Мамедов китабы Йакут әл-Хәмәвинең «Географик сүзлеге»ндәге өлешләр белән тулыландырган. Алар «Язмалар»ның Мәшһәд кулъязмасында бөтенләй юк. Сүзлекнең ахырында һәм аерым китерелсәләр дә, әлеге әсәрне бербөтен итәләр.

Ибне Фазлан «Язмалар»ының татар телендә басылып чыккан беренче тәрҗемәсе татар гуманитар фәне өчен зур кыйммәткә ия. Киләчәктә башка мөһим Көнбатыш һәм Көнчыгыш чыганаклары да

оригинал теленнән татарчага күчерелер дип өметләнәбез, аларны без әлегә икенчел тәрҗемәләре буенча гына беләбез.

**Әдәбият**

*Авербух С.И.* А.П. Ковалевский – исследователь путешествия Ибн Фадлана на Волгу // Страны и народы Востока. Вып. XXVIII. СПб.: Центр Петербургское востоковедение, 1994. С. 161–172.

*Ахунов А.М.* Сами әд-Даххан – арабский исследователь «Рисале» Ибн Фадлана // Диалог культур Евразии: Вопросы средневековой истории и археологии. Изучение и сохранение историко-культурного наследия / Под. ред. А.А. Бурханова. Вып. 2. Казань: Изд-во ТГГИ, 2001. С. 57–64.

*Бартольд В.В.* Арабские известия о русах // Бартольд В. В. Сочинения. М., 1963. Т. 2. Ч. 1. С. 810–858.

*Гаркави А.Я.* Сказания мусульманских писателей о Славянах и Русских: (с половины VII в. до конца X в. по Р. Х.) / собр., пер. и объясн. А. Я. Гаркави. СПб., 1870. IX. 308 с.

[Даххан] Мухаммад Са̄ми ад-Дахха̄н. Риса̄лат Ибн Фадла̄н. Дамаск, 1960.

Әхмәд Ибн Фадлан китабы / Ж.-С. Мамедов тәрҗемәсендә. Казан: Таң-Заря, 2003. 171 б.

*Закиев М.З.* Татары: проблемы истории и языка. Сб. статей. Казань, 1995. 464 с.

*Закиев М.З.* Происхождение тюрков и татар. М.: Инсан, 2002. 496 с.

*Ислам З.* Гыйлемэстәр Әхмәтшакир мирасы // Шәһри Казан, 2001. 28 сент.

*Ковалевский А.П.* Книга Ахмеда ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Харьков: Изд-во. Харьковского гос. университета им. А.М. Горького, 1956. 345 с.

*Мамедов. Җ.* Әхмәт Ибне Фазланның Идел буе болгарларына сәяхәте // Казан утлары. 1972. № 8. Б. 152–159.

*Мишин Д.Е.* Сакалиба (славяне) в исламском мире в раннее средневековье. М.: Институт востоковедения РАН – Крафт+, 2002. 368 с.

*Мухаметдинов Р.Ф.* Что кроется за этимологией слова «сакалиба» // Научный Татарстан. 1999. № 4. С. 53–57.

*Новосельцев А.П.* Восточные источники о восточных славянах и Руси VI–IX вв. // Древнерусское государство и его международное значение. М., 1965. С. 368–369.

*Хәйри Ә.* Әхмәд ибне Фадланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе: (татар теленә яңача тәрҗемә һәм фәнни аңлатмалар). Казан: Сүз, 2013. 532 б.

*Юлдашбаев А.М.* Известный и неизвестный Заки Валиди (в памяти своих современников). Уфа: Китап, 2000.

*Togan A.Z.* Ibn Fadlān's Reisebericht. Leipzig: Kommissionverlag F.A. Brockaus, 1939. XXXIV + 336 P. + 54 стр. в арабской пагинации.

***Ахунов Азат Марс улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 82-21; 792.2

*Е.Н. Шевченко*

# ӘЛМӘТ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ТЕАТРЫ СӘХНӘСЕНДӘ НЕМЕЦ ДРАМАТУРГИЯСЕ

В настоящей статье рассматриваются спектакли Альметьевского татарского государственного драматического театра по немецкой драматургии. Театр активно работает с зарубежной классикой, которая составляют внушительную часть его репертуара. Это постановки немецких, французских, итальянских, испанских, английских, американских, греческих, бразильских, турецких, словацких драматургов. Немецкая драматургия представлена четырьмя названиями: «Коварство и любовь» (1999) Фридриха Шиллера, «Мещанская свадьба» (2013) и «Добрый человек из Сычуани» (2015) Бертольта Брехта, и «Медея-Материал» (2017) Хайнера Мюллера / Еврипида. Эти спектакли стали важным этапом в эстетических поисках театра, освоении им различных художественных систем, совершенствовании актёрского мастерства исполнителей.

**Ключевые слова:** Альметьевский татарский государственный драматический театр, зарубежная классика, немецкая драматургия, художественные традиции, сценическая интерпретация, синтез традиций.

This article discusses the performances of the Almetyevsk Tatar State Drama Theater based on German drama. The theater works with foreign classics, which makes up an impressive part of its repertoire. These are productions by German, French, Italian, Spanish, English, American, Greek, Brazilian, Turkish, Slovak playwrights. German drama is represented by four titles: «Intrigue and Love» (1999) by Friedrich Schiller, «A Respectable Wedding» (2013) and «The Good Person of Szechwan» (2015) by Bertolt Brecht, and «Medea-Material» (2017) by Heiner Müller / Euripides. These plays have become a milestone in the aesthetic search of the theater, in the mastering of various artistic systems, and in the improvement of the acting skills of the actors.

**Key words:** Almetyevsk Tatar State Drama Theatre, foreign classics, German drama, artistic traditions, stage interpretation, synthesis of traditions.

Татар театрына немец драматургиясе иң элек Фридрих Шиллер пьесалары аша килеп керде. Алар революциягә кадәр үк оешкан «Сәйяр», «Нур» һәм «Ширкәт» труппаларында куелган. 1913 елның 29 мартында «Сәйяр» труппасы «Мәкер һәм мәхәббәт» («Коварство и любовь») спектаклен (режиссеры А.С. Загорский) сәхнәгә куя: татар театры беренче тапкыр немец драматургиясенә генә түгел, гомумән Көнбатыш Европа классикасына мөрәҗәгать итә. М. Арсланов татар театрының киләчәктәге үсеше өчен дә моның әһәмияте зур булуын ассызыклый: актерлар зур тәҗрибә туплый; спектакль барлык сәнгати чараларның – декорация, костюм, гримның мөһимлеген труппага төшендергән рус режиссеры белән нәтиҗәле хезмәттәшлек үрнәге булып тора; А.С. Загорский постановкасы труппа репертуарының

алдагы үсешенә дә йогынты ясый; тәрҗемә пьесаларның сәхнә өчен яраксызлыгына, рус һәм чит ил классикасы әсәрләре буенча куелган спектакльләрнең татар тамашачысы өчен ят булуына кагылышлы хорафатлар юкка чыгарыла [Арсланов, 1992, с. 56–57].

Соңрак татар театры берничә тапкыр Ф. Шиллер драматургиясенә мөрәҗәгать итә. Революция һәм Гражданнар сугышы елларында аның драмалары стационар мәйданчыкларда да, фронт театрлары сәхнәләрендә дә куела. Ул чорда сәхнәдә иң күп уйналган әсәрләрнең берсе – революция идеяләрен чагылдырган «Юлбасар» («Разбойники») спектакле. Шиллерның икенче пьесасы – «Мәкер һәм мәхәббәт»е татар аудиториясенә социаль һәм шәхси ирек идеяләрен үткәрүе белән якын булды.

Бу елларда татар театрының Шиллер драматургиясе буенча куелган иң зур спектакльләре – «Юлбасар» (1918) һәм «Мәкер һәм мәхәббәт» (1920), аларны Татар драма артистлары труппасында романтик режиссёр Мөхтәр Мутин куйган.

1926/1927 еллар сезонында режиссёр Риза Ишморатов янә татар театры өчен традицион стильдә “Юлбасар”ны куя» [Арсланов, 2004, с. 38].

XX гасырның 30 нчы еллары башында татар дәүләт академия театрына режиссёр Сәет Булатов килә. Яшь сәнгатькяргә рус һәм чит ил классикасы аеруча якын була. Татар режиссурасының 20 нче еллар башында Мутин иҗатында көчле чагылыш тапкан романтик традицияләре аның эшчәнлегендә яңадан торгызыла [2]. 1932 елда С. Булатов «Мәкер һәм мәхәббәт»не, ә 1934 елда «Юлбасар»ны куя.

1950 елда янә мещанлык белән сугарылган «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясе театр репертуарына кертелә. Шуннан соң шактый озакка сузылган «тынлык» күзәтелә, һәм Шиллер ярты гасырдан соң гына татар тамашачысына кабат әйләнеп кайта – 1999 елда Әлмәт драма театрында режиссёр Фаил Ибраһимов атаклы трагедияне үз интерпретациясендә сәхнәгә куя (сценографы Б. Ибраһимов).

XX гасыр классик немец драматургиясе республикабызның татар театрларында өч исем – Фридрих Вольф, Бертольт Брехт, Хайнер Мюллер аша тәкъдим ителә.

1935/1936 еллар сезонында, бөтен ил буенча барган антифашистик кампания кысаларында, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Ф. Вольфның күренекле «Профессор Мамлок» (1933) пьесасы буенча спектакль эшләнә. Ул 1941 елда, фашистлар Германиясенең СССРга һөҗүм итүенә җавап рәвешендә, яңадан торгызыла.

Татарстан Республикасы театрларының немец драматургиясенә мөрәҗәгать итүе турында сөйләгәндә, Бертольт Брехт пьесалары буенча куелган спектакльләр аерым бер әһәмияткә ия. 2001 елда К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры «Кураж ана һәм аның балалары» («Мамаша Кураж и её дети»; режиссёры Рәшит Заһидуллин) пьесасын сәхнәләштерде. Бу – төрле сәнгати традицияләр синтезына уңышлы мисал. Әлмәт татар драма театры да Брехт

драматургиясенә ике тапкыр мөрәҗәгать итте. 2013 елда режиссёр Искәндәр Сакаев (Санкт-Петербург) театр сәхнәсендә Брехтның «Туй» («Мещанская свадьба») комедиясен, ә 2015 елда аның атаклы «Бистә фәрештәсе» («Добрый человек из Сычуани») пьесасын куйды.

Әлмәтлеләрнең Эдуард Шахов куйган «Медея: Материал» спектакле дә (2017) зур вакыйга булды. Ул Еврипид трагедиясе белән XX гасырның күренекле драматургы Хайнер Мюллер текстының компиляциясеннән гыйбарәт.

Республиканың татар театрларында немец язучыларының проза әсәрләре буенча да аерым спектакльләр эшләнде. Әйтик, 2014 елда Казанда Тинчурин театрында режиссёр Резеда Гарипова Э.М. Ремаркның «Возлюби ближнего своего» әсәре буенча «Без барыбыз да кешеләр» спектаклен куйды (Резеда Гарипова инсценировкасы, Шамил Фәрхетдинов тәрҗемәсе). 2019 елда С. Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театрында Э.Т. Гофманның «Щелкунчик» әкияте буенча Санкт-Петербург режиссеры Евгения Богинская һәм хореограф Нурбәк Батулла (Евгения Богинская инсценировкасы, Рабит Батулла тәрҗемәсе) куйган пластик спектакльнең премьерасы булды.

Күрүебезчә, эстетик традицияләр төрле булуга карамастан, татар театрлары немец әдәбиятына даими рәвештә мөрәҗәгать итәләр. Бу яктан Әлмәт татар драма театры лидерлыкны кулдан ычкындырмый. Анда соңгы елларда классик немец драматургиясе буенча дүрт спектакль куелды.

«Медея: Материал» (2017) спектакле – театрның немец драматургиясе белән бәйле соңгы эше. Бу постановкалар киң яңгыраш алды һәм театрның эстетик эзләнүләрендә, төрле сәнгать системаларын үзләштерүдә, башкаручыларның актёрлык осталыгын камилләштерүдә мөһим этап булып тора. Соңгы өч пьесаны театр директоры Фәридә Исмәгыйлева тәрҗемә иткән.

Брехтның «Туй» пьесасы – мещаннар тормышына үткен сатира. Тәртипле туй тантанасы акрынлап йорт җиһазлары һәм савыт-саба ватып күңел ачу белән алмашына, ә кунакларның һәм хуҗаларның яшертен һәм басынкы кимчелек-бозыклыклары оятсыз рәвештә өскә бәреп чыга. Режиссёр Искәндәр Сакаев «мещан» сүзен спектакльнең исеменнән алуга карамастан, биредә нәкъ менә шушы категория өстенлек итә. Мещан психологиясе, филистерлыкның куркыныч асылы – Гофманнан башлап Томас Маннга, Генрих Маннан алып Брехтка кадәр немец әдәбиятының әһәмиятле темасы. Бар нәрсәдә камиллеккә омтылган боек герман даһие классик философияне, бөек әдәбиятны гына түгел, ә «үрнәк» фашизмны һәм классик мещанлыкны да тудыра. Ул Германиядә нацизм идеологиясен тарату өчен «уңдырышлы туфрак» булып, немец тарихында үзенең хәлиткеч ролен уйнады. Әмма, билгеле булганча, мещанлык – милләттән өстә торучы категория, шуңа күрә Искәндәр Сакаев спектакле, беренче чиратта, безнең бүгенге чынбарлыкның гротеск көзгесе буларак кабул ителә. Бу образ спектакльнең якты сәнгати формасы, аның ассызыкланган

театральлеге аша тормышка ашырыла. Әлмәтлеләр «Туе»ның нигезендә – кыю һәм үзенчәлекле пластик, сценографик һәм музыкаль чишелеш. Режиссёр, Всеволод Мейерхольдка мөрәҗәгать итеп, аның эмоциональ кичерешләргә нисбәтән физик реакцияләрнең беренчел булуына нигезләнгән биомеханика алымын куллана. Бу – билгеле булганча, актёрны психологик рефлекслар аша әзерләү системасы, тәннең механик яшәеше, хәрәкәтләрнең төгәллеге, биредә тышкы пластик рәсем образның мәгънәви доминантасы булып әверелә. Актёрлар механик курчаклар кебек хәрәкәт итәләр, синхрон рәвештә һәм ипле генә бер үк хәрәкәтләрне башкаралар, бу исә үзенчәлеген, индивидуальлеген югалткан масса образын тудыра. Бер үк вакытта монда аерым персонажларга үзенчәлекләр һәм характерлы штрихлар да өстәлә. 2013 елның 4 июнендә «Нәүрүз» фестивалендә спектакль турында фикер алышуда катнашкан тәнкыйтьчеләр бертавыштан актёрлар ансамбленең бердәмлеген, башкаручыларның төгәл һәм нәзакәтле итеп уйнавын, материальлек өстенлек итүне, пластиканың тирән мәгънәгә ия булуын билгеләп үттеләр. Сценография авторы, рәссам Дмитрий Шилченконың да эше югары бәяләнде. Танылган театр тәнкыйтьчесе Павел Руднев әлеге спектакльнең театр үсеше өчен аеруча әһәмиятле булуына игътибар итте [Стенограмма, с. 1].

Әлмәт театрында Искәндәр Сакаев Брехт әсәре буенча куйган «Бистә фәрештәсе» спектакле дә актив сәнгати формасы белән аерылып тора. Фәрештә эзләп табу өчен җиргә төшкән аллалар фахишә Шен Тены шундый зат итеп таныйлар. Ул Сычуанида ярата белүче бердәнбер тере кеше була. Изге гамәлләр кылу өчен явыз Шуй Тага әйләнергә мәҗбүр булган Шен Те (Наилә Нәҗипова) тарихы Әлмәт сәхнәсендә яңача гәүдәләндерелә. Павел Руднев язганча, «чем чаще строгий мужчина довлеет над хрупкой блаженной женщиной, тем все громче и громче в спектакле звучит тема бесконечного одиночества человека во вселенной, которому невозможно осуществить миссию богов» [Руднев]. Шул ук вакытта тәнкыйтьче театрның гражданлык, социаль позицияләрне бөтенләй читләтеп үтүен, мәхәббәт турында сөйләшүне игътибар үзәгенә алуын билгеләп үтә.

Җирдә фәрештәдәй булуның авырлыгы һәм хәтта аллаларның да нәрсәнедер үзгәртергә сәләтсез булуы турындагы мәсәл сәхнәдә утыручы тамашачы алдында уйнала. Аның алдында, И. Илалова фикеренчә, кул сузымында гына «предстаёт злой, экспрессивный, карикатурный мир кричащих людей, в бешеном ритме дерущихся за своё место под солнцем, в данной ситуации за чашку риса и уголок для ночёвки» [Илалова, с. 155]. «Хәерче театр» аскетизмы һәм спектакльдәге вакыйгаларга баш-аягы белән кереп китү тамашачыга бөтен игътибарын актерлар уенына юнәлтергә мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта театрның «хәерчелеге» алдан уйланган һәм купшы: крафт кәгазеннән һәм тупас киндердән эшләнгән декорацияләр һәм костюмнар хикмәтле һәм күп мәгънәле, үзләренең «ясалмалылыгы» белән алар Брехт рухында читләшү тудыра (рәссам Валерий Яшкулов, костюмнар

буенча рәссам Динә Тарасенко, СПб.). Бу – постановкада форманың соң дәрәҗәдә эчтәлекле булып китүенә менә дигән мисал. Актёрлар уенында да кайбер читкә тайпылулар бар. И. Илалова болай дип билгеләп үтә: «При этом самое удивительное заключается в том, что Шен Те, сыгранная в рациональной суховатой манере, трогает сердце зрителя, заставляет его сопереживать, что, казалось бы, должно противоречить теории эпического театра Брехта» [Илалова, с. 156]. Моннан автор ике төрле театр мәктәбенең янәшә уңышлы эшли алуы турында нәтиҗә чыгара. Бу турыда Р.Р. Солтанованың да фикере кызыклы: «…постановки брехтовских пьес на татарской сцене не отказываются от традиций психологического театра, рождая очень любопытный и не предполагаемый самим Брехтом сплав двух противоположных линий мировой драматургии» [Султанова, с. 187].

Театр тәнкыйтьчесе Елена Кожевникова, В.С. Золотухин исемендәге II Бөтенроссия яшьләр театр фестивале (2016) ( анда Әлмәт театры да катнаша) эксперты, «Бистә фәрештәсе» спектаклен түбәндәгечә характерлый: «точный, лаконичный, вычищенный, если можно сказать, аскетичный, полностью сконцентрированный на той интенции, которую посылает зрителю Брехт» [цит. по Катренко, с. 23]. Ә спектакль белән В.С. Золотухин фестивалендә Барнаулда танышкан Станислав Хазиев башка чынбарлык һәм бер үк вакытта гаҗәеп заманчалык хисен ассызыклый, аның без һәм безнең заман хакында булуын билгели [Хазиев, с. 42]. Шулай итеп, театр режиссёр Искәндәр Сакаев куйган бурычны уңышлы чишә – тамашачыны географик, вакыт һәм менталь чикләр аша уздырып, аңарда тану тойгысы уята.

Хәзерге немец драматургиясе белән эшләү тәҗрибәсе турында сөйләгәндә, Әлмәт театрының Хайнер Мюллер пьесасы буенча куелган «Медея: Материал» спектакле бик кызыклы тәҗрибә булып тора. Хайнер Мюллер – Брехттан соң иң күренекле немец драматургы, Европа постдрама театрының иң зур вәкилләреннән берсе. Аның драматургиясенең үзенчәлеге сәяси рефлексияне һәм авангардистик сәнгать формасын берләштерүдән гыйбарәт. Мюллер Брехтның гыйбрәтле пьесаларында үскән, әмма вакытлар узу белән бөек остазының дәресләреннән баш тарткан. 70 нче елларда Мюллерның үз стиле формалаша башлый: ул үзеннән өземтәләр китерергә ярата, текст һәм автор, текст һәм персонаж, вазгыять һәм образ арасында бәйләнеш югала. Мюллерның бөтен иҗатын сугарган темаларның берсе – көчләү. Бу – шул исәптән ир-ат һәм хатын-кыз мөнәсәбәтләренә дә кагыла. Әлеге тема драматург тарафыннан, беренче чиратта, «Гамлет-машина» (1977), «Квартет» (1980/81), «Медея: Материал» (1982) пьесаларында ачыла. «Медея: Материал» – «Разрушенный берег. Медея-Материал. Ландшафт с аргонавтами» драматик триптихының бер өлешен тәшкил итә. Сөт анасы һәм Язонның берничә репликасыннан тыш, бу – Медея монологы – кырыс, радикаль, экспрессив текст. Мәхәббәтен нәфрәт томалаган Медея балаларын үтерү юлы белән үзе тудырган дөньяны «кире алырга», булган тарихны «юкка

чыгарырга» омтыла. Шул рәвешле, дошмани вакыйгалар агышын туктатып, ул үткәннәр белән арасын тәмам өзүе турында белдерә. Мюллер аңлавынча, тарих – үз чираты белән барган көчләү актлары, ир-атлар тарафыннан булдырылган рәхимсез дөнья төзелеше нәтиҗәсе. Хатын-кыз исә – корбан да, шул ук вакытта тарихның ялгыш барышына чик куярга сәләтле көч тә.

Әлмәт театры спектаклендә мәңгелек мәхәббәт, хыянәт һәм үч алу темасыннан тыш бу фикер дә аермачык яңгырый. Режиссёр Эдуард Шахов версиясе Мюллер һәм Еврипид компиляциясеннән гыйбарәт. Медея (Мәдинә Гайнуллина) Мюллер текстын гына укый. «Медея: Материал» турында сөйләшкәндә, беренче эш итеп, Анатолий Васильевның 2001 елгы легендар спектакле һәм француз актрисасы Валери Древильның искә алынуы бик тә табигый. Васильев театрын еш кына «вербаль», «ритуаль» дип атыйлар. Ул үзенең спектакльләрендә бөтен игътибарны сүзгә туплый. Сүз – аның системасында гамәл-хәрәкәт өстеннән хакимлек итә. Тавыш, интонация, тавыш биеклеге дә зур әһәмияткә ия. Бу үзенчәлекләр барысы да Валери Древиль уенында тулысынча чагылыш таба. Сүзнең материальлеге мәгънәсеннән дә мөһимрәк булып чыга. Проекция фонында утырган актриса Медея (Мәдинә Гайнуллина) монологын да үтә көчле экспрессия белән укый, әйтерсең, ачынып кычкырып, сүзләрне түкерә, аларны яңадан «тудыра» дияргә мөмкин. Шул ук вакытта фраза ваклана, синтаксик һәм интонацион төзелеш бозыла. Спектакльләр мизансцена ягыннан да охшаш: йөрәге яраланудан һәм нәфрәтеннән шашкан Медея сәхнә уртасында утыра һәм үзенең өзек-өзек, куркыныч монологын сөйли. Әлмәтлеләр куйган спектакльнең үзенчәлеге шунда: режиссер спектакльгә Еврипид текстын – Сөт анасы һәм Язон репликаларын һәм хор партиясен кабатлап сөйләүче хорны кертә. Шуның белән бергә, әгәр Еврипидта комментатор, Медеяның оппоненты, халык авазы ролендә Коринф кызлары хоры чыгыш ясаса, спектакльдә хор сигез ир-аттан тора, бу исә ирләр һәм хатын-кызлар оппозициясен көчәйтә һәм визуальләштерә. Контраст көчәйгәннән-көчәя барып, Медеяның статик сыны фонында ир-атларның бертуктаусыз хәрәкәттә булуы да ачык күренә. Алар тарихны да, шул ук вакытта аңа шәрехне дә вербаль һәм пластик яктан тәкъдим итә. Биредә пластика буенча режиссёр Алинә Мостаеваның эше мактауга лаек. Пластиканың төрле төрләрен (шул исәптән contemporary dance, әрмән халык биюе элементлары, япон биюе бута һ.б.) куллану ир-атның төрле халәтен чагылдырырга тиеш.

Шулай итеп, спектакльдә экспрессия тудырыла һәм тамашачыга җиткерелә: бер яктан, Медея һәм хор тарафыннан махсус әйттерелгән үзенчәлекле текст аша; икенче яктан, бию, хәрәкәт, киеренкелек, хор актёрларының материальлеге, энергетикасы аркылы. Бу уңайдан Лиотарның «энергетика театры» (драмадан читтә торган театр) теориясе хәтергә килә. Лиотар фикеренчә, бу мәгънә театры түгел, бәлки «көч, интенсивлык, чынлыктагы аффектлар» театры булырга тиеш» [цит. по

Леман, с. 61]. Асылда, монда сүз постдрама театры моделе турында бара. Исегезгә төшерәбез, постдрама театры теориясен уйлап табучы немец галиме Х.-Т. Леман фикеренчә, театр өчен әдәби нигез – мөмкин булган тәрәкләрнең берсе генә ул, һәм театрны спектакль, тамаша дип карарга кирәк [Леман, с. 20]. Леман тән, пластиканы үзәккә куюның мөһимлеген ассызыклый. Ә бу Европа традициясенә түгел, ә бәлки япон театрына барып тоташа. Ул билгеләп үткәнчә, «…постдраматический театр предлагает себя как место встречи различных искусств» [там же, с. 50]. Әлмәтлеләрнең Хайнер Мюллер һәм Еврипид пьесаларын (contemporary dance һәм XVII гасыр композиторы Генри Перселл музыкасы белән) берләштергән спектакле сәнгатьләрнең очрашу урынына әверелә.

Шулай итеп, Әлмәт драма театрының сәнгати эзләнүләре заманча Европа театрының алдынгы тенденцияләренә тәңгәл килә.

Чит ил, шул исәптән немец драматургиясе татар театры репертуарында күптән үз урынын алды. Эстетик аерымлыклар булу сәбәпле, бәйләнешләр гел шома гына бармаса да, башка сәнгать традицияләрен кертеп җибәрү һәрвакыт уңышка илтә: ул кызыклы сәнгати нәтиҗәләргә китерә, татар театрының мөмкинлекләрен киңәйтә һәм аны Европа контекстына алып керә.

**Әдәбият**

*Арсланов М. Г.* Татарское режиссёрское искусство (1906–1941). Казань: Татар. кн. изд-во. 1992. 336 с. с илл.

*Арсланов Г.* Режиссёр Ширъязран Сарымсаков: монография. Казань: Татар. кн. изд-во. 2004. 222 с.

*Илялова И.* Современное звучание мировой классики на татарской сцене // Tatarica. №1 (6) 2016. С. 137–162.

*Катренко Наталья.* Второй Золотухинский: от Москвы до самых до окраин // Вечерний Барнаул. 23 сентября 2016. № 141 (4443). С. 23.

*Леман Х.-Т.* Постдраматический театр. М: Издательская программа Фонда развития искусства драматического театра режиссера и педагога Анатолия Васильева. 2013. 311 с.

*Руднев П.* Рецензия на спектакль «Добрый человек из Сычуани». Пост в фейсбуке от 21 ноября 2016 г.

Стенограмма обсуждения спектакля «Мещанская свадьба» на фестивале «Науруз» 4 июня 2013 года. 2 с. (Архив Альметьевского театра).

*Султанова Р.Р.* Брехт на казанской сцене (проблемы сценографии) // Вестник Нижегородского университета им. Н.И. Добролюбова. 2009. № 6 (2). С. 182–187.

*Хазиев С.* Театральному празднику в Барнауле – быть! // Страстной бульвар, 10. 2016. № 3–193. С. 39–45.

***Шевченко Елена Николаевна,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 069

***З.З. Гыйлаҗев***

# ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ӘДӘБИ МИРАСЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУЗЕЙЛАРЫНДА

Данная статья посвящена вопросам истории музеефикации и презентации литературного наследия татарских писателей в музеях Республики Татарстан. В хронологическом порядке кратко рассматриваются основные музеи татарских писателей их история, особенности деятельности, отслеживается динамика их появления, что позволяет в целом получить достаточно точное представление о развитии сети рассматриваемых музеев. Выделяются периоды развития сети музеев, направление их деятельности и связи с литературой.

**Ключевые слова:** литература, литературные музеи, татарские писатели, музеефикация, музейная сеть.

This article is devoted to the history of museumification and presentation of the literary heritage of Tatar writers in the museums of the Republic of Tatarstan. The main museums of Tatar writers, their history, features of activity are briefly considered in chronological order. The dynamics of their appearance is tracked, which makes it possible to get a fairly accurate idea of the development of the reviewed museums. The periods of development of the museums, the direction of their activities and connection with literature are distinguished.

**Keywords:** literature, literary museums, Tatar writers, museumification, museum network.

Әдәбият – мәдәниятнең аерылгысыз бер өлеше, ул чынбарлыкның социаль һәм әхлакый якларын аңлатырга омтыла, кешенең дөньяга карашын формалаштыра, рухи дөньясын баета.

Милли әдәбиятны өйрәнүдә һәм популярлаштыруда аерым язучыларга яисә, гомумән, әдәбиятка багышланган музейлар әһәмиятле роль уйный. Аларның эшчәнлеге «классик мирасны да, хәзерге әдәби процессны да үзләштерүдә эстетик эталон тудыруга» [Бонами, с. 328] юнәлдерелгән.

Әдәби музейлар – Россия Федерациясенең музейлар челтәре структурасында саллы махсус төркемнәрнең берсе. Бу әдәбиятның иҗтимагый тормышта аерым бер урын тотуы белән аңлатыла. Россиядә әдәби музейларның барлыкка килүе А.С. Пушкинның якты истәлегене мәңгеләштерү белән бәйле. Беренче музейларның бурычы «язучылар яки тарихи-әдәби барыш турында гомуми материаллар җыю, саклау, аларны күрсәтү һәм пропагандалау» [Минц, с. 11] була. Бу мәсьәләне яктырткан махсус хезмәтләр, аерым мәкаләләр язылуга карамастан [Все музеи Казани, 2003; Гаврилова, 2019; Гилазев, 2020; Руденко, 2018; Синицына, 2002; Суслов, 2021], Татарстанның әдәби музейлар тарихы проблематикасы әле дә тулысынча өйрәнелмәгән һәм махсус тикшерү-өйрәнүне таләп итә. Аерым язучыларга

багышланган музейлар хәзерге Татарстан территориясендә республиканың «иң эре музей үзәге…» [Руденко, с. 36] саналган Казанда эшли башлый. Шуларның берсе 1940 елның 12 мартында ачыла, ул танылган рус язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе А.М. Горькийга (Пешков) багышлана (хәзер «А.М. Горький һәм Ф.И. Шаляпин музее» – Татарстан Республикасының Милли музее филиалы, биредә һәм алга таба музейларның хәзерге атамасы кулланыла). Музей М. Беляев йортында урнашкан (бинасы XIX гасырның икенче яртысында төзелә). Биредә язучы 1886–1887 елларда А.С. Деренковның икмәк пешерү йортында ипи пешерүче ярдәмчесе булып эшли. Сүз уңаеннан шуны да искәртеп үтү кирәктер: А.М. Горький музее җитәкчелеге 1940 еллар ахырында Казаннан читтәрәк тә әдәби музей ачу тәкъдиме белән чыга. 1949 елда музей директоры М.Н. Елизарова һәм А.М. Горькийның дусты А.С. Деренков, Кама Тамагы районының Красновидово авылына барып, М.А. Ромасьның (Ромасев) бакалея кибете булган урынны билгелиләр (хәзер шул бинада музей урнашкан). 1888 елның июнь–сентябрь айларында А.М. Горький М.А. Ромасьта кунакта була. Гомеренең әлеге дәверен әдип соңрак «Мои университеты» повестенда һәм башка әсәрләрендә искә ала. 1951 елда китапханә каршында язучыга багышланган күргәзмә эшли башлый. Берничә елдан ул – мәктәп, соңрак клуб бинасына күчерелә һәм бераздан аерым музей дәрәҗәсенә үсеп җитә.

Татар әдәбиятына багышланган музейлар ачу эше 1944 елда җанланып китә (РСФСР Халык комиссарлары советының 1944 елның 2 июнендәге № 1222-р карары белән). Беренчесе 1950 елның 10 февралендә ТАССР Дәүләт музееның әдәби филиалы буларак Казанда ачыла («Татар әдәбияты тарихы музее һәм Шәриф Камал мемориаль фатиры» – Татарстан Республикасының Милли музее филиалы). Баштарак, 1928–1942 елларда, ул Ш. Камал яшәгән фатирда урнаша. ТАССР Халык комиссарлары советының 1944 ел 26 август № 24 карары белән янәшәдәге 5–6 фатирны музейга тапшыру әмер ителгән булса да, фәкать 1980 елда гына йорт тулысынча музей карамагына тапшырыла, хәзерге көндә бу бинада (XIX гасыр ахырында төзелгән) музей гына урнашкан. Әлеге музейның эшчәнлеге эзлекле генә бармый, шактый гына еллар ул ябылып та тора (1965–1980 һәм 2005–2019 елларда төзекләндерү эшләре алып барыла, 2008–2016 елларда мемориаль экспозиция Г. Тукайның Казандагы әдәби музеенда күрсәтелә).

Күренекле татар язучысы М. Җәлилгә багышланган, бүгенге көндә дә эшчәнлеген дәвам итүче музей Минзәлә педагогика көллияте хезмәткәрләре (И.Б. Уткин җитәкчелегендә) тырышлыгы белән 1970 елның 3 мартында көллият бинасында ачыла. Биредә танылган шагыйрь 1941 елның 7 ноябреннән 1942 елның 1 гыйнварына кадәр политработниклар курсларында белем ала. Татар әдәбиятын игътибар үзәгенә куючы музейлар челтәре киңәйгәннән-киңәя барып, 1990 елга кадәр 8 музей ачыла, аларның өчесе – М. Җәлилгә (Минзәлә шәһәре, 1970 ел; Балтач районының Карадуган авылы, 1976 ел; Казан,

1981 ел), өчесе – Г. Тукайга (Арча районының Яңа Кырлай авылы, 1971 ел; Арча районының Кушлавыч авылы, 1976 ел; Казан, 1986 ел) багышлана, шулай ук Ш. Камалга һәм С. Хәкимгә (Әтнә районының Күлле Киме авылы, 1987 ел) багышланган музейлар бар. Бу уңайдан Е.Н. Мастеница сүзләре игътибарга лаек: «1960–1980 еллар – Россиядә әдәби музейлар көчле үсеш алган вакыт һәм бу аларның гадәттән тыш популярлыкка ирешүләре белән генә аңлатылып калмый, ә әдәби мирасны шәрехләү һәм тәкъдим итүнең төрле формаларына ия төрләре барлыкка килү белән дә билгеләнә» [Мастеница, с. 110].

1970–1980 елларда татар язучылары музейлары системасы формалаша һәм 1990 елларда оешып бетә дияргә дә була. Әлеге чорда 9 яңа музей сафка баса: Хәсән Туфан музей-йорты – Аксубай туган якны өйрәнү музее филиалы (Аксубай районының Иске Кармәт авылы, 1990 ел); «Мирхәйдәр Фәйзи музей-утары» – Халыклар дуслыгы туган якны өйрәнү музее (Балтач районының Шода авылы, 1991 ел); «Газиз Кашапов музее» – Аксубай төбәкне өйрәнү музее (Аксубай районының Яңа Үзи авылы, 1992 ел); «Шәйхи Маннур мемориаль музей-китапханәсе» – Мамадыш туган якны өйрәнү музее филиалы (Мамадыш районының Тулбай авылы, 1995 ел); Арча әдәбият һәм сәнгать музее – «Казан арты» тарихи-этнографик музее бүлеге (1995 ел); «Риза Фәхреддин мемориаль музее» (Әлмәт районының Кичүчат авылы, 1995 ел); «Каюм Насыйри исемендәге архитектура-этнография комплексы» – Яшел Үзән тарихи-мәдәни мирасы музее филиалы (Яшел Үзән районының Олы Ачасыр авылы, 1997 ел); «Фатих Кәрими мемориаль музее» – Әлмәт шәһәре төбәкне өйрәнү музее филиалы (Әлмәт районының Миңлебай авылы, 1998 ел); «Гаяз Исхакый тарихи-мемориаль һәм этнографик комплексы» – Чистай дәүләт тарихи-архитектура һәм әдәби музей-тыюлыгы бүлеге (Чистай районының Яуширмә авылы, 1999 ел).

Шулай ук музей экспозициясенең зур өлеше татар шагыйре, прозаигы һәм драматургы С. Батталга багышланган һәм язучының исемен йөрткән, Татарстанда бердәнбер төбәк тарихы музеен искәртеп үтү дә урынлы булыр: «Салих Баттал исемендәге Зур Тигәнәле төбәк тарихы музее» – В.И. Абрамов исемендәге Туган як музее филиалы. Ул 1998 елда авыл мәктәбендә эшли башлый, 2003 елда аерым бинага күчерелә. Музейга экспонатлар туплау һәм аны оештыруда мәктәпнең тарих һәм география укытучысы Д.Н. Хафизова күп тырышлык куя.

Республикада әдәби музейлар үсешенең төп сәбәпләреннән берсе XX гасырның 1980 елларында илдә иҗтимагый-сәяси процесслар башлану һәм алга таба Татарстан Республикасының статусы үзгәрү белән бәйле. Болар барысы да милли мәдәниятнең тергезелүенә һәм милли үзаң үсешенә этәргеч булып тора. Ул чорда әдәби музейлар оештыру процессы әдәбият, фән һәм музей эше үсеше белән тыгыз бәйләнгән була.

Узган гасырның 1990 елларында актив рәвештә татар язучыларына багышланган яңадан-яңа музейлар булдыру процессы 2000 елларда

сүлпәнәя. Бу хәл илдәге иҗтимагый-сәяси вазгыятьнең торышы һәм ТР Мәдәният министрлыгы күздә тоткан өстенлекләрнең үсеш-үзгәреше белән бәйле. Ул чорда әдипләрнең тормышы һәм эшчәнлеге белән таныштыручы 4 әдәби музей: Мөхәммәт Мәһдиев музее – «Казан арты» тарих-этнография музее филиалы (Арча районының Гөберчәк авылы, 2000 ел), «Каюм Насыйри музее» – ТР Милли музее филиалы (Казан шәһәре, 2002 ел), «Фәнис Яруллин музее» (Баулы районының Кызылъяр авылы, 2010 ел), «Туфан Миңнуллин музее» – Кама Тамагы туган якны өйрәнү музее филиалы (Кама Тамагы районының шәһәр тибындагы Кама Тамагы бистәсе, 2012 ел) эшли башлый.

Югарыда каралган музейларның татар әдәбиятына багышланганы – «Арча әдәбият һәм сәнгать музее», калганнары – мономузейлар. Бүгенге көндә «Татар әдәбияты тарихы музее һәм Шәриф Камал мемориаль фатиры» шулай ук татар әдәбиятына багышланган музей буларак эшли, әмма ул 2019 елга кадәр мономузей була. Безнең игътибар үзәгендәге әдәби музейлар арасында аерым авторларга багышланган мәдәни оешмалар (мономузейлар) өстенлек ала. Анда теге яки бу авторның үзе исән чакта һәм аның вафатыннан соң басылган әсәрләре, кульязмалары, аның тормышы һәм иҗаты белән бәйле тарихи-әдәби материаллар тупланган. Язучының эш кабинеты иң изге урын санала, бер генә әдәби музей да әдипнең «язылып бетмәгән кульязмасы» саклангын язу өстәленнән башка була алмый. Музейлар, нигездә, әдәбият белеме белән түгел, ә әдәбият һәм мәдәният тарихы белән бәйле.

Татар язучыларына багышланган әдәби музейлар челтәре үсешен күзаллау өчен мәдәни сәясәткә мөрәҗәгать итү кирәктер. Россия галимнәре хәзерге мәдәни сәясәтне ике чорга бүлеп карый: 1) «1990 еллар – үзәкләштерелгән идарә итү сәясәтеннән арыну процесслары (аерым вәкаләтләрне һәм бурычларны, шул исәптән финанс йөкләмәләрен төбәкләргә тапшыру), җәмгыятьне идеологик кысалардан арындыру, яңа дәүләтнең хокукый нигезен булдыру белән характерлана; 2) 2001 елдан башлап – мәдәният һәм җәмгыять үсешенең үзара бәйлелегенә төшенү, мәдәниятне финанслауны көчәйтү» [Бодрова, Гусарова, Мешкова, с. 86–87] күзәтелә. Беренче чор татар язучыларына багышланган әдәби музейлар үсеше өчен нәтиҗәле дәвер булса, икенче чорда бу өлкәдә билгеле бер сүлпәнлек күзәтелә, бу яңа ачылган музейлар аз булуда күренә. Моңа иҗтимагый-сәяси вазгыятьнең үзгәреш кичерүе, шулай ук күпмедер дәрәҗәдә әдәби музейларның популярлыгы кимү дә сәбәпче була.

Бер караганда, музейларның булганнары да җитәрлек һәм алар күп кенә күренекле татар язучыларының иҗатын колачлый алган, дип канәгатьләнергә дә мөмкин, шуңа күрә яңаларын булдыру зарурлыгы юкка чыга. Шулай да әсәрләре XX гасырда нәшер ителә башлап, хәзер дә басылуын дәвам иткән Т. Миңнуллин, Ф. Яруллин кебек әдипләрдән кала, күпчелек музейлар узган гасырда иҗат иткән язучыларга багышлана. XIX гасыр К. Насыйри музее белән характер-

лана. Иҗади эшчәнлекләре XIX гасырда башланып киткән башка авторларны әдәбият тарихында XX гасыр башы язучылары буларак карау кабул ителгән. К. Насыйридан тыш бу чорда татар әдәбияты тарихына сизелерлек өлеш керткән һәм исемнәре мәңгеләштерелүгә лаек булган башка әдипләр дә бар: М. Акмулла, Г. Кандалый, Г. Утыз Имәни һ.б. Татар әдәбиятының тагын да элгәрерәк чоры музейларда бөтенләй яктыртылмый, югыйсә аның тарихы VI–XII гасырлар гомумтөрки истәлекләреннән башлана һәм анда исемнәре мәңгеләштерелүгә лаек иҗат әһелләре бихисап. Әдәбият тарихына караган музейларның экспозицияләре искәртеп үтелгән исемнәрнең санын бераз арттыра, әмма вазгыятьне үзгәртми, чөнки андый музейлар Татарстанда нибары ике генә. Бу музейлар гына татар әдәбиятының барышын чагылдырып бетерә алырмы икән? Юктыр, мөгаен. Һәрбер язучыга багышлап аерым музей ачу – мөмкин эш түгелдер, әлбәттә. Әмма булганнарының репрезентатив характерга ия булу-булмаулары хакында һәм әдәби мирасны музейлар формасында оештырып мәңгеләштерү буенча алып барылган эшчәнлеккә үзгәрешләр кертү мәсьәләсендә уйланырга җирлек бар.

**Әдәбият**

*Бодрова Е.В., Гусарова М.Н., Мешкова А.В.* Государственная политика РФ в области культуры и образования на рубеже XX–XXI вв. М., 2008. 202 с.

*Бонами З.А.* Литературный музей и общество // Музееведение. Музеи мира: Сборник научных трудов. М.: НИИ культуры, 1991. С. 327–335.

Все музеи Казани. Справочник-путеводитель. Казань: Заман, 2003. 256 с.

*Гаврилова М.Ф.* Роль казанского музея А.М. Горького в деле сохранения литературного наследия Татарстана // Вестник Кемеровского Государственного университета культуры и искусств. 2019. № 46. С. 152–158.

*Гилазев З.З.* Музеи русских писателей Республики Татарстан: штрихи к истории // Актуальные проблемы регионоведения и науковедения: сборник статей научной конференции (г. Казань, 27 мая 2020 г.). Казань, 2020. Вып. 9. С. 171–175.

*Мастеница Е.Н.* Литературные музеи России: генезис и эволюция // Вестник Санкт-Петербургского государственного университета культуры и искусств. 2017. № 2. С. 108–111.

*Минц Н.В.* О путеводителях по литературным и художественным музеям. М., 1960. 168 с.

*Руденко К.А.* Культурное наследие и его роль в современном обществе (на примере музеев Татарстана) // Вестник Казанского государственного университета культуры и искусств, 2018. № 3. С. 35–40.

*Синицына К.Р.* Полвека музеев Казани и Татарии. Очерки истории 1917–1967 годов. Казань: «Kazan-Казань», 2002. 280 с.

*Суслов* А.Ю. Формирование и развитие музейного пространства Республики Татарстан // Манускрипт. 2021. Т. 14. Вып. 3. С. 433–437.

***Гыйлаҗев Зөфәр Зәкәрия улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Татар энциклопедиясе*
*һәм төбәкне өйрәнү институты*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 394.3

***Д.И. Умәров***

# ДӨНЬЯ КАРТИНАСЫ КОНТЕКСТЫНДА ТАТАРЛАРНЫҢ ТРАДИЦИОН БИЮ КУЛЬТУРАСЫ

Семантический статус хореографического фольклора позволяет выбрать его в качестве объекта научного рассмотрения. В статье раскрывается проблема исследования танцевальной культуры. Рассматриваются истоки происхождения танца, эволюция обрядовых и традиционных народных танцев, их сакральные функции. Поднимается проблема исследования этнической танцевальной культуры, а также освещаются вопросы, связанные с методикой преподавания фольклорного танца.

**Ключевые слова:** Традиционная культура, танцевальная культура, этнохореология, фольклор, пляска и танец, культурная идентичность, национальная идентичность, кинетография, запись танца.

The semantic status of choreographic folklore allows you to choose it as an object of scientific consideration. The article reveals the problem of dance culture research. The origin of dance, the evolution of ritual and traditional folk dances, their sacred functions are considered. The problem of the study of ethnic dance culture is raised, as well as issues related to the methodology of teaching folk dance are highlighted.

**Key words:** Traditional culture, dance culture, ethnochoreology, folklore, dance, cultural identity, national identity, kinetography, record dance.

Бию мәдәният тарихының буеннан буена аның белән янәшә атлый, биюнең башлангычы архаик җәмгыятьләргә барып тоташа. Сәнгать төре буларак ул тулысынча XVII гасырда гына формалашкан булса да, бию культурасы кешелек бергәлеге кебек үк борынгы. Биюне һәм аның тарихын тикшерүчеләр биюнең барлыкка килүен мифологик дөнья һәм ритуаль-йола эшчәнлеге белән бәйләп өйрәнәләр. Аларның кайберләре биюне һөнәри контекста, үзенчәлекле иҗади эшчәнлек буларак, таррак кысада карый. Безнең күзлектән, бию милли һәм этник тәңгәллекнең иң мөһим факторларыннан берсе буларак карарга мөмкин, бигрәк тә сүз йола һәм традицион халык биюләренең тарихи эволюциясе турында барганда. А.С. Фомин «биюнең табигате турында белемнәр формалаштыру аны өйрәнүдә төп мәсьәләләрнең берсе булып тора», дип саный, бию культурасын тикшерү мәдәният тарихын тулаем өйрәнү контекстында алып барылырга тиеш, чөнки бию синкретик пространство-вакыт сәнгате буларак, мәдәният өчен мөһим мәгънәләрне гәүдәләндерә һәм символик мәгънәләрне саклый [Фомин, с. 26]. Бию культурасын без «микрокультура» дип саный алабыз, ул көндәлек культура турында да, традицион мәдәниятнең тылсымга ия өлеше турында да фикер йөртергә мөмкинлек бирә. И.А. Герасимова «по мудрым движениям... можно судить о проявленности

особых аспектов сознания, определяющих специфику когнитивной ситуации в ту или иную конкретно-историческую эпоху» дип яза [Герасимова, 1998, с. 40]. Без аның белән килешәбез. Бу очракта бию культура мәгънәләрен саклаучы мәдәният тексты буларак анализланырга мөмкин.

Хәзерге әдәбиятта без биюнең төрле дефинициялəрен очрата алабыз: тарын да, киңен дә. Д.Ш. ван Кэмпка ияреп, биюне формальләштерелгән, махсус кануннар, матурлык һәм грациялелек принциплары нигезендә башкарыла торган ритмик хәрәкәт дип билгели алабыз; ул музыка астында башкарыла һәм ритмик хәрәкәтләрдән тора; максаты – аралашу яки тарих сөйләү, ритуал, хисләрне яки мәгънәләрне җиткерү, ягъни биючеләрне мәдәни идентификацияләү өчен нигез булган мәдәни мәгънәне бирү, дип нәтиҗә ясыйбыз [Кэмп, с. 21].

Биюне өйрәнүгә караганда бию культурасын тикшерү комплекслы һәм киңрәк булырга мөмкин. Бию культурасы халык бию традициясе контекстында карала ала, ул тулаем алганда милли, халык традицияләре белән тыгыз бәйләнгән. Е. Самойленко фикеренчә, «танцевальную культуру можно определить, как систему, в общем виде представляющую собой способ бытования танца в повседневной культуре. В этом случае имеем следующую иерархию: культура – культура повседневности – танцевальная культура, где танцевальную культуру следует считать одним из элементов или, иначе, микрокультурой в границах повседневной культуры» [Самойленко, с. 149]. Әлеге карашка һәм биюнең мәкалә авторы тарафыннан ассызыкланган структурасына (аңа бию үзе һәм көндәлек бию керә) ияреп, без бию культурасын милли һәм этник тәңгәллекне формалаштыруга йогынты ясый торган мөһим элемент буларак анализлый алабыз.

Халык биюе аутентик фольклор шартларында гына яшәми, сәхнә мәйданы да аның яшәү тирәлегенә әверелеп бара. Без халык һәм халык-сәхнә биюен аерабыз. Әгәр беренчесе, тарихи контекстта мәдәни мәгънәләрне теркәсә һәм этнос тормышын чагылдырса, икенчесе, шушы мәгънәләргә таянып, этник тәңгәллек формаларын аңлы рәвештә тарата, ул мәдәни хәтер функциясен үти һәм дидактик аспектлы булуы бәхәссез. Халык-сәхнә биюе сәхнәгә профессиональ хореографлар тарафыннан куела, алар халыкның бию мәдәнияте тарихын йә үзләре өйрәнәләр, йә этнографик тикшеренүләргә таяналар. Шул рәвешле, халык-сәхнә биюендә халык традицион биюләренең төп элементлары саклана һәм яңадан торгызыла. Шуның белән бергә, безнең экспедицияләр һәм фольклор тикшеренүләре барышында шунысы ачыкланды: еш кына безнең информаторлар куллар торышындагы, фигуралар эзлеклелегендәге һ.б. мәгънәви төсмерләрне үзләре дә хәтерләмиләр яки бөтенләй белмиләр. Шул рәвешле, без бию язмаларын мәдәни-тарихи тикшеренүләр белән тулыландыру зарурлыгы алдында калабыз. Алар хәрәкәтләрнең башлангыч мәгънәләрен ачыкларга мөмкинлек бирә.

Бию культурасына багышланган әдәбиятта еш кына «танец» һәм «пляска» сүзләре синонимнар буларак кулланыла. Әмма бу бик үк дөрес түгел кебек. Рус телендә «танец» сүзе кулланылышка шактый соң керде һәм башта спонтан халык биюен түгел, ә сарай биюен, куртуаз, дөньяви биюне белдерде. О.М. Герасимов фикеренчә, «пляска – это нечто спонтанное, импровизационное, а танец – это подготовленное по особым правилам, изученное и закрепленное, то есть канонизированное действо» [Герасимов, 2001, с. 23]. О.М. Герасимовка ияреп, без билгеле бер кануннарны файдаланган уен тамашасы буларак спонтан халык биюен (пляска) һәм куелган, өйрәнелгән биюне (танец) аерабыз.

Тикшеренүчеләрнең түбәндәге фикере дә кызыклы: «танец – один из видов невербального общения, наделенного всеми функциями общения: функцией формирования и развития отношений, функцией познания людьми друг друга, функцией влияния и взаимовлияния, функцией организации межличностного взаимодействия. Выполнение посредством танца функций общения становится возможным благодаря тому, что он является целым комплексом невербальных знаков и сигналов, которые несут информацию о психологических особенностях личности и группы» [Монахова, 2014, с. 187]. Халык-сәхнә биюен шулай ук коммуникация терминнарында тасвирлап була. Е.Г. Монахова билгеләп үткәнчә, әгәр профессиональ булмаган бию өчен «чиста» аралашу функциясе хас булса, профессиональ биюдә тамашачы белән аралашу зур әһәмияткә ия, профессиональ сәхнә биюе халыкка адресланган трансляцияләнүче хәбәргә әверелә [Монахова, 2014, с. 187].

Әмма сүз халык-сәхнә биюенең хәбәр итүе турында гына түгел, аны эстетик кабул итү хакында да бара. «Сәнгатьне куллану», хәзерге заман социологлары теле белән әйткәндә, җәмгыятьнең эстетик ихтыяҗларын канәгатьләндерә [бу турыда кара: Белов, 2009, с. 48]. Бию-сәхнә сәнгате тамашачыда билгеле бер эмоциональ халәт тудырырга тиеш, бу эмоциональ мөнәсәбәт булдыруга караганда катлаулырак (мәсәлән, турыдан-туры бию хәрәкәтләрендә катнашучыларда). Шуңа күрә биюнең сәхнә драматургиясе, аны эстетик һәм сәнгати кабул итү законнары буенча төзү аеруча мөһим. Баштан ук халык биюе буларак синкретик характерга ия бию сәхнәдә дә синтетик сәнгать булып кала – кабул иткәндә аның һәр компоненты – музыкасы, хореографиясе, костюмнар, халык-сәхнә биюенең бер өлеше буларак пантомима – барысы да гаять мөһим. Ю.А. Кондратенко билгеләп үткәнчә, «танец как вид искусства, обладающий специфичным способом художественной рефлексии, в рамках которого посредством ритмо-пластически организованных в пространстве и во времени движений тела создается особый тип художественного языка» [Кондратенко, с. 7].

Бүгенге көндә биюләрне яздыруның гомум кабул ителгән бердәм системасы юк. Европа тикшеренүләрендә Рудольф фон Лабан

тәкъдим иткән метод кулланыла. Лабанның «Хореотика»сы өч үлчәмле язып алу системасыннан гыйбарәт һәм халык биюләрен генә түгел, балет спектакльләрен дә шактый зур төгәллек белән теркәргә мөмкинлек бирә. Техник күзлектән караганда, биш урыннан алып барылырга тиешле видеотөшерү иң ышанычлы ысул булып кала, ләкин бу очракта да күп кенә детальләрне күреп бетермәскә мөмкин (мәсәлән, озын күлмәкле кызның аяк хәрәкәтләрен). Россиядә украин хореографы В. Верховинец методикасы аеруча киң таралган, ул Э.А. Королева, Т.С. Ткаченко, Е.М. Марголис тарафыннан җентекләп эшләнгән һәм камилләштерелгән [кара: Верховинец, 1950]. Әмма, тәҗрибә күрсәткәнчә, бу система фольклор биюләренә караганда сәхнә биюләрен яздыру өчен күпкә кулайрак. Әлеге тикшеренүдә без С.С. Лисицианның язып алу системасына – кинетографиягә таянабыз [Лисициан, 1972]. Бу система А. Эйзенштейн тәкъдим иткән вертикаль символларга нигезләнгән, ул биюне яздырганда гәүдәнең горизонталь һәм вертикаль торышларын төшерергә мөмкинлек бирә.

Без нәкъ менә кинетография системасын биюләрне яздыруда иң нәтиҗәле ысул дип уйлыйбыз, чөнки ул башлангыч бию хәрәкәтләрен, халык бию культурасын теркәргә мөмкинлек бирә. Система авторы тәкъдим иткән сораштыру кәгазьләрендә мәгълүмат җитәрлек күләмдә һәм алар халыкның бию культурасы турындагы белемнәрне сизелерлек киңәйтергә мөмкинлек бирә. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татарлар үз хореографик культурасының бер өлешен югалта. Бу – мәдәният, икътисад һәм тормыш рәвешенең ассимиляциясе белән бәйләнгән. Шуңа күрә бию культурасын тикшерү шактый катлаулы – еш кына безгә теге яки бу биюнең чыганагын табу, аның модификацияләнү юлларын тулаем күзәтү авыр. Мәдәни багланышлар вакытында читтән кергән алынмалар да күп була, без бер үк бию хәрәкәтләре һәм мәгънәләре үзара охшаш гореф-гадәтләр белән очрашабыз, бу – татар халкы мәдәни тәңгәллегенең бердәм нигезле булуы турында сөйли. Шул ук вакытта без этнос эчендә аерым төркемнәрнең характерлы үзенчәлекләрен ачыклый һәм аерым субэтносларның этник үзенчәлеге ничек саклануын һәм төркем бердәйлеге барлыкка килүне күзәтә алабыз. Татарларның һәр этник төркеменә, гомуми хореографик культура белән беррәттән, үз фольклор биюләре булу да хас.

Тулаем фольклор биюләрен бүлгән кебек, татарларның фольклор биюләрен дә ике төргә аерып карарга мөмкин: йола биюләренә һәм йола биюләре булмаганнарга. Беренчесенә туй, календарь һәм рекрут биюләре керә; икенчесенә – уен биюләре, без аларны яшь төркемнәре буенча бүлә алабыз. Биюләрнең һәр төре, йола биюләре дә, йола биюе булмаганнары да, күмәк, ялгыз һәм парлы биюләр рәвешендә тәкъдим ителергә мөмкин.

Шулай итеп, без бию – бию культурасының төп система барлыкка китерүче элементы буларак, халык мәдәнияте кысаларында җитди үзгәрешләр кичергән дип раслый алабыз. Халык биюе акрынлап

үзенең беренчел тылсымлы функцияләрен, бергәлек формалаштыру, идентификацияләү һәм репрезентацияләү функцияләрен югалта. Сценографлар һәм этнохореологлар алдында башлангыч мәгънәләрне ачыклау, аларны, куелышта беренчел этник бию культурасы кодларының бер өлеше сыйфатында алга таба тапшыру өчен, расшифровкалау бурычы тора. Хореографлар халык биюләрен игътибар белән яздырып алалар, аларның мәгънәләренә төшенәләр, көндәлек биюне бию культурасының периферияссе буларак тикшерәләр. Хәзерге этнохореография тикшеренүләренең иң зур әһәмияте әнә шунда һәм аның төп кыенлыклары да шуның белән бәйләнгән.

Безнең очракта институтларда фольклор биюен кертергә кирәк. Югары белем бирү системасы зур кыенлыклар кичерә, фольклор биюен укыту методикасы юк. Студентларга фольклор биюен куйганда, аларның аяк очларын сузмыйча гына хәрәкәт итүләренә ирешү мөмкин түгел.

Фольклорчы хореографлар юк. Институтларда фольклор түгел, ә халык биюе укытыла. Түбәндәгеләрне укыту-өйрәтү зарур:

1) биюне – аралашу чарасы буларак;

2) татарларның субэтник төркемнәренең милли һәм географик характердагы үзенчәлекләрен;

3) татарларның теге яки бу субэтник төркеме урнашкан төбәктә казу эшләре алып бару, милли костюмны өйрәнү;

4) йола культурасын, барлык татар этник төркемнәре килеп чыгышының тылсымлы мәгънәсен, үсеш тарихын;

5) бию лексикасын, йола, тасвирлау методикасын. Кыр сораштыруы төзергә өйрәтү.

Татар фольклор биюе эзсез югалу чигенә якынлашты. Шул ук вакытта халык хореографиясенең бөтен катламнары да өйрәнелмәгән, иң аянычы шул: татар биюе, халык сәнгате күренеше буларак, үзенең табигый мохитеннән чыгып бара.

Хәзерге вакытта этник мәдәният контекстында хореографик фольклорны күзаллау һәм аңлауда яңа ракурсны билгеләргә вакыт җитте. Бу очракта вакытны ычкындырмау – мотивлаштыручы прецедентларның берсе. Бүген, ә илле яисә йөз елдан соң түгел, татар этнохореология мәктәбен ачарга кирәк. Татар фольклор биюен төшенү, тикшерү, өйрәнү һәм аякка бастыру юнәлешендә мөһим адымнар ясау, шул рәвешле татар халык биюе турында ялган күзаллауларны юкка чыгару зарур. Глобальләшү гасырында традицион мәдәният мөһим элемент булып тора һәм буыннарны үзара бәйләүче хезмәтен үти.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: хореографик фольклор әле исән, үзгәргән формада яши. Көнкүреш шартлары һәрдаим үзгәреп тора, бер фольклорны икенчесенә кысрыклап чыгара. Бу кисемдә Әстерхан татарларының фольклор биюләре теркәлгән, яздырып алынган һәм кинетографияләштерелгән. Тарихи вакыт аралыгында катламның үсеше ничек үзгәрер? Әгәр без хәзер, шушы минутта

татар фольклор биюенең типологик үзенчәлекләрен җентекләп тикшерүгә, классификацияләүгә һәм ачыклауга керешмибез икән, дөньякүләм әһәмияткә ия гаять зур мирасны югалтуыбыз бар, – халыкның бию лексикасын югалтуын телне җую белән чагыштырырлык.

## Әдәбият

*Белов В. А.* Особенности формирования эстетических эмоций средствами хореографического искусства // Вестник Челябинской государственной академии культуры и искусств. 2009. № 1 (17). С. 48.

*Верховинец В.* Українська хореографія: Теорія украінского народного танця. Киів, 1919.

*Герасимов О.М.* Очерки по народной хореографии мари. Йошкар-Ола, 2001. С. 23.

*Герасимова И.А.* Философское понимание танца // Вопросы философии. 1998. № 4. С. 50.

*Кондратенко Ю.А.* «Система художественного языка танца: специфика, структура и функционирование»: дис. … д-ра искусствоведения. Саранск, 2010. С. 7 // Научная библиотека диссертаций и авторефератов disserCat http://www.dissercat.com/content/sistema-khudozhestvennogo-yazyka-tantsa#ixzz508aZBHQu (дата обращения 03.12.2017).

*Королева Э.А.* Молдавский танец на русской сцене XIX века. Государственная публичная историческая библиотека (ГПИБ) 1968 г. С. 15–160.

*Кэмп Д.* Философские проблемы танцевальной критики. М., 1981.

*Лисициан С.С.* Старинные пляски и театральные представления армянского народа. Т. I. Ереван, 1958; Т. II. Ереван, 1972.

*Марголис Е.М.* О записи танца. М., 1950.

*Монахова Е.Г.* Социальная функция танца // Austrian Journal of Humanities and Social Sciences. 2014. № 9–10. С. 187.

*Самойленко Е.В.* Танцевальная культура: проблемы дефиниции, структура, ведущие функции // Наука и современность. 2011. № 12-1. С. 149.

*Ткаченко Т.С.* Народный танец. М.: Искусство, 1967. 656 с.

*Фомин А.С.* Танец в системе воспитания и образования. Т. I: Природа, теория и функция танца. Новосибирск, 2005. С. 26.

***Умәров Дәүләт Исмәгыйль улы,***
*культурология кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 398

*Л.М. Фәхриева,*
*Л.Х. Дәүләтшина*

# ТӨРЕК МИФОЛОГИЯСЕ ПЕРСОНАЖЛАРЫН КЛАССИФИКАЦИЯЛӘҮ МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА

В исследовательской работе представлен анализ отдельных классификаций мифологических персонажей турецкой мифологии. Источниками исследования являются работы таких авторов, как Дениз Каракурт, Фузули Баят и Джелал Бейдили. В данной работе применен метод сравнительного анализа как основной. Выполнен обзор работ, в которых предложены типологические признаки мифологических персонажей, на основе которых выстроена классификация персонажной системы турецкой мифологии. Актуальность темы исследования обусловлена отсутствием цельной классификации мифологических персонажей, представленных в мировоззрении турецкого народа, так как исследования в этой области имеют больше энциклопедический и онтологический характер.

**Ключевые слова:** тюркская мифология, турецкая мифология, мифологический персонаж, классификация, модель мира.

The research work gives an analysis of individual classifications of mythological characters of Turkish mythology. The sources of the study are the works of such authors as Deniz Karakurt, Fuzuli Bayat and Jalal Beidili. In this article the method of comparative analysis is used as the main one. A review of works has been carried out and typological features of mythological characters are proposed, on the basis of which the classification of the character system of Turkish mythology is built. The relevance of the topic is caused by the lack of an integral classification of mythological characters represented in the worldview of the Turkish people, since research in this area is more of an encyclopedic and ontological nature.

**Key words:** Turkic mythology, Turkish mythology, mythological character, classification, world model.

Мифология халык иҗатының иң борынгы катламын тәшкил итә. «Миф (сүзнең туры мәгънәсендә) – ул хикәяләү, чынбарлыкны фантастик рәвештә гәүдәләндергән «хикәяләр» җыелмасы, әмма бу сүз сәнгате жанры түгел, ә дөньяны билгеле бер рәвештә күзаллау. Еш кына ул хикәяләү формасын ала; дөньяны мифологик күзаллау башка төрле формаларда – йолага бәйләнешле хәрәкәт, җыр, бию һ.б. рәвешләрдә дә гәүдәләнә» [Мифы народов мира, 1980, с. 14].

Төрки халыклар мифологиясен өйрәнү юнәлешендә бүгенге көндә шактый күп эш эшләнгән [Абрамзон, 1990; Akman, Köktan, 2019; Кляшторный, 1977; Неклюдов, 1980; Стеблева, 1972; Урманчеев, 2008, 2009, 2011; Хисамитдинова, 2016; Халипаева, 1995 һ.б.]. Әмма төрек мифологиясенә бәйле мифологик персонажларның типологик билгеләрен күрсәтүгә багышланган аерым хезмәтләр юк. Кайбер авторлар үрнәк классификацияләр тәкъдим итәләр, кайбер эшләрдә пер-

сонажларны системалаштыру тенденциясе күзәтелә, әмма аларның төп максаты төрек мифологиясе персонажларының тулы классификациясен төзү түгел.

Төрек мифологиясен өйрәнгән хезмәтләр арасында мифологик персонажларны теге яисә бу принциплар буенча классификацияләүгә багышланганнарын күрсәтергә мөмкин. Алар арасында Дж. Бейдилиның «Төрки мифологиянең энциклопедик сүзлеге» [Beydili, 2005], Д. Каракуртның «Төрек мифологиясе энциклопедиясе» [Karakurt, 2011], Фузули Баятның «Төрки мифологик системасы» [Bayat, т. 1, 2007; т. 2, 2007] аерым урын алып тора. Аларда төрки мифологиядәге һәм шул исәптән төрек мифологиясендәге төп мифологик категорияләр турында мәгълүмат бирелә, мифологик персонажларның кайбер төркемнәренә җентекле анализ ясала.

Дж. Бейдилиның «Төрки мифологиянең энциклопедик сүзлеге»ндә төрки мифология элементлары тәфсилләп тасвирлана. Ул төрек галимнәре тарафыннан төзелгән мифологик эчтәлекле сүзлекләр арасында – беренчеләрдән. Әлеге сүзлекне төзегәндә автор рус һәм төрки тел белеме буенча шактый билгеле хезмәтләрдән файдалана. Бу сүзлекнең үзенчәлекләреннән берсе – ул мифологик элементларны, персонажларны бөтен төрлелегендә күрсәтә, ягъни хезмәттә төрле төрки халыкларның мифологиясендә чагылыш тапкан, очраган персонажларның вариантлары тәкъдим ителә (мәсәлән, «albastı» һәм «al karısı»). Әлеге хезмәт мифологик элементларны фәнни дәрәҗәдә чагыштыру өчен файдалы чыганак булып тора [Beydili, 2005, s. 10–12].

Безне, беренче чиратта, мифологик персонажларның фәнни классификациясе һәм аларның типологик билгеләрен аеру тәҗрибәсе кызыксындыра. Югарыда телгә алынган тикшеренүләрдә теге яки бу дәрәҗәдә мифологик персонажларны классификацияләү мәсьәләсе ачыклана. Сүзне Ф. Баятның «Төрки мифологик системасы»ның беренче томыннан башларга кирәк. Әлеге хезмәтендә галим мифологик персонажларны төркиләрнең мифологик моделе контекстында карый. Ф. Баят «Космосның өчле структурасы», «тернар бүленеше»нә нигезләнеп, мифологик дөнья моделенең өч каттан торуын билгели: югары – «gök» (күк), урта – «yer» (җир), түбән – «yeraltı» (җир асты). Өч дөньяда да – күк, җир, җир асты дөньясы – функцияләре төрле булган рухлар яши. Автор әлеге катламнарга караган персонажларны сурәтли, шул ук вакытта төрки халыкларда кулланылышта булган исемнәрнең төрле фонетик вариантларын билгеләп үтә. Күк дөньясына «Gök Tengri» (Күк Тәңресе), шулай ук «күк рухлары» керә. Якутлар аларны «tangara» дип атыйлар, саян-алтай төркиләре «kuday» һәм «tengri», чувашлар «tura» диләр. Кагыйдә буларак, алар – «кече» ходайлар, «Gök Tengri»нең ярдәмчеләре. Күк рухлары ешрак саян-алтай төркиләренең ышануларында күбрәк чагылыш тапкан «Ülgen»нең ярдәмчеләре яки уллары буларак күзаллана. Якутларда исә бу күк рухлары «Yüryüng Ayu Toyon»ның (барлыкка китерүче, тудыручы Ак хан) бертуганнары һәм ярдәмчеләре булып тора.

Ф. Баят урта дөньяның хуҗасы буларак җир рухы «Yer-Sub»ны (Җир-Су) күрсәтә. «Yer-Sub» белән бәйле ышанулар комплексына «таулар, урман, су, рухлар-сакчылар һәм ата-бабалар рухы» керә. «Сакчы рухлар» күзгә күренмиләр һәм саклаган объект янында яшиләр. Бу рухларны Якутияда «iççi», Алтайда – «ezi», Урта Азиядә, Азәрбайҗанда, Идел буенда һәм Анатолиядә – «iye, ie, yiye, ия», Монголиядә – «edzen», Бурятиядә – «ejin» яки «izen»дип атыйлар.

Түбән дөньяның төп каһарманы буларак Ф. Баят караган чыганакларда «Erklik» (Эрклик) яки «Erlik» (Эрлик) телгә алына. Монгол мифологиясендә дә җир асты дөньясының хуҗасы «Erlik Han» дип атала. Якутларда бу функцияне – «Arsan Duolay» (туфрак карынлы хан), кыргыз эпосында «Kök Döö» башкара. Саян-алтай төркиләре җир асты дөньясы ияләрен «körmesler» – «göze görünmezler» (күзгә күренми торганнар) дип атыйлар, алар кешегә килгән авыру һәм үлемнең сәбәбе буларак карала. Шунысы кызык: барлык рухлар да күзгә күренмиләр, әмма бары тик түбән дөнья ияләрен генә «körmesler» дип атыйлар. Шулай ук Ф. Баят алтайлыларның югары дөнья рухларын «ışıklı ülgenler» (якты, нурлы, үлгеннәр) дип атауларын да билгеләп үтә, чөнки, борынгы төркиләр ышануы буенча, алар «чиста, ак, якты», ә түбән дөнья рухлары, киресенчә, «кара» төс белән ассоциацияләшә – шулай итеп, дөнья моделенең «дихотомик» бүленеше барлыкка килә [Bayat, т. 1, 2007].

Югарыда атап үтелгән хезмәтләрдә мифологик персонажлар типологиясе дөнья моделен тасвирлау кысаларында карала, әмма Д. Каракуртның төрек мифологиясе сүзлеге турында болай дип әйтеп булмый. Хезмәтенең кереш өлешендә автор мифларга кыскача характеристика бирә һәм мифологик персонажларның классификациясен тәкъдим итә. Ул аларны дүрт төркемгә бүлеп өйрәнә.

Беренче төркем – «Рухи затлар» («Tinsel (Ruhâni) Varliklar»). Д. Каракурт әйтүенчә, бу төркемгә кергән персонажлар саклаучы рухлар булып торалар, ләкин аларны кеше «рухы» белән бутарга ярамый. Борынгы төрки ышанулар буенча, үсемлекләр, хайваннар һәм хәтта җансыз ияләрнең дә җаны бар. Рух хуҗасын сакласа да, аннан аерым күренеш буларак карала. Бу персонажлар классында автор дүрт төркемчәне билгели.

Беренче төркемчә – «Тәңреләр» («Tanrılar») – кеше кыяфәтендәге барлыкка китерү, иҗат итү һәм идарә итү функциясенә ия көчләр. Ир-ат тәңреләрнең ахырына «Han», хатын-кыз тәңреләренә – «Hanım» (монголларның «Hatan») сүзе өстәлә. Шулай ук «Toyun», «Ata» һәм «Hatun», «Ana», «Alaz Han (Alaz Toyun, Alaz Ata)», «Kübey Hanım (Kübey Hatun, Kübey Ana)» кебек элементлар өстәлә ала. Автор фикеренчә, борынгы төрки мифологик күзаллаулар системасында «Тәңре»не аңлау Көнбатыш системасыннан аерылып тора. Ул грек һәм рим мифологияләренә бәйле политеизм төшенчәсен борынгы төрки мифологик күзалаулар җыелмасын аңлатуга мөнәсәбәттә куллануны ялгыш дип саный. Д. Каракурт пантеонны билгеләүдә башка алым тәкъдим

итә. Аның фикеренчә, «югары тәңреләр» – саклаучы һәм яклаучы рухлар, аларның аермасы – башка рухлардан югары булу. Әгәр дә шаманизмда «фәрештә» төшенчәсе булса, аларны шулай дип атарга мөмкин булыр иде. «Tengri (Gök-Tanrı)» яки «Tura» – абсолют иҗатчыга ышануның абстракт концептуализациясе. «Tengri» үзенең уникальлеге белән төрки диннәрне монотеизмга якынайта, әмма бу ышанулар системасының катлаулы структурага ия булуын исәпкә алырга кирәк, анда башка илаһи затлар булуы да мөһим. Д. Каракурт фикеренчә, кешеләрнең төрле карашлары, шулай ук Көнбатыш тикшеренүчеләренең бу юнәлештәге эшләре, кайбер тикшеренүләрдә тәңречелекнең күпаллалык булып саналуына китергән [Каракурт, 2011, s. 7].

Д. Каракурт «Ata-Analar» (Ата-Аналар) дип аталган икенче төркемчәне аерып чыгара: «Börü Ana (Kurt Ana)» (Бүре Ана), «Zılant Ata (Yılan Ata)» (Елан Ата), «Barak Ata» (Эт Ата), «Yel Ata» (Җил Ата), «Su Ana» (Су Ана). Болар – табигатьтәге төрле җан ияләре һәм күренешләр белән идарә итә торган җан ияләре. Илаһи сыйфатларга ия булу сәбәпле, аларны да «тәңреләр» категориясенә кертергә мөмкин.

Өченче төркемчә – «İyeler» (Ияләр), хуҗасы янында яки аның эчендә булучы сакчы рухлар. Алар сакланган җан иясеннән аерыла ала, ләкин артык ерак китмиләр. Автор билгеләп үткәнчә, бу рухларның шәхес сыйфатлары еш кына ачылмый, чөнки алар күп. Күпчелек табигать күренешләренең сакчы рухы бар.

Дүртенче төркемчәгә галим «бүтән абстракт җан ияләрен» кертеп карый, аларның күбесен «İye» яки «Ruh» («рух») дип атый. Ләкин шул ук вакытта ул аларның үзенчәлекле сыйфатлары һәм функцияләре булуын да билгеләп үтә: «Çor (Cin)», «Abası (Şeytan)», «Körmös (Hayâlet)».

Автор икенче төркемне «Canlı Varliklar», «İnsani Varliklar» («тере затлар һәм кеше сыман затлар») исеме астында формалаштыра һәм андагы ике төркемчәне аера: «кешеләр» һәм «хайваннар / үсемлекләр». Автор «кешеләр»гә асылда абстракт булмаган мифик шәхесләрне кертә. Аларны еш кына лидерлар яки каһарман шәхесләр дип саныйлар; алар гадәти булмаган сәләткә һәм гадәттән тыш сыйфатларга ия, әмма үзләренең кешелек үзенчәлекләрен дә югалтмыйлар. Икенче төркемчәгә изге дип саналган һәм аерым әһәмияткә ия булган хайваннар яки үсемлекләр кертеп карала. Ул ата-бабалар белән бәйле хайваннар булырга мөмкин, еш кына аларга кеше сыйфатларын бирәләр. Изге хайваннар рәтенә «Bozkurt» (Күк бүре), «Alageyik» (Болан) һәм «Bürküt» (Бөркет) керә, изге үсемлекләр дип «Ulukayın» (Зур каен) һәм «Bayterek» (Байтирәк) агачларын атарга була.

Өченче төркемне «Düşsel Varliklar» («күз алдына китерә торган») персонажлар тәшкил итә. Бу төркемгә «Albıs (Cadı)» (сихерче), «Yelbeğen (Dev)» (Җилбәгән, Дию), «Tepegöz» («Циклоп») кебек әкияти персонажлар кертелә. Әлеге персонажлар үзләренең мифологик эчтәлекләрен, тамырларын югалтып, фольклар әсәрләренә күчкәннәр. Бу төркем «алынма» персонажлар булуы белән аерылып тора, ягъни алар төрек мифологиясенә соңрак кергәннәр һәм турыдан әкияти

персонажларга әверелгәннәр. Мәсәлән, «Tepegöz» – «Циклоп», грек мифологиясеннән кергән персонаж.

Дүртенче төркем – «Cansiz / Nesne Varliklar» («җансыз / матди затлар») – бу махсус мәгънәгә ия булган яки ниндидер изге көчне үз эченә алган әйберләр: «Kopuz» (Кубыз), «Ok» (Ук), «Otağ» (Шатыр), «Ak Dağ» (Ак тау), «Kan Irmağı» (Кан елгасы). Д. Каракурт абстракт төшенчәләрне аерым төркем буларак аера, мәсәлән, «Kut» (кот), «Yom» (бәхет), «Arpağ» (тылсым көче) [Karakurt, 2011, s. 7–9].

Д. Каракурт, Дж. Бейдили һәм Ф. Баяттан аермалы буларак, классификациясенә борынгы төрки мифологик катламны гына түгел, башка халыклар мифологиясенә бәйле персонажларны да, мәсәлән, фарсы яки гарәп мифологик персонажларын да кертә. Аның фикеренчә, төрек мифологиясе төрек халкының мифологик күзаллауларын үзенә туплаган мифологик бөтенлекне тәшкил итә, әмма ул иске легендалар, төрки халыкларның борынгыдан килгән уртак ышанулары, тәңречелек элементлары белән генә түгел, иҗтимагый һәм мәдәни яссылыкка бәйле символика белән дә тулылана. Кайбер мифологик категорияләр соңрак ислам ышанулары нигезендә үзгәреш кичергән. Шул ук вакытта төрек мифологиясендә Эгей һәм Анатолия цивилизацияләреннән мирас булып калган күзаллаулар системасы белән дә охшашлык күзәтелә. Үткәрелгән тикшеренүдән чыгып, Д. Каракурт «төрки мифология» төшенчәсе урынына «төрки мифологияләр» төшенчәсен кулланырга тәкъдим итә, чөнки аларның барысына да төрле факторлар йогынты ясаган [Karakurt, 2012, s. 888–889]. Ул төрки мифологияләрне ареалларга һәм тарихи чорларга бүлеп өйрәнә: Европа төрки мифологиясе, Буддизм төрки мифологиясе, Себер төрки мифологиясе, Анатолия төрки мифологиясе, Госманлы төрки мифологиясе һ.б.

Югарыда күрсәтелгәннәрдән күренгәнчә, «Төрки мифологик системасы»ның беренче томында Ф. Баят мифологик персонажларны төркиләрнең мифологик моделе контекстында карый. Ул дөньяны өч катка бүлә: югары – «gök», урта – «yer», түбән – «yeraltı» [Баят, т. 1, 2007]. Дж. Бейдили хезмәтендә төрки халыклар мифологиясенә хас мифологик персонажлар турында энциклопедик характердагы бай мәгълүмат тәкъдим ителә, әмма ул классификация дәрәҗәсендә бирелми [Beydili, 2005]. Д. Каракурт «Төрек мифологиясе энциклопедиясе»ндә мифка кыскача характеристика бирә һәм, башкалардан аермалы буларак, мифологик персонажлар классификациясен китерә. Автор төрки мәдәниятнең мифологик элементларын дүрт төркемгә бүләргә тәкъдим итә: классификация персонажларның һәм аларның функцияләренең аермаларына нигезләнә. Д. Каракурт тарафыннан тәкъдим ителгән классификация каралганнарның барысыннан да тәфсиллерәк һәм төгәлрәк, әлеге хезмәттә төрек мифологиясенең «күрше» мифологияләр белән бәйләнеше чагыла, персонаж исемнәренең төрле фонетик вариантлары тәкъдим ителә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтеп була: тикшерелгән хезмәтләрнең бары берсендә генә классификация дип санарлык һәм күпчелек

персонажларны үз эченә алырлык система бар. Әлеге тема классификация булдыру ягыннан да, мифологик персонажларга багышланган материалларны өйрәнү ягыннан да өстәмә тикшеренүләр таләп итә.

**Әдәбият**


*Абрамзон С.М.* Киргизы и их этногенетические и историко-культурные связи. Фрунзе: Кыргызстан, 1990. 480 с.

*Кляшторный С.Г.* Мифологические сюжеты в древнетюркских памятниках // Тюркологический сборник. 1977. М., 1981. С. 117–138.

Мифы народов мира. Энциклопедия. М., 1980. Т. 1. 1147 с.

*Неклюдов С.Ю.* Мифология тюркских и монгольских народов // Тюркологический сборник. М.: Наука, 1981. С. 183–202.

*Стеблева И.В.* К реконструкции древнетюркской религиозно-мифологической системы // Тюркологический сборник. М.: Наука, 1972. С. 213–226.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек: 3 томда. Казан: Мәгариф, 2008, 2009, 2011. 839 б.

*Халипаева И.А.* Мифология тюркских народов: Эволюционные процессы: дис. … д-ра филол. наук. Баку, 1995. 347 с.

*Хисамитдинова Ф.Г.* Мифологическая лексика башкирского языка (в этнолингвистическом освещении). Уфа: ИИЯЛ УНЦ РАН, 2016. 400 с.

*Akman D.M., Köktan Ö.Ü.Y.* Türk Ve Yunan Mitolojilerindeki Yeralti Âlemine Ait Unsurlar // Türük Uluslararası Dil, Edebiyat Ve Halkbilimi Araştırmaları Dergisi. 2019. № 19. S. 209–225.

*Beydili C.* Türk Mitolojisi Ansiklopedik Sözlük / çev. Eren Ercan. Ankara: Yurt Kitap-Yayın, 2005. 639 s.

*Karakurt D.* Türk mitoloji ansiklopedisi. Açıklamalı-resimli Türk söylence sözlüğü [Электронный ресурс] // Режим доступа: https://www.academia.edu/11557648/T%C3%BCrk_Mitoloji_Ansiklopedisi_Deniz_Karakurt_ (Дата обращения – 15.05.2022).

*Karakurt D.* Türk söylence sözlüğü. Açıklamalı Ansiklopedik Mitoloji Sözlüğü. [Электронный ресурс] // Режим доступа: https://upload.wikimedia.org/wikipedia/commons/3/34/Turk_Soylence_Sozlugu.pdf (Дата обращения – 15.05.2022).

*Bayat, F.* Türk Mitolojik Sistemi 1: Ontolojik ve Epistemolojik Bağlamda Türk Mitolojisi. Ötüken Neşriyat AŞ. [Электронный ресурс] // Режим доступа: https://books.google.ru/books?hl=ru&lr=&id=EFPSDAAAQBAJ&oi=fnd&pg=PT38&dq=T%C3%BCrk+mitolojisi&ots=lox7iBjg0K&sig=XAO0vLoWHYQAybdyW4gXYZWmOFc&redir_esc=y#v=onepage&q=T%C3%BCrk%20mitolojisi&f=false (Дата обращения – 13.05.2022).

*Bayat, F.* Türk Mitolojik Sistemi 2: Kutsal Dişi–Mitolojik Ana, Umay Paradigmasında İlkel Mitolojik Kategoriler–İyeler ve Demonoloji. Ötüken Neşriyat AŞ. [Электронный ресурс] // Режим доступа: https://books.google.ru/books?hl=ru&lr=&id=CsxqDQAAQBAJ&oi=fnd&pg=PT39&dq=T%C3%BCrk+mitolojisi&ots=yOkedIR5Wd&sig=IKnKGQ5SQ0K4FNWPG0HuEmwDL9c&redir_esc=y#v=onepage&q=T%C3%BCrk%20mitolojisi&f=false (Дата обращения – 13.05.2022).



***Фәхриева Ләйсән Марат кызы,***
*Казан (Идел буе) федераль университетының*
*Халыкара бәйләнешләр институты магистранты*

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел,*
*әдәбият һәм сәнгать институты гыйльми секретаре*

УДК 784.4

# СОЛТАН ГАБӘШИ ТАТАР МУЗЫКАСЫ ТУРЫНДА

*(дәвамы)*

*Башы журналның 2022 елның 1 нче санында*

## МУЗЫКА ТУРЫНДА БЕЗНЕҢ СОРАУЛАР[1]

### *«ЯҢАЛИФ» АНКЕТАСЫ*

**Татар музыкасы турында**

*5. Фольклор – халык музыкасын, этнография байлыкларын туплауда бездә хезмәт бармы, бу хезмәтнең төп кимчелекләре һәм нәтиҗәле яклары нәрсәдә дип уйлыйсыз?*

*6. Татардагы ике операның музыкасындагы үсеш, искелек, яңага, культурага бару моментларына карашларыгыз нидән гыйбарәт? Революцион музыкага табан үсеш сизеләме, зәгыйфьлек нидән гыйбарәт дип уйлыйсыз?*

*7. Аерым композиторлар иҗатларына (Сәйдәш, Габәши һ.б.) карашыгыз, алардагы төп сәлби[2] һәм иҗаби[3] моментлары нидә дип саныйсыз?*

*8. «Сания», «Наемщик», «Зәңгәр шәл», «Эшче» әсәрләре ташланырга тиешме, тиеш булсалар, ни рәвешле, аларның музыкаларын нишләтергә, ягъни киләчәктә культура үсеше итеп файдаланып булырлыкмы, алардагы музыканың эчтәлеге либреттоларның эчтәлегенә каршы килмиме яки либретто һәм музыкасында аерылу бармы?*

*9. Бу музыкалы әсәрләр һәм опералар пролетариат музыка культурасын тудыру өчен башлангыч хезмәтне иттеләрме, әллә киресенчә, комачаулык – киртә булып тордыларммы?*

*10. Бездә пролетариат музыкасына таба кирәк культурасы, кирәк эчтәлеге ягыннан үсүгә таба күренешләр бармы, алар нидән гыйбарәт? Татарда пролетариат музыкасына таба үсүнең бик зәгыйфь булуына композиторлар гына гаеплеме, әллә музыкалы әсәрләр яки операга эшләнгән либреттоларның эчтәлекләрендәге идеология кимчелекләре дә зур йогынты ясаганнармы?*

***Композитор Солтан Габәши***

***5 нче сорауга:*** Фольклор – халык музыкасын, этнография байлыкларын туплауда бездә беркадәр хезмәт бар. Музыка эшчеләребезнең

---

[1] Музыка турында безнең сораулар // Яңалиф. 1931. № 3. Б. 59–60, 62–71; № 4. Б. 55–60; № 5–6. Б. 86–91. Әлеге текст кириллицага нигезләнгән татар алфавитында беренче тапкыр дөнья күрә. *(А. Софийская иск.)*

[2] Сәлби – кире.

[3] Иҗаби – уңай.

һәркайсының диярлек кулларында көйләр мәҗмугалары бар. Ул нәрсә миндә дә юк түгел, аңа да ике йөзләп көй җыйналган[1]. Сәйдәш, Мозаффаров, Йосыпов, Яушевлар, Зөлкарнәевләрдә дә болар бардыр дип уйлыйм. Гыйльми үзәктә карт музыка мастеры Гыйлаҗ Сәйфуллиннан[2] алынган бер мәҗмуга саклана. Минем үземдә Сәйфуллин тарафыннан киселгән өч йөзгә якын калай пластинкалар бар һәм шулар ук хәзерге көндә Гыйльми тикшеренү институтының музыка кабинеты тарафыннан киселеп яталар[3].

Ләкин бу көйләр безнең үзебез күп мәртәбәләр ишетеп белгән һәм уйнап җырлаган көйләр, яки иттифакый берәр җирдә, яки берәр кешедән ишетелгән көйләр генә булып, иң зур өлеше Казанның эчендә йә аннан бик ерак булмаган яклардагы көйләр генә. Казаннан читтә, еракта яшәгән чын крестьян массасы эченнән әле берәү дә махсус йөреп, эзләп, җыйнап язганы, алганы юк. Ишетелүгә һәм чамага караганда, мондый байлыклар керәшен татарлары арасында бигрәк тә күп булса кирәк. Шунлыктан Казанның ерак якларында, киң крестьян массасы эчендә әле без белмәгән бик зур байлыклар булса кирәк дип уйлыйм. Менә шул байлыкларның җыйналмавын бу юлдагы бик зур җитешсезлек-кимчелек саныйм. Ләкин бу җитешсезлекне бетерү юлына инде адым атланган. Гыйльми тикшеренү институтының Музыка кабинеты махсус экспедицияләр чыгарып, бөтен ТССРны тикшереп чыгуны үзенең эш планына кертте.

Икенче кимчелек итеп, язуларның күп вакытта зәгыйфь булуларын йә тулы булмауларын исәпләргә кирәк. Мәсәлән, шул ук Г. Сәйфуллин мәҗмугасын алсак, аның язучысы теория белән таныш булмаганлыктан, аның язылышы, гади тел белән әйтсәк, имлясы дөрес түгел. Аны әле яңадан бер кат редактировать итеп чыгасы бар. Читләр язганнарны алсак, баштарак әйтеп киткән сүзне, ягъни «тулы булмыйлар» дигән сүзне кабатларга туры килә. Һәм аны бер Рыбаков турысында гына түгел, Прохоров, хәтта Козлов хакында да әйтергә туры килә. Үрнәк өчен аның («Известия Общ. Археологии, Истории и этнографии», том XXXIV, вып. 1.)[4] да чыгарган көйләрен алам: ниһаять үземнең язганнарымны алганда да, аларның бик күпләре басырасы, кешегә күрсәтәсе булмагач, нык әһәмият биреп, тулы итеп һәм дөресләп язылмаган, фәкать истән чыкмасын өчен генә язылып куелган набросоклар хәлендә генә яталар.

---

[1] Габәши Солтан. Милли моңнар. Төрек-татар көйләре. Кулъязма. ЯМҮ: 60 ф., 1 тасв., 2 сакл. бер. *(А. Софийская иск.)*

[2] Г. Сәйфуллинның кулъязма җыентыгы музыкаль тартмалар өчен металл пластинкаларда язылган татар халык җырларының нота расшифровкаларыннан гыйбарәт. *(А. Софийская иск.)*

[3] Аннан башка чит милләт галимнәре тарафыннан җыйналган берникадәр нәрсә бар. Мәсәлән, Козловның язган нәрсәләре, Прохоровның бастырып чыгарган җиде көе, Эйхенвальдның язган көйләре, ниһаять, Әлмөхәммәтов, Виноградовларның бастырган көйләре һәм профессор Богородскийның бастырган җиде көе. *(С. Габәши иск.)*

[4] Кириллицада бирелгән.

Өченче кимчелек шул кулыбызда булган кадерле байлыгыбызны да киң масса файдалануына тапшыра алмавыбызда, икенче төрле әйткәндә, тарата алмавыбызда дип уйлыйм. Бу бастыра алмауның беренче сәбәбе әлеге татар көйләрен гармонияләштерү ысулларының табылмавы, хәл ителмәве булса, икенче һәм иң зур сәбәбе «Татиздат»-ның гомумән ноталарга үтми торган товар дип карап, ноталар бастыруга нык каршы торуы.

Моңа дәлил итеп, моннан биш-алты еллар элек хор өчен язылган ун көйлек бер мәҗмугамны Татиздатка биреп тә, дүрт ел басылмый ятканнан соң, кайтарып алырга мәҗбүр булганымны күрсәтәм. Ә мәктәпләр, клублар, җырчы-уенчылар музыкадан материалга сусап, кайдан табарга белми, эзләнеп йөриләр. Хәтта ноталар сорап, безне аптыратып бетерәләр.

Нәтиҗәле ягы шул: басылмаган хәлендә генә булган байлыктан да хәзергә кадәр бик нык файдаланып киләбез. Халык көйләре уенчылар-җырчылар тарафыннан бик күп уйналу, җырлану өстенә, ничек кенә булса да, гармонияләштереп, оркестрлар белән дә ифадә ителәләр. Мәсәлән, радиотапшырулар да бу юлларда ифрат зур урын тоталар. Шул ук халык көйләре яңа музыка әсәрләребезнең бик күбесенә нигез булып хезмәт итәләр, хәтта операларыбызның эченә кереп тә зур роль уйныйлар.

***6 нчы сорауга:*** Татардагы ике операның икесенең дә язучыларыннан булганлыгым өчен, бу сорау турында күп сөйләүне уңайсыз табам. Шулай да әле моннан ун-унбиш еллар гына элек борынгы заманнан калган халык музыкасыннан башка әйбере булмаган бер халыкның шул кыска вакыт эчендә опера иҗат итә алуга кадәр барып җитә алуын «искелеккә бару» яисә «үсеш түгел» дип кем әйтә алыр? Әгәр дә болай диюче булса, ул бөтен культур галәмнең фикеренә каршы барган булыр иде. Моны дөресләр өчен, «Сания»нең Франкфурт шәһәрендәге бөтендөнья күргәзмәсендә булып, аңа Европа матбугаты тарафыннан «Татарстанның гадәттән тыш культур үсешенең билгесе» сыйфатында аттестация бирелүе җитсә кирәк дип уйлыйм.

Революцион музыкага таба үсеш мәсьәләсенә килгәндә, «Сания» – беренче тәҗрибә, көч сынап карау, һәм музыкабызның үсешкә кабилияте[1] бармы, юкмы дигән сорауга җавап эзләп каравы иде. Шуңар күрә без шикле бер эшкә тотынган вакытта, фабула итеп, гаять җитди, гаять җаваплы һәм ифрат авыр булган «музыка белән сыйныфлар көрәшен тасвирлау»ны алырга батырчылык итә алмадык. Моның өчен безне критиклар гафу итсеннәр. Шунда да «Сания» өчен фабула итеп, кечкенә булса да көрәш, 1905 елдан соң татар дөньясында булып узган картлар белән яшьләр, иске фанатик, самодур байлар белән укымышлы ярлылар арасындагы көрәш алынган иде. Бу көрәшнең тышкы сыйфаты мәхәббәт сәбәпле барган итеп күрсәтелсә дә, иске һәм төп сәбәбе – Зарифның (Сания атасы) кулак бай булып,

[1] Кабилияте – сәләте.

Зыяның «эттән ярлы, Алласыз, малсыз, патша сүгеп йөргән малай» булуында икәнен Зариф үз теленнән әйтеп бирә.

Менә бу ике агым, ике тартышучы тарафыннан алып барылган көрәш музыкада да күрсәтелә. Яшьләрдә иҗади – матур музыка бирелгән хәлдә, сәлби типлар Зариф, бигрәк тә староста, шулай ук сәлби һәм мәгънәсез, ямьсез музыка белән күрсәтеләләр. Дөрес, музыкадагы аерылу әле революцион музыка дәрәҗәсенә барып җитә алмый. Ләкин шулай да ул киләчәк операда («Эшче»дә) музыканы икегә бүлеп, класслар музыкасы рәвешендә файдалануга нигез булып тора.

«Эшче»дә исә музыканың класслар музыкасы принцибында алынып, беренче пәрдәдә әле аз гына аерымлык белән башланган бу музыка тартышы, ахыргы пәрдәләрдә классларның ачыктан-ачык көрәшләре-бәрелешләре хәленә барып җитә икәнен игътибар беләнрәк, әһәмият биреп тыңласак, һәркем аңлый, ишетә алса кирәк дип беләм.

***7 нче сорауга*** җавап бирүне урынсыз дип саныйм.

***8 нче сорауга:*** Сорауда күрсәтелгән әсәрләрнең киләчәктә музыка культурасының үсешенә зур хезмәт итеп, нигез булып торулары турында югарыда әйтелгән иде. Шунлыктан, минемчә, әле алар хәзергә ташланырга тиеш түгел, моның өчен әле иртә. Бу мәсьәләдә рус музыка дөньясында күп бәхәс ителгәннән соң, хәзер яңа пролетариат опералары тудыру өчен, иске мирасның зур хезмәтләре тиячәгене истә тотып, иске операларны саклау һәм аларны булган хәлендә һич курыкмый, шикләнми пролетариатка күрсәтү фикеренә килгәндә, «Известия[1]« гәзитенең 1931 елгы 9 гыйнварда чыккан (4216) нчы санында Большой театрның рабочий районнарга чыгуы уңае белән язылган «Яхшы башлангыч» («Хорошее начинание»[2]) дигән мәкаләдә менә бу сүзләр әйтелә:

«Чайковский, Римский-Корсаков һәм Мусоргский операларыдай үзләренең музыкалары һәм художество гадилекләре ягыннан классик әсәрләр тыңлаучыны классик музыкага ияләштерәләр һәм төрле музыкаль халтура һәм шапшаклык белән көрәштә аның кулына көчле корал бирәләр. Һәм «Пиковая дама», «Онегин»нар пролетариат идеологиясен «оялтырлар» дип уйлар өчен, пролетариаттан бик читтә булырга һәм аның бөек культур үсешен аңламый торган булырга кирәк».

«Музыкаль драмаларның беренче төзүчеләре – Мусоргский һәм Вагнерлар, халык музыкаль әсәрләре һәм алар артыннан безнең революциягә якын торган башка яшь музыкаль көчләр ул чакта киң масса милкенә әйләнерләр, бу массада әдәбияттагы үз Горькийлары, үз Демьяннары, үз Гладковлары төсле үк, үз пролетар композиторлары тууга булышырлар».

---

[1] Бу сүз кириллицада бирелгән.

[2] Бу сүзтезмә кириллицада бирелгән.

«Зур театр кулында киң массага тәэсир итүнең иң зур, иң көчле коралы ун елларча түгел, йөз елларча төзелгән музыкаль һәм вокаль техника бар. Бу техниканы һичбер төрле шикләнүсез һәм кыек аңлаусыз пролетариатка хезмәт иттерергә кирәк. Музыкаль культураның үсешенә тормазлаучы яраксыз чара булган сәнгатьтәге үзенең группасына гына, үзенең цехына гына «чын юллылык» претензияләре группачылык һәм фракциячелеккә ташларга кирәк».

***9 нчы сорау***га инде җавап бирдем.

***10 нчы сорау***га кисеп җавап бирү өчен, «Пролетариат музыкасы нидән гыйбарәт булырга тиеш?» дигән нигез мәсьәләгә җавап биргән булырга кирәк. Ләкин бу мәсьәлә бездә генә түгел, әле рус музыка галәмендә дә чишелмәгән хәлдә, фәкать эзләнү һәм бик каты дискуссия ясалу хәлендә генә тора. Бездә «пролетариат музыкасы» дигән сүзне бары агитация өчен генә хезмәт итә торган, лириканы да, романтиканы да, шулай ук быт әхвален дә эченә алмый торган ниндидер аерым бер музыка дип карап, аны художество музыкасына каршы куеп йөртү бар. Бу хакта Лебединский «Пролетар массасы җыры» («О пролетарской массовой песне»)[1] дигән китабында:

«Кирәк махсус бу эш белән җитәкчелек итүче дәүләт аппараты эшчеләре арасында булсын, кирәк тәнкыйтьчеләр арасында булсын, «Музыкаль»-художество әдәбиятын надан рәвештә һәм торышы белән буржуача аеру, еш кына аны гомуммахсус агитация масса әдәбиятына каршы кую фикере бик таралган.

Бу композиторларны ялгыш ориентировать итә, аларның иҗатларында зыяны чагыла, масса җыры төзү мәсьәләсенә юл куелмаслык җиңел мөнәсәбәткә булышлык итә.

Масса җыры мәсьәләсен иҗади җирлектә куймастан, һөнәрчелек-эшлеклелек җирлегендә кую ниндидер махсус масса җыры төзү турында сөйләү, бер яктан, музыка тәнкыйте өлкәсендә безнең көчләребез юклыгын чагылдырса, икенче яктан, пролетар масса җыры эшенә хәленчә зыян да китерә иде. Дөресендә, мәсьәлә хәзерге музыка иҗатын пролетариат идеологиясе һәм аның культур кирәкләре торышы карашыннан тәнкыйтькә алу, композиторларның массага якын, актуаль һәм сюжетларга ориентациясе тормышның үзе күтәрә торган һәм массада яши торган яңа музыкаль формалар эзләү һәм табу җирлегендә куелырга һәм хәл ителергә тиеш», – ди.

Икенче урында «Кирпичники», «Чай пила»[2] кебек әйберләрнең масса эчендә яшәү сәбәпләрен тикшереп:

«Алар нидә торалар соң? Эшче һәм эшче хатын-кызның канәгатьләндерелмәгән, ләкин чынында билгеле төр романтикада, җырда бытның кара һәм якты якларын, интимный һәм быт настроениеләрен белгертүендә» дигәннән соң:

---

[1] Җыр исеме кириллицада бирелгән.

[2] Бу исемнәр кириллицада бирелгән.

«Хәзерге вакытта массада, һичшиксез, чын герой һәм революциянең чын төзүчесе урта эшченең тәэсиратларын, үзенә якын булган настроение һәм тәэсиратларны сизә алырлык быт җырларына, кайчакта лирик, кайчакта драматик җырларга омтылыш бар», – ди.

Мин менә бу фикерләрне дөрес тапканлыктан, пролетариат музыкасына һәм гомумән пролетариат сәнгатенә фәкать сәясәттән генә торган коры бер сәнгать булырга тиеш дигән төсле карашларны дөрес түгел дип табам һәм шул ук Лебединскийның:

«Теоретик» композитордан билгеләнеп кабартылган «сәясәт» белән «идеология»не соравы мөмкин. Пролетар композиторны үз юлында очрый торган төрле головотәплекләр куркытмасыннар. Ул бу чакта теоретикларның революциягә зарар гына итүләрен, ләкин файда бирмәүләрен белсен» дигән сүзенә кушылам.

Шуңар күрә мин пролетариат музыкасы һәм гомумән революцион музыка турында сүз йөрткәндә, бөтен СССР күләмендәге музыка конференциясе әйткән: «Музыка төзелеп яткан социализмга аккомпанемент булып барырга тиеш», – дигән нигездән чыгып сөйләргә кирәк дип уйлыйм. Ләкин бу нигездә әйтелгән «аккомпанемент»ның тышкы рәвеше, формаль ягы, югарыда әйткәнчә, әле билгеләнмәгәнлектән, без хәзерге музыка һәм музыкаль әсәрләр турында сөйләгәндә, аларның тематикасы һәм эчтәлегенә карап кына сүз йөртергә мәҗбүрбез.

Менә бу яктан – тематика һәм эчтәлек ягыннан бездә революцион музыканың үсүенә таба күренешләр бар дип, мисал өчен, түбәндәге әсәрләрне санап күрсәтәм:

Минем тарафтан хор өчен язылган «Эшче кызы» – Кәрим Әмири сүзләренә, шул ук Әмиринең сүзләренә язылып, Комсомолның 6 нчы съездында үтәлгән дингә каршы әйбер – «Комсомол мөнәҗәте»; Крыймовның «Октябрят бишектә», «Октябрь» һәм «Авылыма» дигән шигырьләренә махсус язылган көй, 1929 ел Сәнгать техникумы укучылары язгы чәчү компаниясенә чыкканда алып чыккан һәм крестьян массасы тарафыннан яратып каршы алынган. «Колхоз җырлары» – Ганиев сүзләре, минем үк әйберләр: «Бер буржуйның зары», «Салчылар» һәм 5 нче ел революциясенең 20 еллыгына карата, 1905–1925 еллар арасындагы аерманы күрсәтү өчен язылган «Ике заман» дигән әйберләр, ялгыз җыр өчен Такташ сүзләренә язылган «Кызыл батыр», Газиз Әлмөхәммәтов тарафыннан 21 нче ел ачлыгына карата язылган «Шомлы җыл» һәм Маяковскийның үлеменә багышлап язылган «Юлдыкай» дигән әйбере, Сәнгать техникумы укучысы З. Хәбибуллинның бу ел гына язып, культэстафета уңае белән үтәлгән берничә әсәре һәм башка яшь авторларның берничә әсәрләре, инструменталь әйберләрдән: Татарстанның 3 нче елына ук багышланып, минем тарафтан язылып, Литвинов оркестрга салган «Татарстан маршы», С. Сәйдәшевнең Кызыл гаскәр өчен язган маршлары, Сәнгать техникумы укучысы Батыршинның «Комсомол маршы» һәм башка оркестр әйберләре,

З. Хәбибуллинның «Татарстан 10 еллыгы маршы», бу ел Мәскәү консерваториясен бетерүче М. Мозаффаровның «Көтүче җыры», «Колхозниклар маршы» һәм шулай ук «Татарстанның 10 еллыгы маршы», безнең коллектив (Әлмөхәммәтов, Виноградов, Габәши) тарафыннан язылган монументаль-зур әсәрләр: «Яңалиф маршы» һәм «Эшче» операсы.

Бу соңгы ике әсәрнең пролетариат музыкасы дип аталырга күпме хаклары турында үзем сөйләмәстән, беренчесе хакында Казанда булган 3 нче Яңалиф пленумының «Союз җөмһүрият һәм өлкәләрендәге бөтен яңалиф тарафдарлары өчен Габәши һәм Әлмөхәммәтовлар тарафыннан төзелгән «Яңалиф маршы»н кабул итәргә һәм Бөтенсоюз яңалиф үзәк комитетына бу маршны басу һәм аның ноталары белән җөмһүриятләрнең Бөтен үзәк комитетларын тәэмин итәргә йөкләргә» дигән карарын күчереп, хәзерендә яңалиф хәрәкәтенә катышкан бөтен өлкәләрендә бу маршның бердәнбер «Яңалиф маршы» гимны булып уйналып йөргәнлеген күрсәтәм. Ә икенчесе – «Эшче» хакында Мәскәү матбугат һәм критикасы сүзләрен күчерәм:

1) Мәскәүдә сәнгатьләр олимпиадасы вакытында бары өч кенә театрга (грузин, үзбәк музыкаль театры һәм татар операсына) үз битләрендә урын биргән «Правда» гәзите:

«Операда таза, җанлы орлык бар. Эшче бытын күрсәтү музыкаль фактураның сентиментальлеге, төссезлегеннән тыш, көчле, ачык ритмнарда җәелергә тиеш һәм авторлар халык җырларына таянып, ләкин аларны бөтенләй кул тимәгән килеш үз операларына кертмәстән бик дөрес эшләгәннәр.

«Эшче» – халык көенә иҗади якынаю омтылышы, аңарда ярлы крестьян һәм көрәшүче пролетариат психологиясе чагылдырылган.

Опера ополитик халыкчылык төсеннән чит булып, сәяси хәрәкәтле һәм кирәкле күп моментларны эченә ала». Аннан соң операның үтәлүе (исполнение[1]) турында бераз туктап:

«Театр алдында зуррак өйрәнү (учеба[2]) тора, ләкин «Эшче» операсы төзүдә беренче адым атланган һәм бу татар эшче опера театры өчен алдагы көрәшне җиңеләйтер», – ди.

2) «Рабис» журналы:

«Композиторлар хәзерге пролетариат операсы бурычларына, тулысынча сюжет ягыннан дөрес килешләренә карамастан, иске музыкаль штамплардан котыла алмаганнар» дигәннән соң, мәкаләне бу сүзләр белән бетерә:

«Һәрхәлдә, «Эшче»не татар пролетар операсына хәзерлектә беренче этап итеп санарга кирәк.

Тарихи балласттан котылу һәм гадәттәге опера тематикасы белән өзелеш ясау, һәрхәлдә, яхшы прогнозга нигез бирә».

---

[1] Бу сүз кириллицада бирелгән.

[2] Бу сүз кириллицада бирелгән.

3) «Культура и революция» журналы, постановканың җитешсезлекләрен санап килгәндә, болай ди:

«Зур опера» стилендәге зиннәткә көчәнеп, постановщиклар дөресендә хәзерге моментта бездә совет сәхнәсендәге опералардан иң пролетарча тематикасын бирәләр:

4) «Красная Татария»гә язган мәкаләсендә Поляновский:

«Эшче» үзәк театрлар репертуарларында булган совет операларына караганда иске опералар эчтәлеге белән гаять артык радикалырак өзә.

Либретто үзендә музыкант-композитор формасы белән, милли һәм эчтәлеге белән тулысынча интернациональ булган сәнгатьнең иң шәп узорларын киңәйтү өчен яхшы канва дип, ахырында болай ди:

«Постановканың гомумйомгагы: татар операсына башка халыклар театрыннан өйрәнердәй нәрсә бар. Шулай ук безгә Мәскәү театрына һәм милли җөмһүрият театрына, татар сәнгатеннән өйрәнерлек күп нәрсә бар», – ди.

Октябрьдән соң гына аякка баса башлаган һәм бөтен композиторлык составы ике кул бармагы белән санарга да җитмәгән, бер музыка өчен бу үсешне юк дип әйтергә мөмкин түгелләр дип уйлыйм.

Ә үсешнең «нидән гыйбарәт» икәне шул югарыда күрсәтелгән әсәрләрнең исемнәреннән үк күренеп тора. Күбрәге – массовый хәрәкәткә карата, зурмы-кечкенәме масса белән күмәкләшеп (оркестр, хор белән) үтәү өчен төзелгән әйберләр. Ләкин алар, бер яктан, сыйфатлары (күмәкләшеп үтәүгә мохтаҗ булулары сәбәпле), икенче яктан, һичберсенең бастырылып таратылмавы сәбәпле, киң масса тыңлаучы алдына еш куела, күп кабатлана алмыйлар һәм шуның аркасында күз алдыннан югалып, бөтенләй юк хөкеменә әйләнәләр.

Шуның белән бергә, бу үсештә бик зәгыйфь бер участканың барлыгын да яшерер хәл юк. Ул да булса, һәр җирдә һәркем тарафыннан дигәндәй, җиңел үтәлә ала торган концерт һәм эстрадаларда соло (ялгыз) җырлау өчен заманыбызның теләвенә каратылган сүзләргә махсус язылган әсәрләрнең булмавы.

Бу юклыкта, бәлки, хәзерге көндә булган композиторларыбыз гаепле дәдер, ләкин аларны гына гаепле итәргә мөмкин түгел дип уйлыйм.

Төп гаеп музыка иҗатының, материал аз булу сәбәпле, гаять авыр бер эш булуында дип уйлыйм. Бу кыенлыкны аңлату өчен, бер мисал китерим. Бер кешенең җырлый ала торган тавышлары, бик күп булса, 2 октава санала. Бу 2 октавада, Европа гаммасы буенча 7 табигый тавыш арасыннан җыеп исәпләгәндә, барысы 25 тавыш чыга. 5 тавышлы кытай гаммасы нигезендә исәпләсәң, ул 18 тавышка гына кала. Менә бу тавышларның һәрберенә бер иҗек җырларга мөмкин. Димәк, музыкант бөтен әйтә торган сүзен, шул 25 иҗектән оештырырга тиеш. Әгәр ул сүз тагын саф татарча да чыксын дисә, 18 генә иҗектән оештырырга мәҗбүр. Шуңар күрә теләгән бер оратор, йә теләгән бер шагыйрьгә 25 иҗек биреп, шуларның комбинацияләрен-

нән җитди бер әсәр төзергә кушылганда, музыка иҗатының авырлыгына ошаганрак бер хәлне күз алдына китереп булыр иде дип уйлыйм.

«Ун меңнәр белән саналган музыкантлары, меңәрләп музыка галиме, йөзәрләп композиторы, ничә гасырлар тарихы һәм шул тарих эчендә дистәләп даһи узган рус музыка галәмен “Массовый музыкасы һәм аны төзү” мәсьәләсе күптәннән инде совет җәмәгатьчелеге һәм бөтен безнең музыка дөньябыз алдына куела. Ә массовый музыка һәмишә[1] юка дип әйттерткән нәрсә дә шул булса кирәк дип уйлыйм»[2].

Икенчесе: һәркемгә мәгълүм сәбәпләр аркасында композиторларыбыз үз иҗатлары белән генә яши алмаганлыктан, мәгыйшәтләрен тәэмин итәр өчен, башка берәр эш белән шөгыльләнергә мәҗбүрләр, ул эш аларның бөтен вакытларын ала. Шул төп эшләре белән мәшгуль булу өстенә, алар шулай ук музыкант булу сәбәпле дә, башка кешеләргә караганда, җәмәгать эшләрендә артыграк катнашлык итәргә мәҗбүр булалар. Алардан да арттыра алган вакытларын югарыда күп сөйләгән зур иҗатлары өстендә уздыралар. Инде аннан да артык вакыт табу мөмкин түгел булып чыга. Кыскасы, композиторларыбыз артык күп эшле (перегружены[3]) булып, ирекле иҗат өстендә утырырга вакытлары калмый.

Өченче сәбәп буларак, композиторларыбызның шул ук сәбәп белән төп пролетариат массасыннан читтә яшәүләре һәм аның белән элемтәләре әз торулары булырга мөмкин. Мисал өчен үземне алсам, 28 нче ел җәенең «Эшче»нең II, III пәрдәләрен язар алдыннан Урал эчендәге һәм Златоустагы заводларга Мәҗит ага Гафури һәм Әлмөхәммәтовлар белән берлектә махсус ясаган экскурсияләребездән башка (ара-тирә клубларга концерт белән баруны алмаганда) һичбер завод-фабрика, чын пролетариат эчендә була алганым юк. Ике, өч ел инде колхозлар хәрәкәте башланганга, ә мин әле бер колхоз күргәнем юк.

Дүртенче – сәбәп композиторлар белән шагыйрьләребез арасында элемтәнең начар булуы, хәтта бер дә булмавыдыр, дип уйлыйм. Кайвакытта берәр төрле фикер килә йә берәр музыкаль яхшы берәр фигура күңелгә төшә. Ләкин шуларны гәүдәләндерергә яраклы сүз булмый. Сүз өчен кемгә мөрәҗәгать итәргә белмисең дә, алар ятып калалар. Мисал өчен шушы фактны китерим: елдан артык инде «Дисәнә» дигән халык көен квартет өчен үзгәрткәләп (варьировать итеп), колхоз хәрәкәтенә агитировать итә торган кечкенә генә бер картина язмакчы булган идем. Башыннан берникадәр җирен шул ук халык җырыннан үзгәрткәләп, Теләшев әйтмешли, әллә нәрсә күтеп булмаган каләмем белән өстерәп алып килеп карадым да ахырында җитә алмый төртелдем, һәм ул әйберем хәзерге көндә дә шул башланган килеш ярты юлда ята бирә. Мин ике кешегә мөрәҗәгать

[1] Һәмишә – һаман.

[2] Шул ук Лебединский сүзләре. *(С. Габәши иск.)*

[3] Бу сүз кириллицада бирелгән.

итеп карасам да, «Ярый, эшләрбез» вәгъдәсеннән артык эш чыкмады, вакытларыбыз туры килми. Мөрәҗәгать иткәндә дә артык басып кушарга (настаивать[1] итәргә) туры килми. Чөнки эшләнәчәк әйбернең басылмаячагы алдан билгеле булу, эшнең бушлай эшләнергә тиешле булуын аңлатып үтенү сорау дәрәҗәсеннән узарга ярамаганлыгын күрсәтеп тора.

Мондагы элемтәне нинди дә булса бер вәзен белән, берничә шигырь язып ташлау дип кенә аңларга ярамый. Күбесенчә, язылган сүзләргә музыкаль оформление биргән вакытта, күңелгә яңа уйлар төшә, яңа икенче фигура, икенче форма кертергә кирәксенелә. Шул вакытта сүзләрне өстәргә йә киметергә, йә үзгәртергә, алмаштырырга, язарга, кыскасы, сүзләрне берничә кабат язып чыгарга туры килә. Димәк, шагыйрь белән музыкантка озак заманнар бергә эшләргә кирәк була.

Менә шушындый элемтә бездә булганы юк дияргә мөмкин.

Бишенче сәбәп шагыйрьләребез өстендә. Язган әсәр-шигырьләрнең музыкага салыну эшләре юлга куелмаганлыктан, шагыйрьләр әсәрләренең музыка биргәлектән үтәлүләре турысында уйлап та карамыйлар булса кирәк, бервакытта диярлек музыка салу өчен көйләнгән һәм уңайлы булган тулы мәгънәле кыска-кыска гына шигырьләр язмыйлар.[2] Аларның гади язылыш белән язылган әйберләрен алып караганда, алар, беренчедән, күп сүзлек – озынлыкка мөбтәля[3] булсалар, икенчедән, симметрия кагыйдәсенә аз әһәмият бирү һәм бер дә игътибар итмәү белән сыйфатланалар. Хәлбуки бу ике сыйфатның икесе дә ул әсәрләргә музыка язуга иң зур комачаулыклар булып торалар. Чөнки, сәхнәдән җырлау өчен озын юллы шигырьләрдән 4 юл (2 мисраг) сүз җитеп, иң күбе сигез юл (дүрт мисраг) булырга мөмкин. Аннан да артса, тыңлаучылар күтәрә алмый, ялыга башлыйлар. Менә бу нигез теләк булган кыскалыкка озын шигырьнең башыннан йә артыннан 8 юлны кисеп алу шикелле операцияләр белән генә ирешеп булмый. Чөнки әйтелә торган фикер әсәрнең башыннан ахырына кадәрле тигез чәчелгән булып, сүзләр бер-бере белән бәйле булганлыктан, операция ясау белән фикер өзелеп, шигырьнең мәгънәсенә зарар килә йә ул бөтенләй югалып кала.

Инде симметрия мәсьәләсенә килсәк, музыкада ул төп мәсьәләләрнең берсе хисапланып, музыкаль җөмлә төзү эше бөтенләе белән симметрия кагыйдәсенә нигезләнә. Чөнки сүз мәсьәләсендә бер иҗек белән генә дә бер мәгънә аңлатып булса да, музыкада бер тавыштан

---

[1] Бу сүз кириллицада бирелгән.

[2] Бу урында характерлы шул хәлне күрсәтеп китми хәл юк. Мин бу бишенче елдан бирле Казанда торам. Минем музыка һәм композиция белән шөгыльләнгәнемне шагыйрьләрдән һәркем белә торгандыр, һичбулмаса ишеткәне бардыр дип уйлыйм. Менә шул мөддәт эчендә «Таһир – Зөһрә»сенә көйләр язып бирүне сораган Фәтхи Бурнаштан башка, үзенең берәр шигыренә музыка язарга тәкъдим иткән һичбер кеше булмады. *(С. Габәши иск.)*

[3] Мөбтәля – дучар.

көй (мотив[1]) ясап булмый. Иң азында ике тавыш кирәк. Аннан соң сүз белән өч иҗекне бер рәттән тезеп куйганда, бербөтен җөмлә оештырып булса, музыкада өч нотаны рәттән тезеп куеп кына бөтен җөмлә төзеп булмый. Аның өчен әлеге өч нотага каршы, аларга җавап булып төшә торган тагын өч нота йә алар урынына торырлык озынлыктагы берәр фигура кирәк була. Шуннан соң гына музыкаль җөмлә тәмам була ала. Менә музыкада, гомумән, шундый зур урын тоткан симметрия мәсьәләсе югарыда әйтелгән кыска шигырьләр һәм кыска көйләр өчен гаять мөһим бер мәсьәлә булып тора. Мәсәлән, аларда берьюлы 7 иҗекле, икенчесе 13 иҗекле, 3 нчесе 5 иҗекле шигырьләр булырга мөмкин түгел.

Дөрес, озын шигырьләргә дә музыка язарга мөмкин. Ләкин аларны югарыда әйткәнчә, бер көйгә генә җырлап чыгарга мөмкин булмый. Шунлыктан аларның һәрбер җөмләсе саен дигәндәй, аерым көйләр, яңа ритмик фигуралар бирә барырга кирәк була. Менә бу чакта аларның, кыска шигырьләрнең киресенә буларак, бөтен ахырына кадәр бер вәзендә булмый, вәзеннең алышына баруы яхшырак булып, симметриягә игътибарсызлыгы зарар итми генә түгел, бәлки файдалы да була. Ләкин андый шигырьләрдән ун, унбиш минут хәтта артыгракка да җырлана торган бөтен бер ария, хәтта кечкенә опера диярлек дәрәҗәдә зур әйберләр хасил булганлыктан, алар техника һәм сәнгать ягыннан бик нык эшләнүне телиләр. Һәм шуңар күрә аларны язу да, алар өстенә махсус күп вакытлар, күп эшне сораган кебек, үтәү өчен дә бай техникалы зур артистлар булуны таләп итәләр. Болар икесе дә, әлбәттә, җиңел шартлар түгел.

Аннан соң тагын бик авыр мәсьәлә – музыка теләгенә хәрефләрнең туры килмәве. Мәсәлән, көйнең барышы яки шигырьдәге сүзнең мәгънәсе буенча бер сүзне югары тавыш белән каты кычкырып җырларга туры килә, ә карасаң, шул ук сүз үзе тавыш бирдерми торган «к», «х» төсле тамак төбе хәрефләре яки «и», «е», «ы» төсле тавыш чыгартмый торган хәрефле иҗекләр була. Менә шундый бер-ике туры килмәү бөтен эшне юкка чыгара да куя.

Ахырда, бик күп шигырьләрнең үзләрендә һәм сүзләрендә музыкальность һәм шигърияткә – художествога әһәмият бирелүен дә искә алмый хәл юк. Мин бу хакта шул ук Лебединский сүзләрен китерәм:

«Әгәр композитор яки шагыйрь иҗат материалы сыйфатында нинди булса сюжет алса, ул бу сюжетны эшче бытына якынайтырга кирәклекне һәм моны эшләү мөмкин икәнлекне хәтердә тотарга тиеш. Бу моментка еш кына художник тиешенчә игътибар итми, ә ул исә гаять әһәмиятле момент.

Стачка, геройларча хәрәкәтлек тасвирлаучы гадәти образлар тел ягыннан бу темалардагы сәяси докладлар, брошюра, гәзит мәкаләләреннән һич аерылмыйлар. Музыка да шулай ук мондый чакларда коры, трафаретный була. Нәтиҗәдә, художество әсәрләре эшчегә җитмиләр һәм безгә аңардан еш кына: «Нәрсә? Концерт?» « Бик шәп.

[1] Бу сүз кириллицада бирелгән.

Ләкин революцион түгел!..» дигәнне ишетергә туры килә. Нәрсәгә? Бик гади – бу сәнгать түгел. Бу тик начар, талантсыз (шуңар күрә дә ул эч пошыра) рәвештә сәясәтне дублировать итү. Эшче сәясәтне, публицистиканы болай дияргә ярый, беренче кулдан, бу эшнең белгечләреннән, докладчылар, журналистлардан алуны артыграк күрә һәм ул хаклы да. Композиторлар һәм шагыйрьләр шуңар күрә эшченең үзләреннән, бәлки шул ук сюжетларындыр, шул ук темаларындыр чагылдырылуын, ләкин тәэсир итү ягыннан бөтенләй башка планда, сәнгать романтикасы белән сугарылган, шигъриятләштерелгән рәвештә бирелүен көткәнен исләрендә тотарга тиешләр».

Сәбәпләрдән берсе – бездә тәнкыйть тиешле хәлдә булмавы да. Бу тәнкыйть эше рус галәмендә дә шәп түгел. Ул хакта шул ук Лебединский бу сүзләрне яза:

«Музыка өлкәсендә, композиторларга юл күрсәтүче, тәрбияләүче иҗтимагый марксчы тәнкыйть турында сөйләү дә көлке: бездә ахры чиктә, безнең гәзит һәм журналларыбызның «Музыка» бүлекләрендә мондый тәнкыйть юк.

Принципсыз, экликтик һәм еш кына яңа әсәрләргә тиз генә, надан эшләнелгән рецензияләр, иң күп өлешләрендә, һичбер төрле фикердә түгелләр. Әгәр мәгънәсез сүзләр һәм фразалар наборын чистартып ыргытсаң, күп чакта тулы бушлык кала.

Пролетариат йогынтысын үткәрергә, композиторны эшче сыйныфка якынайтырга тиешле тәнкыйть, композиторга караганда да, аңардан ераграк булу гына түгел, бәлки үзенең күпчелегендә эшче сыйныфка чит, кайчакларда дошман да була».

Бездә бу хәл тагы да йомшаграк тора.

Музыка өлкәсендә аз гына булса да белеме булган һәм аның өстенә дөрес сәяси карашы булган кешеләр бездә юк. Шунлыктан аерым кешеләр, һичбер нигезсез-нисез фәкать үз хисләренә, үз максатларына таянып кына, теләсәләр ни язып килделәр. Мәсәлән, берничә ел рәттән музыка тәнкыйтьчесе сыйфатында «җидегәнче» Кутуй эшләп килде. Бу кеше, гомумән, юньле-башлы бер сүз әйтә алмаса да, музыка галәмендәге эшчеләр арасында группачылык оештырып, үзара сугыштырырга маташып, теләгән бер әйберен һичбер нигезсез мактап, (яисә үз кәефенә һәм сәясәтенә кирәкле булса), шулай ук һичбер нигезсез, төпсез һәм дәлилсез, эштән чыгарып сүгеп килде. Шуның белән бергә, аның ялгышларын күрсәтеп, аңар каршы язучылар булганда, редакция ул әйберләрне бастырмый, Кутуйга җил, яңгыр тидерми саклап килде.

Бу сүзләргә дәлил итеп түбәндәге хәлне китерәм:

Моннан 3–4 ел элек, Музтехникумда композиторлык сыйныфы төзеттереп, үзе шунда профессорлыкны алып, Казанда калырга уйлаган Эйхенвальдның коткысы буенча, Музтехникум директоры Литвинов белән Музтехникум адресы буенча күп ялганнар кыстырып мәкаләләр язылды. Шул вакытта техникумда укучылар, ялгыз-ялгыз һәм күмәкләшеп, чын хәлне күрсәтеп, мәкаләләр яздылар. Ләкин

аларның һичберсенә редакция урын бирмәде. Бу хәл хәзерге көндә дә шулайрак: шул ук шәхси күзлекләр аша узган хосусый фикерләр рәвешендә дәвам итәләр. Хәлбуки тәнкыйтьләр аерым кешеләрнең фикерләре булмастан, тыңлаучы массаның киң катлау пролетариатның, һич булмаса, кечерәк бер түгәрәк җәмәгать эшчеләренең фикерләрен җыйнап, күмәк фикер, күмәк тәэссер һәм хиссият рәвешендә, объектив рәвештә, әсәрләрнең җитеш якларын күрсәтү белән бергә, җитешмәгән якларын ачып салып, шуларны төзәтергә юллар күрсәтү, кай җирен кая таба бору һәм алып бару хакында файдалы киңәшләр бирү рәвешендә барырга тиеш иде. Менә шул хәлдә торган тәнкыйть файда бирмәде һәм бирмәде генә түгел, Лебединскийның соңгы сүзләренә 100% артыгы белән туры килеп, зарар итеп кенә торды.

Сәбәпләрдән тагын берсе нәшрият өстенә төшә. Ул да булса, махсус революцион шигырьләр мәҗмугалары бастырылмау һәм аерым-аерым шагыйрьләрнең шигырьләрен җыеп барган мәҗмугаларның бик аз булуы йә бер дә булмавы. Мин ара-тирә Татиздат кибетеннән кереп, шундый әйберләрне сораштырып карыйм. Ләкин юньле-башлы бер нәрсә дә алганым юк. Ә шагыйрьләрнең төрле журнал, бигрәк тә төрле гәзитләрдә чәчелгән әйберләрен барысын да җентекләп җыйнап бару табигый мөмкин түгел. Бу юклык хәтта шул дәрәҗәгә барып җитә, революцион җырлардан: «Интернационал», «Марсельеза», «Варшавянка», «Похоронный марш» кебек шигырьләрнең җыентыгы да юк. Хәлбуки ул нәрсәләрнең бөтенесенең тәрҗемәләре бар. Мин бер-ике кешегә шул әйберләрне эзләп табып, җыеп бастырырга бирүләрен киңәш итеп тә карадым, ләкин нәтиҗә әле һаман юк.

Музыкаль әсәрләрнең либреттолары музыкаларына ни рәвешле тәэсир иткәнен югарыда язган идем. Шуңар күрә, бу урында сүзне озайтмыйча, бу мәсьәләдә либреттоларның да, әлбәттә, йогынтылары бар дияргә туры килә.

*(Дәвамы бар)*

*Текстны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге фәнни хезмәткәре* ***Фәйзуллина Фәния Галимулла кызы*** *әзерләде*

УДК 811.512.1

*Н.С. Майнагашева*

# КҮРЕНЕКЛЕ ТЮРКОЛОГ НИКОЛАЙ ФЕДОРОВИЧ КАТАНОВ ЮБИЛЕЕ УҢАЕННАН

Статья посвящена жизни и деятельности ученого-востоковеда, тюрколога, этнографа, фольклориста, доктора сравнительного языкознания, экстраординарного профессора Императорского Казанского университета, ординарного профессора Казанской духовной академии, действительного статского советника – Николая Фёдоровича Катанова. Личность Н. Ф. Катанова как истинного учёного, достойного сына своей земли, трудолюбивого и гуманнейшего человека автор ставит в пример в воспитании подрастающего поколения. В научном мире он известен, прежде всего, как лингвист. Наследие Катанова – это многочисленные работы по лингвистике, этнографии, археологии, нумизматике, фольклору и библиографии. Его путь к образованию, к науке вызывает восхищение. Статья приурочена к юбилею великого хакасского ученого мирового уровня.

**Ключевые слова:** Николай Фёдорович Катанов, первый хакасский ученый, деятельность, исследования, тюркология, основоположник, наследие ученого.

The article is devoted to the life and work of an Orientalist, Turkologist, ethnographer, folklorist, Doctor of Comparative Linguistics, Extraordinary Professor of the Imperial Kazan University, Ordinary Professor of the Kazan Theological Academy, State Councilor Nikolai Fedorovich Katanov. The author sets the personality of N.F. Katanov (a true scientist, a worthy son of his land, a hardworking and most humane person) as an example in the upbringing of the younger generation. In the scientific world, he is known primarily as a linguist. Katanov's heritage is numerous works on linguistics, ethnography, archeology, numismatics, folklore and bibliography. His path to education, to science is admirable. The article is dedicated to the anniversary of the great Khakass scientist.

**Key words:** Nikolai Fyodorovich Katanov, the first Khakass scientist, activity, research, Turkology, founder, scientist's legacy.

Шәркыятче галим, тюрколог, этнограф, фольклорчы, чагыштырма тел белеме докторы, Император Казан университетының экстраординар профессоры, Казан духовный академиясенең ординар профессоры, хакыйкый статский советник – болар барысы да Аскиз шәһәрендә дөньяга килгән беренче хакас галиме Николай Фёдорович Катанов турында.

Н.Ф. Катановның иҗтимагый эшчәнлеге дә киңкырлы: ул ике чит ил җәмгыятендә торган – Societe des sciences et lettres (Бельгия) и Ungarische ethnographische Gesellschaft (Венгрия), Гельсингфорс шәһәрендә фин-угор җәмгыяте мөхбир әгъзасы, император Рус география җәмгыяте, император Рус археология җәмгыяте, Мәскәүдә табигать фәннәрен, антропология һәм этнографияне сөючеләр


Николай Федорович Катанов

җәмгыяте, Ташкент шәһәрендә Төркестан археология сөючеләр түгәрәге хакыйкый әгъзасы, Казан һәм Җидепулат-Семипалатинск статистика комитетлары хакыйкый әгъзасы, аеклык җәмгыяте әгъзасы булган.

Н.Ф. Катанов – чын галим, үз халкының лаеклы улы, хезмәт сөючән, максатчан һәм гуманлы кеше. Соңгы ун-унбиш елда, чыннан да, республикада (шулай ук Татарстанда, Тувада, Төркиядә) аның истәлеген мәңгеләштерү һәм мирасын өйрәнү буенча шактый эшләр башкарылды: Хакас дәүләт университеты һәм Хакас милли гимназиясе аның исемен йөртә, конференцияләр үткәрелә [Научное наследие Н.Ф. Катанова..., 2003], аның фәнни хезмәтләре яңадан бастырыла [Катанов, 2004], фәнни монографияләре [Султанбаева, 2006; 2009 һ.б.] нәшер ителә, аның тарафыннан җыелган фольклор материаллары тәрҗемә ителә һәм популярлаштырыла [Фольклор саянских..., 2003]. Аскиз һәм Абакан шәһәрләрендә аңа һәйкәлләр ачылды, Абакан урамнарының берсе Н.Ф. Катанов исеме белән аталды. Болар барысы да – хакас фәненә нигез салучының шәхесенә һәм мирасына җылы, сакчыл мөнәсәбәтнең дәлиле. Быелгы юбилей елында да аның турында күп сөйләнәчәк, Н.Ф. Катановка багышланган күпсанлы чаралар үткәреләчәк. Н.Г. Доможаков, С.Е. Малов, С.Н. Иванов, К.М. Патачаков һ. б. галимнәр озак еллар «онытылуга» дучар ителгән беренче хакас галименең исемен торгызуга үзләреннән шактый зур өлеш керттеләр.

Николай Федорович Катанов кебек галимнең дөньяга килүе очраклы түгел, һәм бу – мөгаен, халык тарихында кабатланмас вакыйга. Катановның тормышын, халыкның фәненә һәм мәдәниятенә керткән өлешен өйрәнү безгә, беренче чиратта, бүгенге көндә дөньядагы урыныбызны аңларга мөмкинлек бирәчәк.

Н.Ф. Катанов – дөньякүләм танылган беренче хакас тюркологы. Фән дөньясында ул, барыннан да элек, лингвист буларак билгеле. Үзенең хезмәтләрендә ул дөньяның 114 теле мәгълүматларын файдаланган. Полиглот Н.Ф. Катанов барлык Европа, күп кенә Азия, шул исәптән латин, борынгы грек, санскрит телләрен белгән. Унике яшендә туган авылыннан киткәндә, ул ике – хакас һәм рус телләрендә генә сөйләшкән. Гимназиядә укыган елларда Николай үзендә тырышлык, үз-үзенә таләпчәнлек, пөхтәлек, тыйнаклык, аралашучанлык кебек бик күп яхшы сыйфатлар тәрбияли. Ул бер генә дәресне дә калдырмый, гимназияне алтын медаль белән тәмамлый. Башка фәннәр белән беррәттән, Николай туган телне өйрәнүгә дә бик зур әһәмият бирә. Н.Ф. Катановның фәнни эшчәнлеге А. Кастрен һәм В. Радлов бастырган хакас текстларын чагыштырып өйрәнү нәтиҗәсе буларак язылган «Описание шаманского бубна и костюма сагайского племени» дигән

беренче публикациясеннән башланып китә. Гимназиядә укыганда ук ул хакас теле буенча ике өлештән торган зур хезмәт яза: «Татарский язык (сагайского наречия). Ч. I. Грамматика (этимология и синтаксис)» (1882), «Грамматика (сагайского наречия) татарского языка. Ч. II. Сборник примеров и словари» (1884), гомуми күләме 800 биттән артып китә.

Үсмер чагында ук үз-үзенә таләпчәнлек тәрбияләп, Н.Ф. Катанов фәнни эшкә һәрчак намус белән карый, бу, һичшиксез, безнең замандашларыбыз өчен дә үрнәк булып тора. В.Е. Майнагашева, аның фәнни этикасы турында фикер йөртеп, болай дип билгеләп үтә: «Трудившийся титанически Н.Ф. Катанов был человеком исключительной честности, щепетильности. По части научной этики он потрясает весьма высокой требовательностью ко всем, кто трудился на научной ниве. Это – поистине священное служение науке. И в этом он, может быть, остаётся недосягаемым образцом для всех» [Майногашева, с. 54–55].

Рус милләтеннән булмаган һәм урта хәлле гаиләдә үскән Н. Катановка классик гимназиядә, ә аннан соң Петербург университетында белем алу, Себер халыклары вәкилләре чиркәү-мәхәллә мәктәбен көчхәл белән тәмамлаган заманда фәнни даирәдә танылу җиңел булмый. Хәер ул вакытта Россиядә җәмгыятьнең барлык катлауларыннан чыгучыларга да, шул исәптән рус милләтеннән булмаганнарга да, белем ишекләре ачыла. Әмма хакаслар арасында грамоталы кешеләр бармак белән генә санарлык була.

Катанов шәхесе, аның Россия һәм дөнья фәне үсешенә йогынтысы турында сөйләгәндә, берничә аспектны аерып күрсәтергә кирәк: беренчедән, Николай Федоровичның тормышы үз заманы өчен гадәти түгел: хакаслар турындагы фән, нигездә, Европа сәяхәтчеләренең хезмәтләреннән генә торганда, ул – ватанга фидакяр хезмәтнең һәм фән сукмагыннан китүнең әһәмиятен аңлау үрнәге булып торды; икенчедән, галимнең фәнни хезмәтләре Көнчыгышны өйрәнү һәм тюркология үсешендә гаять мөһим, ә кайвакыт хәлиткеч роль уйнады. Н.Ф. Катанов мирасы лингвистика, этнография, археология, нумизматика, фольклор һәм библиография буенча күпсанлы хезмәтләрне колачлый. Монда үзенең «Опыт исследования урянхайского языка» дип аталган фундаменталь хезмәтендә, абруйлы тикшеренүчеләрнең фикеренә каршы килеп, урянхай (тува) теленең төрки телләр семьялыгына керүен раслаган галимнең кыюлыгын да ассызыклап китәргә кирәк. Әлеге хезмәте белән Н.Ф. Катанов төрки телләрне чагыштырып өйрәнү методологиясенә нигез сала. Аның биографларының берсе С.Н. Иванов билгеләп үткәнчә, «труд Н.Ф. Катанова представляет собой "колоссальный справочник по всем тюркологическим материалам", собранным к началу XX века, и как свод фактических данных по сравнительной грамматике тюркских языков является основой для дальнейших изысканий в этой области… Капитальный труд Н.Ф. Катанова занимает видное место в классическом наследстве

отечественной тюркологии, являясь единственной в своем роде сводной работой по тюркским языкам» [Иванов, с. 60].

Фәндә зур уңышлар казанып, Н.Ф. Катанов үзен педагог буларак та сынаган. Көчле лектор-эрудитны тыңларга килүчеләр белән аудиторияләр шыгрым тулган, ул катлаулы фәнни проблемалар турында ялкынланып, гади һәм аңлаешлы итеп сөйли белгән. Шәкертләрендә фәнгә кызыксыну уяткан. Тәртибе, патриот, намуслы һәм игелекле булуы белән аерылып торган бу зат һәрвакыт халыкны агарту проблемалары белән янып яшәгән, сәяхәтләрдән һәм экспедицияләрдән кайтып кермәгән, халык белән турыдан-туры аралашырга яраткан. Н.Ф. Катановның һәр кешегә тирән ихтирам белән караган бөек гуманист булуын да истән чыгарырга ярамый.

**Әдәбият**

*Иванов С.Н.* К характеристике лингвистического наследства Н. Ф. Катанова. «Опыт исследования урянхайского языка». Казань, 1903 // Николай Федорович Катанов. Материалы и сообщения / сост. канд. филол. наук Н.Г. Доможаков. Абакан, 1958. С.60.

*Катанов Н.Ф.* Избранные труды о Хакасии и сопредельных территориях / Сост. Угдыжеков С.А. Абакан: Изд-во Хакас. гос. ун-та им. Н.Ф. Катанова, 2004.

*Майногашева В.Е.* Заметки о научной этике Н.Ф. Катанова // Катановские чтения. Сборник статей. Казань: Мастер Лайн, 1998. С. 54–55.

Научное наследие Н.Ф. Катанова и современное востоковедение. Материалы Международной научной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Н.Ф. Катанова. 22–24 мая 2002 г. Абакан: Изд-во Хакас. гос. ун-та им. Н.Ф. Катанова, 2003.

*Султанбаева К.И.* Николай Федорович Катанов – выдающийся ученый-востоковед, тюрколог, просветитель. Абакан, 2009.

*Султанбаева К.И.* Педагогическая система Николая Федоровича Катанова. Казань, 2006.

Фольклор саянских тюрков XIX века. Из собрания доктора языкознания Н.Ф. Катанова. В 2 т. / Сост., переводы, стихотв. перелож., лит. обраб., заключит. статья и коммент. А.В. Преловского. М.: Новый ключ, 2003.

***Майнагашева Нина Семеновна,***
*филология фәннәре кандидаты, Хакасия Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты директоры*
*(Хакасия Республикасы, Абакан)*

УДК 82(091)

***Э.М. Галимҗанова***

# ФАЗЫЛ ТУЙКИН МИРАСЫ: БАРЛАУ ҺӘМ ӨЙРӘНҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

В истории татарской литературы есть такие личности, наследие которых в силу определенных общественно-политических обстоятельств до сих пор оставалось вне поля зрения исследователей. В статье представлен краткий обзор творчества Фазыла Туйкина, ставшего жертвой репрессий 20–30-х годов XX века, и исследована степень изученности его творческого наследия.

Статья посвящена 135-летию со дня рождения Фазыла Туйкина.

**Кючевые слова:** Фазыл Туйкин, творческое наследие, история литературы, история изучения.

In the history of Tatar literature, there are such personalities whose legacy, due to certain socio-political circumstances, has so far remained outside the field of view of researchers. The article presents a brief overview of the work of Fazyl Tuykin, who became a victim of repression in the 20-30s of the XX century, and examines the degree of study of his creative heritage.

The article is dedicated to the 135th anniversary of the birth of Fazyl Tuykin

**Keywords:** Fazyl Tuikin, creative heritage, history of literature, history of study.

XX гасырның 20–30 нчы елларында тоталитар режим тарафыннан хаксызга рәнҗетелеп атып үтерелгән үзенчәлекле шагыйрь, талантлы драматург, тарихчы, фольклорчы, телче, мәгърифәтче педагог һәм публицист Әхмәтфазыл Әхмәткәрим улы Туйкинның тууына 2022 елның 22 июнендә 135 ел тулды.

Фазыл Туйкин – бар гомерен халкыбызга хезмәт итүгә, аң-белем таратуга багышлаган мәгърифәтче, яңа тип мәктәпләр ачу, аларда дөньяви фәннәр укыту өчен көрәш алып барган мөгаллим дә, әдәбиятта, беренчеләрдән булып, тарихи темага мөрәҗәгать итеп, шактый кызыклы һәм мөһим яңалыкларны гәүдәләндергән романтик һәм реалистик рухта әсәрләр иҗат иткән язучы да, татар фольклористикасы өчен мөһим күзәтүләр ясап, XX гасыр башы татар әдәбиятында үз урынын булдырган галим дә.

Хезмәт юлын туган авылы Зәй-Каратайда беренче җәдитчә яңа мәдрәсә ачудан башлап җибәргән мөгаллимнең алдынгы карашлы шәхес булып формалашуына «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем алуы зур йогынты ясый. 1911–1914 елларда Уфада, «Хәкимия» мәдрәсәсендә укыткан елларда, ул танылган язучылар Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов әсәрләре белән якыннан таныша, шулар тәэсирендә үзе дә иҗат итә. 1912 елда «Шура» журналында аның шигырьләре басыла башлый. Шул ук елда 1100 халык җырын туплаган «Җырлар әхтәрисе» китабы, «Ватан каһарманнары», «Тормыш корбаннары» драмалары, «Сугышчы Сатыш әфәнде» хикәясе дөнья күрә.

1913 елда «Кечек тәҗвит», 1914 елда «Әхкәме ислам» исемле дини хезмәтләре, 1919 елда абыйсы Кәбир Туйкин белән берлектә язылган «Төрек тарихы» китабы нәшер ителә.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы — күп кенә иҗтимагый-икътисади, сәяси һәм рухи үзгәрешләр дәвере. Татарлар тормышы да бу чорда шактый үзгәрешләр кичерә. XIX гасырның икенче яртысында мәгариф өлкәсендә укыту методикасы үзгәрә, җәдитчелек хәрәкәте башлана. Җәдитчеләрнең тел реформасы үткәрүе татар матбугаты, әдәбияты һәм сәнгатенең үсүенә китерә. Татар театры, әдәбият һәм сәнгатьнең алга китешенә җирлек тудыра. Шундый шартларда туып-үскән Ф. Туйкинга Россия һәм СССР дигән империяләрнең иҗтимагый тетрәүләре аша үтәргә, өч революция (1905–1907 еллар, 1917 елгы Февраль һәм Октябрь революцияләре) кичерергә, рус-япон, Беренче бөтендөнья сугышы афәтләре аша үтәргә һәм Сталин репрессиясе эзәрлекләүләрен үз җилкәсендә татырга туры килә. Һәм үзе дә шул тоталитар режимның корбаны була.

Әдип иҗади талантын бары тик революциягә кадәрге чорда гына ача алган; әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә эшчәнлек алып барып, җәмәгатьчелеккә берникадәр үз исемен таныткан. Гомумән алганда, унлап китап-җыентыгы басылган; «Фикер», «Шура», «Идел» кебек мәшһүр газета-журнал битләрендә шигырьләре; «Әлислах», «Шура», «Сөембикә»дә тел, әдәбият, тарих, уку-укыту мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләре дөнья күргән.

Ф. Туйкин XX гасыр башы вакытлы матбугатында барган тел, әдәбият, тарих өлкәсенә караган бәхәсләрдән дә читтә калмаган, шулай ук педагогика һәм методикага караган мәкаләләр белән дә чыгыш ясаган. Мәсәлән, 1908 елда «Әлислах» газетасында аның «Бөгелмә өязендә мәктәпләр» язмасы басыла. Мәкаләдән күренгәнчә, Ф. Туйкин һәм аның абыйсы Кәбир шул елларда ук Бөгелмә өязе мәктәпләрендә җәдитчә укытуны кертү, яңа мәктәпләр ачу эшендә башлап йөрүчеләрдән булганнар.

1910 елларда тел һәм имля төзәтү тирәсендә көрәш аеруча кискенләшеп китә. Матбугат битләрендә, бигрәк тә «Шура» журналында ана телен укыту, гомумән, педагогика мәсьәләләре турында кызу бәхәсләр бара. Тынгысыз педагог буларак, Ф. Туйкин да бу бәхәсләрдән читтә калмый. «Шура» журналының 1915 елгы 5 нче, 6 нчы саннарында аның мәктәпләр тормышы турындагы «Мәктәпләребез ни көтәләр?» исемле зур мәкаләсе басыла. Анда ул мәктәпләрнең торышы, яшәешеннән канәгатьсезлек белдереп, уку-укыту өлкәсендә зур үзгәрешләр кирәклеген күтәреп чыга.

Революциядән соң әдипкә иҗат белән шөгыльләнү кыенлаша. 1931 елда ул милләтчелектә гаепләнеп кулга алына, Казанның 1 нче номерлы төрмәсендә 6 ай утырып кайтканнан соң, аңа әсәрләр язу тыела. Ф. Туйкин, бар көчен уку-укытуга багышлап, мәктәпләрдә укытуның эчтәлеген, сыйфатын, программаларны камилләштерү мәсьәләләре белән ныклап шөгыльләнә башлый. Совет мәгарифенең

күп кенә кимчелекләрен бетерү максатыннан, еш кына матбугат битләрендә методик һәм педагогик темаларга мөрәҗәгать итеп, конкрет тәкъдимнәр белән чыга.

Гомеренең соңгы елларында иҗади көчен Казанда оештырылган Гыйльми үзәк белән хезмәттәшлек итүгә багышлый: халык авыз иҗатын җыю, аерым бер системага салып, җыентыклар итеп туплау, аларны фәнни яктан өйрәнү белән шөгыльләнә. Бу юнәлештәге эшчәнлекнең нәтиҗәсе буларак, галимнең «Балалар сәхнәсе», «Ил әдәбияты», «Озын көйләргә халык җырлары» җыентыклары, «Халык әдәбиятын гыйльми, әдәби яктан тикшерү юлында» кебек гыйльми хезмәтләре языла. Кызганычка каршы, алар басылмый кала, югала.

XX гасырның соңгы елларында илдәге вазгыять үзгәреп, халкыбызны аң-белемле итү, милли әдәбиятыбызны үстерү, баету өлкәсендә армый-талмый хезмәт куйган, шул эшкә гомерләрен биргән шәхес культы корбаннарының иҗатларын өйрәнүгә игътибар артты. Шул исәптән, милләтчелектә гаепләнеп, 1938 елның 15 февралендә атып үтерелгән Ф. Туйкинның да мирасын барларга, иҗатын киңрәк планда өйрәнергә мөмкинлекләр туды.

Ф. Туйкинның эшчәнлеген, иҗатын барлау, өйрәнү эшен өч этапка бүлеп карарга була. Беренчесе – революциягә кадәрге чор. Әдип эшчәнлеге белән кызыксыну әсәрләре дөнья күргәннән соң ук башлана. Иҗаты хакында мәгълүмат, тәнкыйть мәкаләләре вакытлы матбугат битләрендә 1912 елда ук басыла башлый. «Ватан каһарманнары», «Тормыш корбаннары» пьесалары «Нур», «Ширкәт», «Сәйяр» кебек киң билгеле һәм һәвәскәр труппалар тарафыннан татарлар яшәгән кайбер шәһәрләрдә уйнала. «Ялт-йолт» журналында – «Тормыш корбаннары» китабы [«Кәлтрифан», б. 4–5], «Йолдыз» [Һатиф] һәм «Вакыт» [Бәкер Кәбир] газеталарында «Ватан каһарманнары» пьесасының «Сәйяр» һәм «Нур» труппалары тарафыннан уйналуы турында мәкалә-рецензияләр басыла. Ф. Туйкинның иҗади эшчәнлегенә классик язучыбыз Галимҗан Ибраһимов та игътибар итә. 1914 елда ул үзенең әдәбияттан дәреслек-хрестоматия итеп төзегән «Яңа әдәбият» исемле китабына аның берничә шигырен урнаштыра һәм «Яңа әдәбият» хакындагы тәнкыйтьләр мөнәсәбәте илә» мәкаләсендә: «Аның кемлеген мин үзем дә белмим, ләкин әсәрләрен газета, журналларда укып яратканымыз хәтеремдә калган», – дип яза [Ибраһимов, 2019, б. 236].

Ф. Туйкин мирасын өйрәнүнең совет чорын ике өлешкә бүлергә мөмкин. Беренче өлеше – 20–30 нчы еллар. 1927 елда «Мәгариф» журналында Габдрахман Сәгъдинең «Беренче дәвер татар әдәбиятына яңа материаллар» исемле мәкаләсе басылып чыга [Сәгъди, б. 64–72]. Бу язмада галим Ф. Туйкинның Мәүлә Колый хикмәтләрен табуы хакында хәбәр итә. Алдагы елларда язучыны эзәрлекләү чоры башлана: иҗат белән шөгыльләнү тыела, әсәрләре матбугатта басылмый. 1938 елда «халык дошманы» буларак атып үтерелгәннән соң, Ф. Туйкинның әсәрләрен басу түгел, исемен дә телгә алырга ярамый.

Җырлары, халык җырлары буларак, телдән телгә күчеп йөри, яисә башка исем белән басыла.

Совет чорының икенче өлеше – Ф. Туйкинның исеме аклангannan алып 90 нчы елларга кадәрге чор. Сталин культы фаш ителгәннән соң, 1958 елның 27 маенда аның гаепсезгә хөкем ителүе хакында карар чыгарыла. Язучының иҗаты белән кызыксыну яңа сулыш ала. 1977 елда Эльмира Шәрифуллинаның «Илебез – кадерле җиребез» исемле мәкаләсе бу юнәлештә беренче ныклы адым була [Шәрифуллина, б. 163–169]. 1987 елда Җәүдәт Миңнуллин белән берлектә язылган «Бүген дә хәрәкәттә» исемле икенче мәкалә дөнья күрә [Шәрифуллина, Миңнуллин, б. 164–168]. Татар әдәби тәнкыйтендә дә әсәрләренең иҗат ысулына караган фикерләр, сәхнә әсәрләренең куелышы хакында язмалар күренә башлый. 80–90 нчы елларда якташлары, туганнары тарафыннан исемен мәңгеләштерү буенча эш активлаша. Зәй-Каратай авылы мәктәбенә һәм үзәк урамга Ф. Туйкин исеме бирелә. Мәктәптә музей оештырыла, яхшы укучы мәктәп балаларына премияләр билгеләнә. Лениногорск шәһәренең «Сугышчан дан» музеенда Туйкиннарга караган материаллар, документлар, истәлекләр туплана башлый. Шушы төбәк газета-журналарында мәгълүмати характердагы мәкаләләр, истәлекләр урын ала.

Татар һәм башкорт әдәби тәнкыйтендә дә Ф. Туйкин әсәрләренең эшләнеше, иҗат ысулларына карата фикерләр күренә. Исеме татар һәм башкорт поэзиясе антологияләренә кертелә, әдәбият тарихына караган хезмәтләрдә иҗатына игътибар арта.

Өченче этап – XX гасырның 90 нчы еллары, үзгәртеп кору чоры. Бу елларда шәхес культы корбаннары булган әдипләрнең иҗатларына да караш уңай якка үзгәрә. Галимнәргә архивларда эшләү мөмкинчелеге туа. Ф. Туйкинның мирасы да тулаем барланып, иҗади эшчәнлеге монографик планда өйрәнелә. Архив документлары нигезендә гомеренең соңгы көннәре ачыклана, эшчәнлегенә объектив бәя бирелеп, исеме халыкка, әдәбиятка кайтарыла, иҗаты фәнни әйләнешкә кертелә. 2006 елда Казанда «Фазыл Туйкин: язучы, телче һәм фольклорчы» исемле хезмәт [Ханнанова-Галимҗанова, 2006], 2007 елда бертуган Кәбир һәм Фазыл Туйкиннарның әсәрләре, хатлары, документлар, истәлекләр тупланган «Бертуган Туйкиннар» исемле тарихи-документаль җыентык [Бертуган Туйкиннар, 2007], Уфада Миңлегали Нәзерголов төзегән «Ватан каһарманнары» [Туйкин, 2007] китаплары дөнья күрә.

1910 елда Габдулла Тукай, балаларга әдәбияттан хрестоматия итеп, «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле җыентык төзи [Тукай, 1910]. 1911 елда Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хатында әлеге китапка әсәрләрнең нинди принциптан чыгып урнаштырылуы хакында: «...шигырьләрнең үзенә һич тә әһәмият бирмичә, фәкать мәгънәви яклары яхшы булганга күрә генә алдым», – ди ул [Тукай, 2016, б. 215]. Ф. Туйкинның да иҗатының башлангыч чорында язылган әсәрләре сәнгатьчә эшләнеше ягыннан, бәлкем, әллә ни уңышка

ирешә алмаганнардыр. Әмма әдипнең дәүләтчелек, ватанчылык идеяләрен яктырткан тарихи әсәрләренең мәгънәви кыйммәте әле дә бар. Дәүләтебезне, милләтебезне, телебезне саклау буенча бер гасыр элек Ф. Туйкин күтәргән мәсьәләләр бүген дә актуальлеген югалтмый.

**Әдәбият**


*Бәкер Кәбир.* *** (8 декабрь...) // Вакыт. 1914. 10 декабрь.

Бертуган Туйкиннар: тарихи-документаль җыентык / Төз.-авт. Эльмера Ханнанова-Галимҗанова. – Казан: Рухият, Җыен, 2007. 592 б.

*Ибраһимов Г.Г.* Әсәрләр: 15 томда. Академик басма. 6 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 327 б.

*«Кәлтрифан».* «Мин сиңа әйтим» // Ялт-йолт. 1912. № 44. Б. 4–5.

*Сәгъди Г.* Беренче дәвер татар әдәбиятына яңа материаллар // Мәгариф. – 1927. № 4. Б. 64–72.

*Туйкин Ф.* Ватан каһармандары. Шигырьзар, йырзар, поэма, хикәйә һәм пьесалар / Текстологик эштәрзе башкарыусы, төзөүсе, баш һүз языусы, аңлатмалар биреүсе филология фәндәре кандидаты Миңлегәли Нәзерголов. Өфө: Китап, 2007. – 200 б.

*Тукай Г.М.* Әсәрләр. 6 томда. Академик басма. 5 т.: мәсәлләр, балалар өчен хикәяләр, автобиографик повесть, юлъязмалар, хатлар (1903–1913)/ төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Г.А. Хөснетдинова, Г.М. Ханнанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 415 б.

*Тукай Г.* Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. Казан: Үрнәк, 1910. 143 б.

*Ханнанова-Галимҗанова Э.* Фазыл Туйкин: язучы, телче һәм фольклорчы. Казан, 2006. 156 б.

*Һатиф.*Татарча театр // Йолдыз. 1912. 23 октябрь.

*Шәрифуллина Э.* Илебез – кадерле җиребез // Казан утлары. 1977. № 6. Б. 163–169.

*Шәрифуллина Э., Миңнуллин Җ.* Бүген дә хәрәкәттә // Казан утлары. 1987. № 6. Б. 164–168.



***Галимҗанова Эльмера Мәхмүт кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге мөдире*

## И.И. САБИТОВА, Э.И. САФИНА, Ф.И. ТАҺИРОВАНЫҢ «ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ КЫЕНЛЫКЛАР СҮЗЛЕГЕ» (Казан: ТӘһСИ, 2019. 184 б.) ТУРЫНДА

Билгеле булганча, сөйләм культурасын күтәрүдә сүзнең дөрес кулланышын, язылышын, әйтелешен, төрләнешен, аерым сүзләр арасындагы мәгънә аерымлыкларын күрсәткән кыенлыклар сүзлегенең әһәмияте бик зур. Әлбәттә, сүзнең мәгънәсен аңлатмалы сүзлектән ачыклап була. Дөрес әйтелеш һәм дөрес язылышны исә орфография һәм орфоэпия сүзлекләреннән карарга мөмкин. Стиль үзенчәлекләрен, ясалышын да махсус хезмәтләрдән укып белергә мөмкин. Әмма әдәби тел нормаларын саклау, дөрес сөйләм күнекмәләрен формалаштыру һәм ныгытуда кыенлык тудырган очракларны бергә туплап, аларны аңлатып биргән хезмәтләр аеруча әһәмияткә ия. Тәкъдим ителгән сүзлек әнә шул максатларны күздә тотып төзелгән. Ул – татар лексикографиясендә мондый типтагы беренче сүзлек. Хезмәттәге төп мисаллар матур әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет челтәре кебек төрле чыганаклардан тупланган. Алар авторлар тарафыннан системалаштырылган, кыенлык тудырган очракларның асылы, төрләре, сәбәпләре, дөрес вариантлары китерелгән. Монда якынча 1400 баш сүз теркәлгән. Сүзлектә бирелгән материалның башка сүзлекләрдән үзгә булуы сәбәпле, сүзлек мәкаләсен оештыру рәвеше дә аерылып тора. Монда сүзнең дөрес яисә ялгыш кулланышын күрсәткән *дөр.* (дөрес) һәм *ялг.* (ялгыш) пометалары файдаланылган. Әлеге тамгаларның мәкалә эчендә урнашуы да төрлечә. Мәсәлән, вокабула итеп алынган сүз үзе дөрес булып, ә ялгыш аның төрләнешендә, стилистик кулланылышында булса, типик хаталарны күрсәткән сүзтезмәләр *ялг.* пометасыннан соң китерелә, иллюстратив материал белән дәлилләнә:

**ЛАГЕРЬ** *и*. Лагерьга, лагере, лагерена, лагерьлар; *ялг.*: **лагерьгә, лагеренә, лагерьләр; лагергә, лагерләр; лагерга, лагеры, лагерына, лагерлар**. *Хөкем урыны итеп иң куркыныч дәүләт җинаятьчеләре сөрелә торган Рогервик* ***лагеры*** *билгеләнә*. Г. Мөхәммәтшин. *Җәйге* ***лагерга*** *сыер саварга мин төшеп киттем*. Мәйдан.

Баш сүз итеп хаталы сүз алынганда, ялг. пометасы сүз төркемен күрсәткәннән соң ук урнаша, аннан иллюстратив материал бирелә һәм дөр. пометасы белән татар теле өчен норма булган кулланыш теркәлә:

**МӘШГҮЛЬ** *хәб. сүз. ялг. Үз дөньябыз белән* ***мәшгүль*** *булыйк, Яхшылык бит тормыш безгә!* К. Фатыйхова-Бәдретдинова. *Анда һәркем үз биографиясе, тормышта ирешкән уңышлары, балалары, оныклары турында, бүген ни белән* ***мәшгүль*** *булуын сөйли.* Мәйдан; *дөр.*: **мәшгуль**.

Пометаларны шул рәвешле урнаштыру дөрес һәм хаталы куллану очракларын чагыштырып истә калдыруны җиңеләйтә.

Күренә ки, хаталы баш сүз итеп, нигездә, орфоэпия, орфография, сүзьясалыш нормаларына җавап бирмәгән сүзләр алынган. Сүзлекләр норматив функция башкарганга, ялгыш кулланылган сүзләрне вокабула итеп чыгару, беренче карашка үзен акламый кебек. Әмма кыенлыклар сүзлегенең спецификасын, үзенчәлеген, кулланучы ихтыяҗыннан чыгып эшләнүен исәпкә алганда (ә кеше дөрес кулланышны белмәскә, хатаны хата дип уйламаска да мөмкин), сүзләрне нәкъ шулай теркәү кулай икәнлеге ачыклана. Ул ялгыш вариант аша да дөрес вариантны табу мөмкинлеген тудыра.

Кыенлык охшаш яңгырашлы яки язылышлы пароним сүзләрне яки омонимнарны куллануда булса, аларның мәгънә аермасын күрсәтү өчен кыскача аңлатмалар бирелә һәм *чаг.* пометасы белән берсе икенчесенә җибәрелә:

**ОРИГИНА́Л** *и.* Төп нөсхә; күчерү, яңадан бастыру өчен хезмәт иткән нәрсә; оригинальлеге белән танылган кеше; *ялг.:* **оригинал рәсем, оригинал язу**. *Ә менә «Отдамся в добрые руки» дигән* ***оригинал*** *язулы футболка киеп йөргән Салаватны гына үзенә алучы изге җаннар табылмады*. Тамаша. *Мамадышның Совет урамында беркетелгән территорияләрдә фигураларны иң* ***оригинал*** *бизәү буенча 1 нче урын – Белоснежка һәм җиде гном композициясе өчен «Коррекцияләү мәктәбе»нә һәм «Боз капкалар» фигурасы өчен «Мамадыш ТКХ» коллективларына бирелде*. Мамадыш муниципаль районы ММЧ мәгълүмати сайты; *чаг.:* **оригиналь**; *к.* **вокаль**.

**ОРИГИНА́ЛЬ** *с.* Төп, оригинал булган; башкаларга охшамаган; мөстәкыйль иҗат нәтиҗәсендә туган: **оригиналь образ, оригиналь номер, оригиналь әсәр**; *чаг.:* **оригинал**; *к.* **вокаль**.

Телдә норма һәм норма булмаган күренешләр турында сөйләгәндә вариантлар мәсьәләсе дә килеп баса. Сүзлек авторлары әлеге проблемага да игътибар иткәннәр. Мондый сүзләр янында *вар.* пометасы кулланылган һәм аларның вариант статусын алуы аңлатыла:

**ГАЗЕ́ТА** *и. вар. Беркөнне ул,* ***газеталарны*** *укыгач, бик озак нидер исәпләде.* А. Алиш. ***Газетаның*** *үз хәбәрчесе булып эшләгән елларымда бер зур түрәдән интервью алдым*. А. Хәсәнов. *Бу хакта күптән түгел* ***газетада*** *язганнар иде.* А. Тимергалин.

Кайбер алынмалар татар теле тарафыннан өлешчә үзләштерелеп, ***котлет, резин, фанер*** кебек сүзләрдә сүз ахырында ***-а*** сузыгы апокопа кичереп төшеп кала. Бу әдәби тел өчен норма булып санала. Аларны чыганак телдәгечә тулы язылышта куллану стилистик вариант булып тора.

Шунысын да әйтергә кирәк: сүзлек сүзләрнең ялгыш кулланылышын күрсәтү белән генә түгел, ә дөрес язу, сөйләү кагыйдәләре

бирелүе белән дә кыйммәтле. Кыен очракларны хәл иткәндә, авторлар төрле лексикографик чыганакларга, лексикология, сүзьясалыш, орфоэпиядән фәнни хезмәтләргә мөрәҗәгать иткәннәр, язучылар телен анализлаганнар. Сүзлек мәкаләсенең бу өлеше компактлы, ул сүзлекне сүзлек буларак кабул итүгә зыян итми.

Гомумән алганда, сүзлек татар телен өйрәнүчеләргә, татар телендә сөйләшүчеләрнең һәркайсына файдалы булачак. И.И. Сабитова, Э.И. Сафина, Ф.И. Таһированың «Татар теленең кыенлыклар сүзлеге» уңай бәяләнергә хаклы. Ул белешмәлек һәм гамәли кулланма буларак, мәктәп укучылары, татар филологиясен өйрәнүче студентлар, татар теле укытучыларына тәкъдим ителә.

***Галимова Ольга Николаевна,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

**2022 елның 22 апрелендә** Габдулла Тукайның Казандагы әдәби музеенда Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән берлектә «Габдулла Тукай хәзерге социомәдәни киңлектә» дигән темага түгәрәк өстәл оештырылды. Чарада галимнәр, язучылар, вакытлы матбугат вәкилләре катнашты. Түгәрәк өстәл кысаларында Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык (ФАДН) оештырган «Ключевое слово» конкурсының «Иң яхшы фәнни проект» номинациясендәге лауреаты – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әзерләнгән һәм нәшер ителгән «Габдулла Тукай тормышы һәм иҗаты хроникасына материаллар» дигән өч томлы басма тәкъдим ителде.

**2022 елның 22 апреленнән 4 маена кадәр** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге фәнни хезмәткәрләре – сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова, сәнгать фәннәре кандидаты Людмила Шкляева Урал буе шәһәрләрендә һәм авылларында татар йортларын бизәүнең төбәк, милли һәм җирле үзенчәлекләрен өйрәнде. «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020–2024 еллар)» дәүләт программасы кысаларында үткәрелгән экспедиция маршруты Екатеринбург, Магнитогорск, Оренбург, Троицк, Уфа, Чиләбе шәһәрләрен, шулай ук Курган өлкәсен (Шадрин һәм Шатров районнары) үз эченә алды. Сәфәр барышында Милли-мәдәни мохтарият активистлары белән очрашулар узды, урындагы музейларның фәнни хезмәткәрләре, гамәли сәнгать осталары, рәссамнар белән элемтәләр урнаштырылды.

Моннан тыш, 2022 елның 14–20 маенда Пермь краена оештырылган экспедиция барышында татар йортларын бизәүнең төбәк, милли һәм җирле үзенчәлекләрен ачыклау буенча эш алып барылды. Пермьнең Туган якны өйрәнү музеенда, Пермь сәнгать галереясында булган татар декоратив-гамәли сәнгать коллекцияләре өйрәнелде, ук татар Милли-мәдәни мохтарият әгъзалары белән очрашулар үткәрелде.

**2022 елның 25–26 апрелендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә татар әдәбияты классигы, галим, сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 135 ел тулуга багышланган «Галимҗан Ибраһимов һәм XX–XXI гасырлар татар белеме» дигән темага Халыкара фәнни-гамәли семинар узды. Чарада түбәндәге мәсьәләләр буенча фикер алышу оештырылды: Г. Ибраһимовның иҗтимагый-сәяси, мәдәни, мәгърифәтчелек һәм оештыру эшчәнлеге; Г. Ибраһимовның әдәби иҗаты һәм фәнни хезмәтләренең төрки дөньядагы роле; Г. Ибраһимов хезмәтләрендә татар теле проблемалары һәм XX–XXI гасырларда татарларда тел белеме үсеше; XX гасырның беренче чирегендә милләтне формалаштыруда, татар җәмгыяте, мәдәнияте үсешендә җитәкче-лидерларның роле.

Семинар эшендә Казан, Уфа, Ижау, Якутск, Мәскәү һ.б. шәһәрләр, шулай ук Казакъстан,

Кыргызстан, Азәрбайҗан, Төркия галимнәре, академик структуралар, югары уку йортлары, иҗат интеллигенциясе вәкилләре, «Казан утлары» журналының 100 еллыгына багышланган чаралар кысаларында Татарстанга килгән кунаклар катнашты.

Махсус оештырылган күргәзмәдә соңгы елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан нәшер ителгән китаплар, фәнни хезмәтләр, шул исәптән Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең 15 томлы яңа басмасы тәкъдим ителде. Институтның әдәбият белеме бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов чарада катнашучыларны яңа басманың авторлар коллективы белән таныштырды, хезмәтнең эчтәлеге, үзенчәлекләре турында сөйләде.

**2022 елның 26 апрелендә**, татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көнендә, мәркәзебез Казанда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары игълан ителде. Г. Тукай бүләгенә быел түбәндәге шәхесләр лаек дип табылды: язучы Ләбиб Лерон – «Җил көймәсе» (Мәгариф, 2009), «Әкиятче малай» (Татарстан китап нәшрияты, 2016) китаплары өчен; рәссам Анатолий Егоров – «Над Казанью луна» гобеленнар циклы өчен.

Лауреатларга премияне Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында үткәрелгән тантаналы чарада Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов тапшырды.

**2022 елның 21 маенда** Болгар шәһәрендә Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан Изге Болгар җыены узды. Чарада Россия Федерациясенең Ислам хезмәттәшлеге оешмасы каршындагы махсус вәкиле Рамазан Абдулатипов, Россия Президенты администрациясенең Эчке сәясәт идарәсе башлыгы Анатолий Вылегжанин, Россия Федерациясе Мәдәният министры урынбасары, Федераль оештыру комитетының җаваплы сәркатибе Ольга Ярилова, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Премьер-министры Алексей Песошин, Татарстан Республикасы вице-премьеры, Бөтендөнья татар конгрессы «Милли Шура»сы рәисе Васил Шәйхеразыев, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Россия мөфтиләре, төрле төбәк дини оешма җитәкчеләре һ.б. катнашты. Гомумән алганда, чарага 20 меңнән артык кеше килде.

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү чарасы көрәш буенча Дөнья кубогына ярышлар, концерт программасы белән дәвам итте – «Илаһи моң» рухи мирас әсәрләрен башкаручыларның төбәкара конкурсы лауреатлары һәм республиканың әйдәп баручы иҗат коллективлары, танылган рухи музыка башкаручылар чыгыш ясады, Татарстан мөфтияте махсус күргәзмә оештырды.

**2022 елның 30 мае – 10 июнендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан Чувашия Республикасы

территориясендә татарлар күпләп яшәгән Батыр, Комсомол һәм Шомыршы районнарына комплекслы фәнни экспедиция оештырылды. Филология фәннәре кандидаты, халык иҗаты бүлеге мөдире Илмир Ямалтдинов җитәкчелегендә галимнәр төркеме Озын Куак, Шыгырдан, Кызыл Камыш, Кызыл Чишмә, Яңа Чепкас, Татар Согыты, Татар Тимәше, Кече Шыгырдан, Кыр Бикшиге, Имәнкисәге (Батыр районы), Тукай, Урмай, Чичкан, Татар Шырты (Шырт), Әлебаш, Татар Юашкасы, Каенлык, Әхмәт (Комсомол районы), Өч Балтай, Байтирәк, Әсән (Шомыршы районы) авылларында эш алып барды. Кыр тикшеренүләре барышында галимнәр биредә көн күрүче татарларның милли-мәдәни мирасын өйрәнделәр, халык авыз иҗаты, аларның теле, сәнгате, музыкасы, археографиясе, эпиграфикасы, шулай ук традицион мәдәнияте буенча бай материал тупладылар.

**2022 елның 31 маенда** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Идел буе Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган чаралар кысаларында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әзерләнгән яңа китаплар тәкъдим ителде. Институт директоры, филология фәннәре докторы Ким Миңнуллин халкыбызның мәдәнияте һәм сәнгате, авыз иҗаты, язма әдәбияты нигезләре формалашуның турыдан-туры Идел буе Болгар дәүләте, шунда яшәгән ата-бабаларыбызның рухи мирасы белән бәйлелеген билгеләп үтте, кабер ташлары Болгар чорларыннан ук килүче язма истәлекләрнең берсе булуын, аларны өйрәнүнең татар халкының мәдәни тәңгәллеге турындагы күзаллауларны киңәйтергә мөмкинлек бирүен ассызыклады.

Чарада ике яңа басма тәкъдим ителде: «Татар эпиграфик традициясе. XIII–XIV гасырлар болгар эпиграфик ядкярләре» (Татарская эпиграфическая традиция. Т. 1: Булгарские эпиграфические памятники XIII–XIV вв. Кн. 1. / Авт.-сост.: Гумеров И.Г., Ахунов А.М., Усманов В.М. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2021. 160 с.; Татарская эпиграфическая традиция. Т. 1: Булгарские эпиграфические памятники XIII–XIV вв. Кн. 2. / Авт.-сост.: Гумеров И.Г., Ахунов А.М., Усманов В.М. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2021. 160 с.) һәм «Идел буе Болгар дәүләте язма истәлекләре» (Духовное наследие: поиски и открытия. Письменные памятники Волжской Булгарии = Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Идел буе Болгар дәүләте язма истәлекләре / редкол.: И.Г. Гумеров (рук. проект., ответ. ред.), Г.М. Давлетшин, А.М. Ахунов; сост.: Н.Г. Гараева, Л.Ш. Гарипова. Казань: ИЯЛИ, 2022. Вып. 12. 300 с.).

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, фәнни оешмалар, вакытлы матбугат вәкилләре һ.б. катнашында узган түгәрәк өстәлдә татар халкының рухи мирасын саклау мәсьәләләре турында сүз барды. Татарстан Фәннәр академиясе вице-президенты, филология фәннәре докторы Дания Заһидуллина галимнәр тарафыннан бу юнәлештә алып барылган эшнең мөһимлеген һәм аны алга таба да дәвам итү зарурлыгын ассызыклады.

**2022 елның 31 маенда** Казан (Идел буе) федераль университе-

тының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында Казакъстан Республикасының Казан шәһәрендәге консуллыгы, Абай исемендәге Казакъ милли педагогика университеты белән берлектә казакъ халкының олы остазы Әхмәт Байтурсынулының тууына 150 ел тулу уңаеннан конференция үткәрелде.

**2022 елның 15 июнендә** Г. Тукайның Казандагы әдәби музееның күргәзмәләр залында Татарстан Республикасының халык рәссамы Мөдәрис Минһаҗевның «Төсләрдә милли хисләр» дип аталган күргәзмәсе ачылды. Әлеге күргәзмә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, халык рәссамы Мөдәрис Минһаҗевның ярты гасырлык иҗади эшчәнлегенә багышланган. Рәссамның үз халкына, аның тарихына ихтирамы, милли традицияләргә тугрылыгы чагылыш тапкан күргәзмә тамашачылар хозурына тәкъдим ителде. Мөдәрис Минһаҗев – Россия гуманитар фәннәре академиясенең шәрәфле академигы, Шамил Бикчурин исемендәге премия лауреаты, алты йөздән артык эше Татарстанда, Мәскәү, Санкт-Петербург, Бакчасарай, Симферополь һ.б. шәһәрләрдә күрсәтелгән.

**2022 елның 16 июнендә** Казакъстанның Актау шәһәрендә Әхмәт Ясәви исемендәге Халыкара казакъ-төрек университетында төрки халыклар мифологиясе өлкәсендә зур хезмәтләр авторы Серикбол Кондыбайга багышланган «Серикбол Кондыбай һәм төрки мифология» дип аталган III халыкара фәнни-теоретик конференция узды. Халыкара конференция эшендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан Институтның баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Лилия Мөхәммәтҗанова катнашты, галимә «Төрки мифологиягә караган язма чыганаклар һәм аларның халык тарихын торгызудагы әһәмияте» дигән темага онлайн-доклад белән чыгыш ясады.

**2022 елның 16 июнендә** «Интертат» электрон газетасының 20 еллыгы уңаеннан «Шагыйрьләр урамы» дип аталган яңа рухтагы шигъри җыен үткәрелде. Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә Шигърият бәйрәменә төрле буын татар шагыйрьләре җыелды.

Шигърият бәйрәме Милли китапханә һәм Язучылар берлеге белән берлектә оештырылды. Кичәдә Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ, Разил Вәлиев, Ренат Харис, Марсель Галиев, Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Илсөяр Иксанова, Рәмис Аймәт, Гөлүсә Батталова, Луиза Янсуар, Йолдыз Миңнуллина, Лилия Гыйбадуллина, Рүзәл Мөхәммәтшин, Резеда Гобәева, Рифат Сәлах, Эльвира Һадиева, Булат Ибраһим, Фәнил Гыйләҗев, Ләйлә Хәбибуллина, Гүзәл Закирова, Миләүшә Гафурова һ.б. катнашты.

**2022 елның 17 июнендә** Казакъстан Республикасында Уральскиның Дуслык Йортында «Габдулла Тукай: тормышы һәм иҗаты» дип исемләнгән өч томлы басманы тәкъдим итү чарасы оештырылды. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының галим-тикшеренүчеләре

Марсель Ибраһимов һәм Әнисә Алиева әлеге уникаль хезмәтне эшләү үзенчәлекләре турында сөйләде. Хезмәтнең беренче томы тулысы белән Тукайның иҗади туган ягы Уральскида (Җаекта) үткәргән тормышына багышланган.

**2022 елның 17–18 июнендә** Ульяновск шәһәрендә XXII федераль Сабан туе оештырылды. Татар халкының төп милли бәйрәменә Россиянең төрле төбәкләреннән кунаклар җыелды. Ульяновск шәһәре ипподромында ат чабышлары узды, ә кичен сәнгать осталары концерт куйды. XXII Федераль Сабан туенда 40 меңнән артык кеше катнашты.

**2022 елның 20–22 июнендә** Казан шәһәрендә, Татарстан Республикасы, Милләтләр эшләре буенча Федераль агентлыкның финанс ярдәме белән «Күпмилләтле дәүләт шартларында туган телләрне саклау һәм үстерү: тел сәясәте, проблемалар һәм перспективалар» төбәкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Чараны ЮНЕСКО «Информация для всех» Программасының Россия комитеты, Төбәкара китапханә хезмәттәшлеге үзәге, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Гамәли семиотика институты, Татарстан Халыклар дуслыгы йорты оештырды.

Конференциядә Татарстан Республикасыннан һәм Россиянең башка төбәкләреннән әйдәп баручы экспертлар, галимнәр, халыкара һәм Россия тел сәясәте өлкәсендәге белгечләр катнашты.

**2022 елның 22–25 июнендә** Саха (Якутия) Республикасында Татарстан көннәре узды. Аның барышында Якутия халкын һәм кунакларны республика мәдәнияте, гореф-гадәтләре һәм йолалары белән таныштыру өчен киң программа тәкъдим ителде. Мәдәни программа Татарстан киносы көннәре белән ачылып китте. Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан Саха (Якутия) әдипләре белән хезмәттәшлекне ныгытуга юнәлтелгән чаралар комплексы тәкъдим ителде, Татарстан театрлары һәм сәнгать әһелләре үзләренең тамашаларын күрсәтте. Мәгариф, мәдәният һ.б. өлкәләрдә төрле оешмалар белән хезмәттәшлек турында килешүләр төзелде.

**2022 елның 27–29 июнендә** Казан шәһәрендә татар теле һәм әдәбияты укытучыларының VIII Бөтенроссия съезды үткәрелде. Чараның төп оештыручысы – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Съездда Россиянең төрле төбәкләреннән 400 гә якын вәкил катнашты. Алар арасында мәгариф бүлекләре вәкилләре, милли мәгариф өчен җаваплы методистлар, татар телендә белем бирүче мәгариф оешмалары директорлары, милли-мәдәни автономия вәкилләре, Россия субъектларындагы Татарстан Республикасы вәкиллекләре һәм Бөтендөнья татар конгрессы бүлекләре вәкилләре бар иде. Өч көн дәвамында мөгаллимнәр өчен төрле юнәлештәге күргәзмәләр, экскурсияләр, мастер-класслар һәм тренинглар оештырылды. Панель дискуссияләрдә алдынгы

педагогик эшчәнлек тәкъдим ителде.

Съездның пленар утырышы 29 июньдә «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов катнашында узды.

**2022 елның 27 июненнән 8 июленә кадәр** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Пенза өлкәсенең Каменка, Белински, Пачелма, Вадински, Спасск районнарындагы татар торак пунктларына комплекслы экспедиция оештырды. Аның максаты – татар халкының рухи һәм язма мирасы, матди һәм традицион музыкаль мәдәнияте, сәнгате буенча материаллар җыю һәм өйрәнү. Экспедиция составында халык иҗаты, лингвистика, этномузыкология, халык һөнәрчелеге һәм кәсепләре, археография һәм эпиграфика буенча галимнәр эшләде. Пенза өлкәсендә татарлар яши торган торак пунктларның күп булуын исәпкә алып, бу төбәккә Институт тарафыннан инде өченче экспедиция оештырыла. 2019 елда галимнәр Неверкина, Кузнәй, Сосновоборск районнарында эшләсә, 2021 елда Лопатино, Шемышейка, Городишче, Исса, Лунино районнарында кыр тикшеренүләре алып барган иде.

***Мөхтәрәм авторлар!***

«Фәнни Татарстан» журналы татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере темаларын яктырткан мәкаләләрне бастырып, киң җәмәгатьчелеккә таратуны күздә тота.

Материалларга түбәндәге таләпләр куела:

Мәкалә тексты *.doc форматында җыела, аерым хезмәтләрдән алынган өзекләр, сылтамалар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Файл автор фамилиясе белән исемләнә (Әхмәтов. doc).

Мәкаләгә түбәндәге мәгълүматлар өстәлә:

– авторның фамилиясе, инициаллары

– мәкалә исеме (татар һәм рус телендә)

– аннотация (рус һәм инглиз телендә)

– төп сүзләр (рус һәм инглиз телендә)

– сылтамалар.

Мәкаләдән тыш, *.doc форматында аерым файлда автор турында мәгълүмат җибәрелә (исеме, әтисенең исеме, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, вазифасы, электрон адресы һәм телефоны).

Сылтамалар текст азагында ГОСТ Р 7.0.5-2008 таләп иткәнчә алфавит тәртибендә урнаштырыла.

Мәкалә белән бергә аңа карата фән докторы яки фән кандидаты тарафыннан язылган рецензия җибәрелә.

Редакциягә килгән мәкаләләр шулай ук бәйсез рецензияләүгә тәкъдим ителә, мәкаләне басмага алу-алмау аның нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12, 1 нче кат, 10 нчы бүлмә
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

*Уңышлар теләп һәм Сезнең белән хезмәттәшлек
итүебезгә өмет баглап,
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе*

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2022. № 2

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 30.06.2022. Басылды: 15.07.2022.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 12. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшриятында басылды
(нәшрият адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал бушлай таратыла